Татарстан Фәннәр Академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН: МИРАСЫ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

Фәнни конференция материаллары
Казан, 16 ноябрь 1999 ел

Казан — 2003

Институт истории им. Ш.Марджани
Академии наук Татарстана

РИЗАЭДДИН ФАХРЕДДИН: НАСЛЕДИЕ И СОВРЕМЕННОСТЬ

**Материалы научной конференции
Казань, 16 ноября 1999 года**

Казань — 2003

ББК
С

Редакцион коллегия: Р.М.Әмирханов, И.К.Заһидуллин, Р.Әмирхан

Җаваплы редактор: Равил Әмирхан

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН: МИРАСЫ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН: Мәкаләләр җыентыгы. Казан, 16 ноябрь 1999 ел./Редколлегия: Р.М.Әмирханов и др.- Казань: Изд-во Института истории АН РТ, 2003. - 332п с.

Җыентык Казанда, 1999 елның 16 ноябрендә Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 140 ел тулуга багышланган фәнни конференциядә укылган нотыклар һәм чыгышлар нигезендә төзелде. Җыентыкка кергән мәкаләләр авторлары тәкъдим иткән телдә басылды.

Сборник составлен на основе докладов и выступлений на научной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Ризаэддина Фахреддина, состоявшейся в Казани 16 ноября 1999 года. Статьи, включенные в сборник, публикуются на представленном их авторами языке.

ISBN

© Институт истории АН РТ, 2003

Равил Әмирхан

Р.ФӘХРЕДДИН МИРАСЫН БАРЛАУ ЮЛЫНДА (КЕРЕШ СҮЗ)

Милли тарих фәненең нигез ташларын түшәгән Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Һ.Атласи, Г.Әхмәров, Г.Гобәйдуллин, Ә.-З.Вәлиди һәм башка галимнәрнең иҗади эзләнүләре татар халкы рухи байлыгының аерылгысыз өлешен, тоныкланмас сәхифәләрен тәшкил итә. Соңгы 60-70 ел дәвамында шушы олы мирасны бөтенләй инкяр итү яки күрмәмешкә салышу совет гуманитар фәненең миңле тамгасы булды, татар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә XIX йөз азагы - XX йөз башында калыпланып җиткән традицияләрнең өзелүенә китерде. Милли мираска карашның бүген уңай якка үзгәрүен - илдә барган иҗтимагый-сәяси тормыш чагылышы гына түгел, бәлки татар гуманитар фәне үсешендә мөһим бер этап, үзенә күрә бер яңарыш чоры дип бәяләргә кирәктер.

Шушы принциптан карагандa, даны бөтен төрки, хәтта ки ислам дөньясында киң таралган, Европа, Америка илләрендә яхшы мәгълүм булган акыл иясенең мирасын барлау, кылган гамәлләрен һәм иҗатын өйрәнү, аларга объективүлчәмле бәя бирү - үтә актуаль күренешләрнең берсе буларак күзаллана. Бу адымнар башлыча Ризаэддин бине Сәйфеддин бине Фәхреддиннең тәрҗемәи хәлен тәмамән ачыклау, хезмәтләрен нәшер итү, иҗатына һәм тормыш юлына багышланган китаплар, мәкаләләр язу, биографик җыентыклар чыгару, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү, аның исемендәге музейлар, гимназияләр ачу, эшчәнлеген чагылдырган диссертацияләр яклау, мирасын төрлечә пропагандалау һ.б. юнәлешләрдә бара. Әлеге күркәм эшләр беренче чиратта Казан галимнәреннән М.Гайнуллин, М.Госманов, А.Фәтхи, М.Әхмәтҗанов, Ә.Хәйри, Б.Солтанбеков, Х.Миңнегулов, Р.Мәрданов, Р.Бикмөхәммәтов, Уфа галимнәреннән Ә.Харисов, Г.Хөсәенов, Р.Үтәбай-Кәрими, Ф.Баишев, Оренбургта яшәп иҗат иткән энтузиаст тарихчы М.Рәхимкулова исемнәре һәм иҗтиһадлары белән бәйле.

Совет чоры историографиясендә Р.Фәхреддин беркадәр уңай яктан 60 нчы елларда гына телгә алына башлады. Анда да баштарак аның турында гомуми проблемалар кысасында гына сүз йөртергә мөмкин булды. 60 нчы еллар азагына таба бу җәһәттән сулышлар иркенәебрәк китте, бөек шәхеснең үз исемен үзәккә алган язмалар, тикшеренүләргә юл ачылды. Әмма әле Р.Фәхреддингә сак килү, бәяләмәләрне төрле «ләкин»нәр белән аралаштыру галәмәте, фәлсәфи, дини эшчәнлеген читләтеп, нигездә әдәбият өлкәсенә генә кагылу көчендә иде. 70 нче еллар яңа мөмкинлекләр алып килде: Риза казый хакында артык җәелеп, казый-мөфтилегенә уңай төсмер биреп сөйләргә мөмкинлек булмаса да, татар әдәбияты, журналистикасы һәм публицистикасында ул инде мәртәбәле урын били башлады, кулъязма мирасының кыйммәте, аны өйрәнүнең зарурлыгы мәсьәләсе күтәрелде. Тора-бара бу барлау, тикшеренү идеясе яңа куәт алды, мирасы җентекләп өйрәнүне көтә дигәнрәк әһәмиятле фикерләр әйтелде.

Ниһаять, бөек галимнең 125 еллыгы (1984) уңае белән аның хакында бөтен бер тикшеренүләр «ташкыны» барлыкка килде. Казан һәм Уфа галимнәре вакытлы матбугатта Риза казый эшчәнлегенең төрле тармакларын колачлап, дистәләгән язмалары белән чыгыш ясады, аның биографиясенә, төрле документларны, шәҗәрәләрне тәфтишләү нигезендә ачыклыклар кертелде. Хәер, әле бу чорда да галимнең эшчәнлеген тулаем уңай бәяләү мөмкинлекләре ярыйсы ук чикләнгән иде. «Катлаулы чорның каршылыклы вәкиле» дигән мәкаләнең (авторы М.Г.Госманов) исеме генә дә (Казан утлары, 1984, № 1) бу хасиятне шактый ачык чагылдыра. 1984-1989 еллар арасында Р.Фәхреддин мирасын өйрәнү, аның исемен тулы мәгънәсендә торгызу эше, әкренлек белән булса да, алга барды. Проблема яңа куелышта Советлар иле кысаларыннан чыгып, чит илләргә дә таралды: олпат галим, дин әһеле хакында төрек һәм гарәп телләрендә язмалар дөнья күрде. Р.Фәхреддин шәхесенә һәм иҗатына яңа чалымнар, бәяләмәләр

өстәүдә башкортча һәм урысча басылып чыккан рисалә дә (Творчество Ризы Фахретдинова. Исследования, материалы. Уфа, 1988) мәгълүм уңай роль уйнады.

1989 ел, Р.Фәхреддинне тәкъдир итү мәгънәсендә, яңа дәвер ачты. Чөнки нәкъ шушы чордан башлап, Октябрь түнтәрешеннән соң тәүге тапкыр дип әйтерлек Риза казый әсәрләре өлешчә булса да халыкка яңадан кайта башлады. «Казан утлары»ның 1989 елгы январь санында бөек галимнең «Болгар вә Казан төрекләре» хезмәтенең журнал варианты дөнья күрде (әзерләүчесе Ә.Хәйри). 1993 елда исә бу өлкәдә тагын да алга китеш күзәтелде: Татарстан китап нәшриятында «Болгар вә Казан төрекләре» инде күләмле китап булып басылды (төзүчесе Ә.Хәйри). Шушы ук хезмәт Ә.Мәңгәр вакыфы ярдәме белән Казанда латин графикасында нәшер ителде (1997) һәм гомумтөрки яңгыраш алды.

«Мирас» журналы гамәлгә куелгач, Р.Фәхреддиннең иҗат үрнәкләрен киң катлам укучыларга җиткерү эше тагын да җанланып китте. 1991-1995 елларда бөек галим, мәгърифәтче һәм дин эшлеклесенең «Ислам дине нинди дин?», «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» дип исемләнгән күләмле хезмәтләре журналның буеннан-буена сузылып басылып килде (әзерләүчесе Ә.Хәйри). Биредә Р.Фәхреддиннең янә «Мәшһүр хатыннар» китабыннан өзекләр, Болгар тарихы, Казан ханнары (1994,1996,1997) буенча кыскача язмалары урнаштырылды (әзерләүчесе нигездә Ә.Хәйри). Шушы күркәм традицияне дәвам итеп, Ә.Хәйри «Ялкын» журналында Риза казыйның «Әһле гыял» (1996-1997), «Сабыйга»да (татар һәм урыс телләрендә) - «Тәрбияле бала» (1996), «Идел»дә - «Нәсыйхәт»нең барлык өч кисәген әзерләп бастырды (2000).

1993 - 1995 елларда «Татарстан», «Мирас», «Идел» журналларында, өлешчә «Шәһри Казан» гәзитендә Ризаэддин Фәхреддиннең Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан, Касыйм ханнары турындагы, ә «Мәгариф» журналында 1996-1999 елларда үгет-нәсихәтләре бөтен бер мәкаләләр

тезмәсе сыйфатында дөнья күрде (әзерләүчесе Р.Әмирхан). Тарихи проблемаларны колачлаган әлеге язмалар «Казан ханнары» (1995), «Алтын Урда ханнары» (1996) исемле аерым китаплар рәвешендә Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты (төзүчесе Р.Әмирхан).

Р.Фәхреддин хезмәтләрен әзерләп бастыру, популярлаштыру юлында туган як тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче галимә Мәдинә апа Рәхимкулова зур эш башкарды һәм төрле ысуллар белән казый вә мөфтинең «Әхмәд бай» (1997, татар һәм урыс телләрендә), «Җәвамигуль кәлим шәрхе» (1995, Р.Үтәбай-Кәрими белән берлектә), «Комментарии к изречениям Мухаммеда» (1998) китапларын мәйданга куйды.

Шул ук елларда Риза казыйның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән күләмле монографияләр, фәнни-биографик һәм юбилей җыентыклары дөнья күрде. Болар хисабына беренче нәүбәттә Ф.Баишевның «Общественно-политические и нравстенно-этические взгляды Риза Фахретдинова» (1996), Г.Хөсәеновның «Ризаитдин бин Фәхретдин» (1997), М.Рәхимкулованың «Ризаэтдин бин Фәхретдингә 140 яшь тулу мөнәсәбәте белән (1859-1936)» (1998), Р.Мәрданов, Р.Миңнуллин, С.Рәхимов төзегән «Ризаэтдин Фәхретдин. Фәнни-биографик җыентык» (1999) дигән хезмәтләрне кертергә кирәк.

Әлеге игелекле гамәл кысаларында олуг галимнең туган авылы Кичучатта музей, Әлмәттә Р.Фәхреддин исемендәге Ислам институты, шунда ук Р.Фәхреддин исемендәге татар гимназиясе ачу һәм аның каршында музей булдыру, Әлмәт төбәгендә Р.Фәхреддин исемендәге региональ премия тәгаен итү кебек күркәм эшләр башкарылды (1994-1998) һәм хәзер дә башкарылып килә.

Шул ук вакытта нигездә 1984 елдан башлап энциклопедик галимнең киңкырлы эшчәнлегенә багышланган фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү гадәткә керде. 1989 елда, Р.Фәхреддиннең 130 еллыгы уңае белән, алар аеруча зур куәт алды. Әлеге җәһәттән Казанда үткәрелгән конференция (1989) сизелерлек эз калдырды. 1999 ел -

бу фасылда бигрәк тә «уңдырышлы» булды. Әлмәт шәһәрендә январь һәм апрель айларында Казаннан да килгән күренекле галимнәр, җитәкче даирәләр, дин эшлеклеләре катнашында ике фәнни-гамәли конференция булып үтте.

Ниһаять, 16 ноябрьдә Казанда Ризаэддин бине Фәхреддингә 140 ел тулуга багышланган һәм республика күләмендә киң яңгыраш тапкан фәнни конференция үткәрелде. Бу соңгы конференция шыгрым тулы залда пленар утырыш һәм төрле биналарда өч зур секция кысаларында эшләде. Пленар утырышта һәм «Р.Фәхреддиннең фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлеге», «Р.Фәхреддиннең дини һәм иҗтимагый эшчәнлеге», «Р.Фәхреддиннең әдәби мирасы» дип аталган секцияләрдә 30 га якын доклад тыңланды. Нотыкчылар арасында академиклар, фән докторларыннан алып аспирантларга кадәр бар иде. Шушы фәнни конференциядә ясалган чыгышлар хәзер сез кулыгызга алган җыентыкның эргәсен тәшкил итә дә инде.

Әйтергә тиешледер ки, Р.Фәхреддиннең 130 еллыгы уңае белән 1989 елда үткәрелгән конференция дә күтәренкелек белән үткән, андагы чыгышлар да бастыру максатында җыентык итеп әзерләнгән иде. Ләкин, бердән, төрле «техник» сәбәпләр, икенчедән, яңа вәзгыять шартларында күпчелек материалларның «мораль яктан» искерүе, ә кайберләренең инде басылып өлгерүе сәбәпле нәшер итү планнары тормышка ашмый калды. Инде бу юлы да форсатны кулдан ычкындыру гафу ителмәслек хата булыр иде.

Җыентыкка кергән материалларны эчтәлеккә җавап бирү нисбәтеннән өч өлешкә бүлү кулай табылды. Бу нигездә пленар утырыш характеры һәм секцияләр эшенең үзенчәлекләре белән бәйле. Шуның белән бергә конференцияне ачуны, аның максатларын билгеләүне күздә тоткан ике чыгыш аерым рәвештә алгы планга чыгарылды. Татарстан Президентының сәяси мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе, Татарстан Фәннәр Академиясенең Тарих институты директоры Р.С.Хәкимов, конференцияне ачып, Р.Фәхреддин эшчәнлегенә кыскача анализ ясады,

«Иҗтимагый фикер хакиме» дигән чыгышында олуг галимнең мирасына фәнни җирлектә үлчәмле бәя бирергә чакырды. Татарстан Фәннәр Академиясе президенты М.Х. Хәсәновның чыгышы «Р.Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы» проблемаларын кочаклады, бөек гуманист зыялының фикер вә идеяләрендә бик куәтле практик хәрәкәт егәре яшеренгәнен шәрехләде.

Җыентыкның **«Тарих»** бүлеге академик М.Г. Госмановның «Ризаэддин Фәхреддинов мирасын өйрәнүдә мөһим бурычлар» мәкаләсе белән ачыла. Һәм мәгънәви җәһәттән шушы бурычларны үтәү сыйфатында тарих фәннәре докторы Р.У.Әмирхановның «Ризаэддин Фахреддин как историк», академик М.З.Зәкиевнең «Р.Фәхреддин һәм халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләләре», тарих фәннәре кандидаты И.К.Заһидуллинның «Ризаэддин Фәхреддин хөкүмәтнең XIX йөзнең икенче яртысындагы милли сәясәте турында», филология фәннәре докторы М.И.Әхмәтҗановның «Ризаэддин бине Фәхреддинең нәсел шәҗәрәсе һәм нәселе хакында», тарих фәннәре докторы Р.Г.Хәйретдиновның «Татар руханилары һәм сәясәт (Р.Фәхреддинов мисалында)», тарих фәннәре кандидаты А.А.Арслангованың «Риза Фәхреддинов иҗатында көнчыгыш чыганаклары («Шура» журналы материаллары буенча)», аспирант А.Х.Төхфәтуллинның «Критика европоцентризма в трудах Р.Фахреддина и Х.-Г.Габяши», филология фәннәре кандидаты А.М.Ахуновның «Риза Фахреддинов и средневековый историк ат-Табари (839-923)», аспирант Л.Ф.Байбулатованың «Изъятые страницы из свода «Асар» Ризаэтдина Фахретдинова» дип исемләнгән күзәтүләре урын алды.

«Мәдәният һәм мәгърифәт» дип аталган икенче бүлекне филология фәннәре докторы Х.Й.Миңнегуловның «Ризаэддин Фәхреддин: әдип һәм әдәбиятчы», филология фәннәре кандидаты М.В.Гайнетдиновның а) «Риза Фәхреддинов - публицист» б) «Риза Фәхреддиннең иҗат пафосы», баш фәнни хезмәткәр Ә.Хәйринең «Ризаэддин бине Фәхреддин әсәрләрендә тәрбия-әхлак мәсьәләләре», педаго-

гика фәннәре кандидаты Ф.Ф.Исламовның «Ризаэддин Фәхреддинов - мәшһүр мәгърифәтче, педагог», филология фәннәре кандидаты И.Б.Бәшированың «Татар әдәби теле һәм Ризаэддин Фәхреддин иҗаты», филология фәннәре кандидаты Ф.К.Бәшировның «Р.Фәхреддин прозасында тәрбия һәм әхлак мәсьәләләре», фәнни хезмәткәр Р.Ф.Мәрдановның «Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура» журналындагы әдәби эшчәнлеге» дигән мәкаләләр тәшкил итә.

Өченче бүлек **«Дин һәм җәмгыять»** шәкелендә калыплашты. Аның асылын шәригать һәм исламият белгече Р.Үтәбай-Кәриминең «Ризаэддин бине Фәхреддин - исламият сакчысы» (тезислар), тарих фәннәре кандидаты Ф.Г.Ислаевның «Русиядә ислам-нәсари мөнәсәбәтләре турында Ризаэддин Фәхреддин», филология фәннәре кандидаты Ф.З.Яхинның «Риза Фәхреддинов ваһһабилар хакында», тарих фәннәре кандидаты А.Ю.Хабетдиновның «Риза Фахреддин и теология эпохи джадидизма», фәнни хезмәткәр А.Г.Хәйретдиновның «Риза Фәхреддин һәм Муса Бигиев», кече фәнни хезмәткәр Н.К.Гариповның «Деятельность Р.Фахреддинова в составе Оренбургского Духовного собрания (1891-1906 гг.)», аспирант Г.Г.Галиәхмәтованың «О влиянии доисламских верований на распространение ислама в Поволжье (по книге Р.Фахреддинова «Болгар вә Казан төрекләре»)», фәнни хезмәткәр Р.Р.Бикмөхәммәтовның «Р.Фахраддин о философских взглядах Ибн Рушда», аспирант Л.И.Төхфәтуллиннаың «Специфика гендерных представлений Ризаэтдина Фахретдинова» кебек чыгышлар билгели.

Шулай итеп, әлеге җыентыкта 28 докладчының 29 чыгышы мәкалә рәвешендә урын алды. Аларда олпат зыялы затның эшчәнлеге һәм иҗаты тарихи, иҗтимагый, фәлсәфи, дини, әдәби, лисани һ.б. яссылыкта тикшерелә, аның төрки-татар, мөселман дөньясындагы җисмани һәм рухани урыны билгеләнә.

Материалларны басмага хәзерләгәндә язмаларның байтагына «каләм тыгарга» туры килүен искәртергә кирәк. Бу беренче нәүбәттә күп кенә мәкаләләрдә еш кабатлан-

ган бер үк типтагы биографик мәгълүматларны, бер үк төрле сюжетларны кыскартуда чагылды. Кайбер субъектив, хискә корылган, шәхси мөнәсәбәтләрне чамадан тыш күперткән моментларга карата да шул ук чара кулланылды. Икенчедән, аерым авторларның «тотрыксыз» язу ысулын фәннирәк калыпка салу ихтыяҗы үзен әледән-әле сиздереп торды. Шуның белән бергә, авторларның асыл концепцияләренә, төп сүз сөрешләренә, нәзари фикерләү һәм гомумиләштерүләренә, йомгак-нәтиҗәләренә бернинди хилафлык кылынмады, кытыршырак тоелган булса да, аерым күзәтүләрне ыспайлау юлына басылмады, техник характердагы төзәтүләр кертелсә дә, галимнең позициясе, мәсләге, беренчел максаты үзенең әйдәүче дәрәҗәсен җуймады. Тикшеренүчеләр кайбер урыннарда «уртак» мисалларга бердәй мөрәҗәгать итсәләр дә, төрле фән һәм төрле мәгънә калыбы белән килгәнлектән, андый фасыллар (әйтик, «Әсма...». «Сәлимә...» романнарына бәйле рәвештә) «имгәтүләрдән» имин калды. Авторның принципиаль позициясен чагылдырган очракларда хәтта исем язылышы ысулларын да үзгәртү, бер стандартка китерү тиеш табылмады, алар галимнәрнең үз хөкеменә, үз җаваплылыгына калдырылды («Ризаэтдин», «Ризаэддин», «Фәхретдин», Фәхреддин», «Фәхретдинов», «Фахраддин» һ.б.).

Энциклопедик гыйлем иясе Р.Фәхреддиннең шәхесен, эшчәнлеген, иҗатын төрле яклап яктырткан, бәяләгән бу җыентык, ихтимал кимчелекләренә карамастан, фәнни даирәләрдә генә түгел, киң җәмәгатьчелектә дә кызыксыну уятыр, иҗтимагый тормышыбызны баетучы һәм рухи яктан зиннәтләүче вакыйга буларак кабул ителер дип өметләнәбез.

19 сентябрь 2000 ел.

Рафаэль Хәкимов

ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР ХАКИМЕ

Мөхтәрәм җәмәгать!
Галимнәр!
Конференция кунаклары!
Ризаэддин бине Фәхреддиннең туганнары!

Без бүген сезнең белән бар аңлы гомерен газиз халкына хезмәт итүгә багышлаган, аның күңеленә зыялылык нуры чәчкән, зиһененә гыйлем, затлылык төшенчәләре сеңдергән бөек акыл иясе, олуг җәмәгать хадиме, олпат дин әһеле, мәгърифәтче, вәгазьче, нәсихәтче, тарихчы, археограф, әдип, педагог, мөхәррир, публицист Ризаэддин бине Фәхреддиннең (икенче исеме белән әйткәндә, Риза казыйның) 140 еллык мөбарәк юбилее уңаеннан җыелдык.

Энциклопедик белем иясе, рухи-иҗтимагый тормышның төрле тармакларында йөзләрчә кыйммәтдар хезмәтләр иҗат иткән шәхес буларак, Риза казый XIX йөз азагы - XX йөз башларында нигездә татар, ә гомумән алганда, илдәге барча мөселман-төрки халыкларының тарихи әдәбияты, иҗтимагый фикер үсеше һәм мәдәниятендә үзәк урыннарның берсен биләп торды. Аның даны Оренбург, Уфа, Казан, Санкт-Петербург, хәтта Русия кысалары белән генә дә чикләнмәде, бәлки чит мәмләкәтләргә, бигрәк тә төрки һәм ислам дөньясына киң таралды.

Күп кенә, аеруча көнчыгыш телләрне ана теледәй белгән Ризаэддин Фәхреддин әтрафлы гыйльми җирлектә эш итте, Петербург университеты профессоры Җамаледдин Әфгани, Русия академиклары А.Н.Самойлович, В.В.Бартольд, И.Ю.Крачковский һәм башка атаклы галимнәр белән иҗади элемтәдә торды, алар белән хезмәттәшлек кылды. Ул Русия һәм мөселман мәмләкәтләреннән тыш, АКШ, Германия, Франция, Испания, Канада, Япония, Кытай, Скандинавия илләре галимнәре белән язышты, уртак фәнни проблемаларны чишүгә нәтиҗәле өлеш кертте.

Фән дөньясында, иҗтимагый фикер даирәсендә ифрат зур шөһрәт казанган Риза казый байтак шәрәфле мәҗлес-симпозиумнарның үзәгендә кайнады. Мәсәлән, 1925 елның сентябрендә, СССР Фәннәр Академиясе Президиумы чакыруы буенча, ул Фәннәр Академиясенең 200 еллык юбилеенда мәшһүр шәркыятче (востоковед) буларак иң хөрмәтле кунак сыйфатында катнашты. Озак еллар дәвамында Дини Нәзарәтендә казый, 1922 елдан гомеренең соңынача мөфтилек вазифасын үтәгән Ризаэддин Фәхреддин 1926 елда Согуд Гарәбстанына, Мәккәи-Мөкәррәмәгә Бөтендөнья мөселманнары конгрессына барды. Анда ул корылтайның вице-президенты итеп сайланды. Бөек галим һәм дин эшлеклесе биредә гарәп телендә чыгыш ясады, аны зур хөрмәт белән Согуд Гарәбстаны короле кабул итте.

Яшьтән үк үзен бинийһая сәләте, рухи пакьлеге һәм иҗади колачы белән таныткан Ризаэддин Фәхреддин өлкән һәм кече замандашларының олуг ихлас ихтирамына юлыкты. Мифтахеддин Акмулла аны «хөрмәтле Ризаэддин - бер камил зат» дип олылады, Зәки Вәлиди аңа «татарларның бөек галиме» дигән бәя бирде, ә барлык күренекле замандашларын очлы сатира каләменә «элгән» әче телле Шәехзадә Бабич Риза казыйга карата чәнчкеле сүзләр әйтмәү генә түгел, киресенчә, аның олуглыгына болай дип мәдхия җырлады:

Риза хәзрәт, сиңа әйтәм, син мөхтәрәм, дип әйтәм,
Бер җирене тешләр идем, ил ышанмас, дип әйтәм!

Фәнни конференция яссылыгында сүз йөртсәк, татар (һәм башка төрки-мөселман халыкларының) иҗтимагый фикере вә мәдәнияте тарихында Ризаэддин Фәхреддин барыннан да элек фәнни белемнәрне, әдәбият, мәдәният тарихын, фәлсәфә һәм тарих, дөньяви фәннәрне, мәгърифәтне халык арасында пропагандалаучы, рационалистик карашларны алга сөрүче шәхес буларак танылды. Шуңа күрә XX йөз башында Ризаэддин бине Фәхреддинне Идел-Урал әтрафында тереклек кылучы халыкларның

иҗтимагый фикер хакименә әверелде, дип әйтәк, бу һич тә арттыру булмастыр. Моңа бөек акыл иясенең тарих, археология, этнография, нумизматика, генеалогия, эпиграфия, фәлсәфә, юриспруденция, педагогика, астрономия, география, әдәбият, тел белеме, сәнгать, медицина, халык авыз иҗаты, әхлак, дин тарихы һәм башка төрле фәннәр белән якыннан кызыксынганлыгы, алар буенча күп санлы оригиналь хезмәтләр иҗат итүе дә ныклы дәлил. Шулар өстенә, Ризаэддин бине Фәхреддин - югары әхлак, әдәп, тыйнаклык, тырышлык, рухи камиллек, иманга тугрылык кебек гүзәл сыйфатларының кабатланмас гәүдәләнеше булды.

Диңгездәй гыйлем иясе, милли тарихыбызның йөзек кашларыннан булган гаҗәеп ШӘХЕСНЕ олылау, биниһая киңкырлы иҗатын кадәри хәл барлау, аңа фәнни җирлектә үлчәмле бәя бирү - бүген безнең алдыбызда торган җаваплы вә саваплы бурычларның берсе. Шушы изге максатны асыл юнәлешебез итеп алсак, мин ышанам ки, бүгенге конференциябез үзенең төп максатына, һичшиксез, ирешәчәк.

Алда әйтелгәннәрнең һәм әле әйтелеп бетмәгәннәрнең барысын да күздә тотып, Ризаэддин бине Фәхреддин бине Сәйфеддиннең 140 еллыгына багышланган фәнни конференцияне ачык дип белдерәм, аның иҗади күтәренкелек атмосферасында нәтиҗәле һәм уңышлы эшләвен телим!

М.Х.Хәсәнов

Р.ФӘХРЕДДИН МИРАСЫ ҺӘМ ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң берничә гасыр буена рухи һәм мәдәни торгынлыкка дучар ителгән татар дөньясында XIX йөзнең икенче яртысыннан бөек реформатор Ш.Мәрҗани эшчәнлеге белән башланып киткән татар яңарышы бик күп мәшһүр каһарманнарны тудырды. Мәдәният күгендә Ш.Мәрҗани сызган юлда И.Гаспринский, К.Насыйри, М.Бигиев, Й.Акчура, Ф.Кәрими исемнәре кабынды. Р.Фәхреддин әнә шул йолдызлыкта янган якты йолдызлардан.

Үзенең остазы Ш.Мәрҗани шикелле, аның таланты да тирән һәм куәтле, эшчәнлеге бай, күпкырлы. Ул галим һәм мәгърифәтче, дин эшлеклесе, педагог, философ һәм тарихчы, журналист, язучы. Татар яңарышының беренче буын вәкилләре кебек үк, ул да энциклопедик галим, XIX гасыр - XX гасырның беренче яртысы мәдәни тарихында тирән эз калдырган тарихи шәхес.

Бүгенге җыелыш Р.Фәхреддиннең тууына 140 ел тулу уңае белән үткәрелгән чараларның иң мөһимнәреннән булса да, бу туры мәгънәсендә юбилей тантанасы түгел, ә фәнни конференция. Шуңа күрә мин аның тормыш этапларына тукталуны кирәк санамыйм, бәлки татар дөньясына нисбәтән Р.Фәхреддин мирасының актуаль моментлары хакында кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим.

Иң беренче мәсьәлә - әлбәттә, Риза Фәхреддинне барлыкка китергән тарихи-мәдәни мохиткә бәйләнешле рәвештә аның шәҗәрәсе, талантының тирән тамырлары хакында.

Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, С.Максуди талантлары турында сүз барганда гадәттә безнең караш Казан артына - Арча, Кырлай якларына юнәлгән була. Бу табигый, чөнки татар теле һәм милләте формалашуда, милли мәдәнияткә талантларны бирүдә бу якның роле гаять зур. Әмма Татарстанның башка төбәкләре дә бу җәһәттән кысыр калмаган, милли мәдәният казанын кайнатуга зур өлеш керткәннәр. Алыйк Кама аръягын.

Р.Фәхреддиннең үзенең мәгълүматларына караганда, аның 6 нчы бабасы Юлдаш бине Ишкәй Идел елгасының Тау ягындагы зур татар авылы Шырданда (Каюм Насыйри туган авылда) туып үскән булган. Ә Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, көчләп чукындырудан куркып, Шырданнан чыгып китәргә мәҗбүр булган. Кама аръягына күчеп килеп, хәзерге Әлмәт районы Кичү елгасы буена урнашкан һәм «Юлдаш» авылын нигезләгән. Мәгълүм булганча, ул авыл хәзер Кичүчат дип атала.

Бу фактка тукталуның сәбәбе шул: аның һәм этник, һәм тарихи, һәм сәяси әһәмияте бар. Ул Р.Фәхреддиннең тумышы, нәсел-нәсәбе ягыннан чын татар булуы турында сөйли. Бу хакта артык сүз куертуның кирәге юктыр. Аның татарлыгы кызы Әсма Шәрәф истәлекләрендә, галимнәрдән М.Госманов, Ә.Хәйруллин, М.Әхмәтҗанов, Д.Гарифуллин һ.б. мәкаләләрендә тирән һәм дәлилле исбатланган.

Р.Фәхреддин хезмәтләрендә татар халкының этногенезы һәм тарихы, мәгарифе һәм мәдәнияте, милли прогресс, дин һәм фән, ислам тәгълиматы, милли азатлык хәрәкәте һәм башка бик күп мәсьәләләр тирән яктыртылган. Аларда шулай ук Европа һәм көнчыгыш халыкларының иҗтимагый-сәяси фикер үсеше, рухи багланышлар, педагогика һәм әхлакый тәрбия проблемалары чагылыш тапкан.

Татар яңарышының күренекле вәкиле буларак, Р.Фәхреддин гомер буена мәгърифәтчелек һәм гуманизм традицияләренә турылыклы булып кала. Ул үзенең таланты, алган тәрбиясе, милли традицияләр белән сугарылганлыгы, дөньяга карашы белән олуг бер гуманист иде. Ул тарихи барыш, җәмгыять үсеше көн тәртибенә китереп куйган мәсьәләләрне революция, корал көче белән, сыйнфый көрәш, кан кою аркылы түгел, эволюцион үсеш белән, реформа аша, мәгърифәт-тәрбия, халыкның мәдәни үсеш дәрәҗәсен күтәрү аркылы хәл итү тарафдары булды.

Татар дөньясы турында сүз барганда мин вакыт ягыннан бер гасыр дәверне - аның XX нче гасырдагы яшәешен, милли халәтен, казаныш-югалтуларын һәм башка

факторларны күздә тотам. Ә Риза Фәхреддин мирасының бу чордагы хәл-үзгәрешләргә, татарның XX нче гасыр вәзгыятенә турыдан-туры катнашы, бәйләнеше бар.

Татар ренессансы классикларының - Й.Акчура, С.Максуди, Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Дәрдмәнд һәм Г.Ибраһимовларның карашынча, бу гасыр татарның тарихи барышында, аның язмышында гаять зур роль уйнарга тиеш иде. Моның өчен объектив шартлар да була. Алардан файдалана алу, әлбәттә, икенче нәрсә.

Татарның тарихында күп нәрсәләр кабатлана дияргә мөмкин. Моның шулай булуын XX нче гасыр башында һәм ахырында Рәсәйдәге һәм татар дөньясындагы иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтәге уртаклыклар раслый. Безгә бүген дә моннан 100 ел элек торган проблемаларны хәл итү хакында баш ватарга туры килә. Р.Фәхреддин мирасын өйрәнүнең зарурлыгы һәм актуальлеге, фәнни-иҗтимагый әһәмияте нәкъ шуның белән аңлатыла да.

XX гасыр башында татар дөньясын борчыган мөһим мәсьәләләрнең берсе - Рәсәйнең, шул исәптән татар халкының да, тарихи үсеш юлын билгеләү иде. Ә монда игътибар үзәгендә тарихи барышта нинди ысулны - революцион сикереш яки эволюцион тәрәккыять юлынмы сайлау мәсьәләсе торды.

Р.Фәхреддин үзенең чыгышы, дөньяга карашы, милли-дини тәрбиясе, ислам тәгълиматына рухи якынлыгы һәм башка сәбәпләр аркасында иҗтимагый барышта сыйнфый көрәш һәм революцион катаклизмнар юлын кискен кире какты, эволюцион үсеш, цивилизация казанышларын ватмау-җимермәү, явызлыкны, кан коюларны булдырмау ягында иде. Ул 1917 ел октябрендә большевикларның властька килүен кабул итмәде, аннан соң Илдә кабынып киткән ватандашлар сугышы янгынын, аларның нәтиҗәсе булган 1921 елгы коточкыч ачлык фаҗигаләрен авыр кичерде. Ә 1922 елда Диния Нәзарәтенә мөфти булып сайлангач, үзенең дини эшчәнлеген һәм фәнни хезмәтләрен тулысынча тынычлык максатларына - туган халкының аң-белем

дәрәҗәсен, әхлакый тәрбиясен күтәрү максатларына хезмәт иттерүгә багышлады.

Әлеге мәсьәләгә бик якын булган, аның белән турыдан-туры бәйләнгән икенчесе - демократия һәм, хәзерге термин белән әйткәндә, «кеше хокуклары» мәсьәләсе.

Р.Фәхреддин үзенең таланты, характеры, дөньяга карашлары, менталитеты белән чын мәгънәсендә зыялы демократ иде. Ул кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә, милләт һәм дәүләтара багланышларда диктатны, көч-корал куллануны кабул итмәде, үзара аңлашу, сәяси мөсахабә, гуманизм һәм демократия, хокукый тигезлек принципларын яклады. Үзенең ислам фәлсәфәсе һәм төрки халыклар тарихына караган хезмәтләрендә дә әнә шуларны алга сөрде.

Бу җәһәттән «Шура» журналының методологиясен, алга куйган максатларын һәм эчтәлеген искә төшереп үтү артык булмас, дип уйлыйм.

Бу журнал 1908 елның гыйнвареннән 1918 елның гыйнварена кадәр, 10 ел буена аның баш мөхәррирлегендә чыгып килә. Журналның исеменнән үк күренгәнчә, аның нигез принципларында, иҗтимагый тормышта, сәясәттә, фәндә һәм мәдәнияттә булсын, киңәшеп эшләү һәм демократия, ислам дине белән фәнне үзара яраклаштыруны максат итеп кую алга сөрелгән була. Моның шулай икәнлеген журналда басылган дистәләрчә, йөзләрчә мәкаләләрдән күрергә мөмкин.

XX нче гасыр башында татар дөньясы алдында торган мөһим проблемаларның тагын берсе - татарның тарихи үсеш кыйбласы мәсьәләсе. Татар матбугаты тарихын тикшерүчеләргә яхшы мәгълүм, гасыр башында вакытлы матбугат битләрендә «Шәрекъме, гаребме?» бәхәсе киң җәелеп китә. Берәүләр: татар шәрекъ баласы, милләтнең тоткан кыйбласы да шәрекъка таба дип, икенчеләр: гаребкә, аның мәдәниятенә борылырга вакыт җитте, дип язып чыгалар. Р.Фәхреддин исә боларның икесенең синтезын алга сөрә. Аның «Шура» журналында басылган мәкаләләре шуны раслый.

Шәрекънең олуг шагыйрь һәм акыл ияләренең, ислам дөньясының мәшһүр философларының гына түгел, көнбатышның галимнәре, мәдәният, сәнгать, дәүләт эшлеклеләренең, Европа ренессансы классикларының исемнәрен, әдәби мирасын журнал битләрендә даими пропагандалау, татар яңарышы процессын шулар белән азыкландыру, Дәрдмәнд образлавы белән әйткәндә, дөнья океаны киңлекләренә юл тоткан татар корабын ике җилкән - шәрекъ һәм гареб кыйблаларына юнәлдерелгән җилкәннәр белән тәэмин итү әнә шул фикерне раслый.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң бу җитди мәсьәлә өстән ихтыяр көче белән җиңел «хәл ителә». Большевиклар хакимиятенә тулысынча буйсындырылган татар халкы бер генә якка - рус ягына гына карарга тиеш дип табыла. Татар менталитетыннан шәрекъ факторы бөтенләй алып ташлана. 1927 елда булып узган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак» исемле дискуссияне, татар халкының бер буын формалашуы дәверендә үз алфавитын ике тапкыр алмаштыруны, дистә- ләрчә еллар буена татар зыялылары баш өстендә «солтангалиевчелек» кылычы асылынып торуын искә төшерегез. Риза Фәхреддин шикелле зыялылар боларның бөтенесен гаять авыр кичерәләр. Ә татар мәдәнияте язмышына бәйләнгән проблема фәнни яктан да, сәяси җәһәттән дә, милли мәктәпләр язмышына нисбәтән дә уңай хәл ителми кала. Табигый, XX нче гасыр ахырында ул яңадан калкып чыкты, көн тәртибенә килеп басты. Татарның тарихи язмышына бәйләнгән бу җитди проблеманы хәл итүдә Р.Фәхреддин мирасы, һичшиксез, таяныч ноктасы була ала.

Р.Фәхреддин әдәби мирасын өйрәнү белән турыдантуры бәйләнгән тагын бер проблема - милли-азатлык мәсьәләсе, аның татар дөньясы өчен зарурлыгы һәм актуальлеге.

Совет чорында Рәсәй империясендә колониаль шартларда яшәгән халыкларның милли азатлыгы бары тик пролетариат революциясе, сыйнфый көрәш, кан кою белән

генә бәйләнешле рәвештә аңлатылып киленде. Ә тарихи чынбарлыкта исә татар дөньясында эш башкарачак тора иде. И.Гаспринский, Г.Баруди, Й.Акчура, С.Максуди, Р.Фәхреддин кебек фикер ияләре, күренекле сәясәтчеләр милли азатлыкны сыйнфый көрәш, сугыш һәм революцияләр, көч куллану аша түгел, цивилизацион юл белән хәл итүне алга сөрделәр. Бу бөек шәхесләр нигезләгән һәм җитәкчелек иткән татар җәдидчелек хәрәкәте әнә шуның конкрет гәүдәләнеше иде. Җәдидчелек хәрәкәте XX нче гасыр барышында революция һәм сыйнфый көрәш юлына альтернатив юл була ала иде. Кызганыч ки, тарих башкача юнәлеш белән китте.

Әмма тарихи барышның беркавым вакыт үткәч, үткән юлында ясалган хаталарга яңадан әйләнеп кайту гадәте дә бар. XX нче гасыр азагында гасыр башында куелган, ләкин хәл ителми калган мәсьәләләрнең тагын калкып чыгуы әнә шул хакта сөйләмиме?

Риза Фәхреддиннең «Шура» журналы чын-чынлап плюрализм, демократик фикер йөртү трибунасы була. Анда милли тел һәм әдәбият, татарның тарихына һәм мәдәниятенә, иҗтимагый тормышына һәм киләчәгенә, милли, дини һәм сәяси менталитетына караган төрле фикерләр, дискуссион карашлар чагылыш таба, һәм боларның барысы да баш мөхәррирнең һәм күпчелек мәкаләләрнең авторының дөньяга карашларын, демократик принципларын чагылдыра. Ул юкка гына бу журналда эшләгән дәверен иң бәхетле чоры дип санамый.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, «Шура» журналында Риза Фәхреддин татар яңарышының әдәбият классиклары булган Дәрдмәнд, Г.Тукай, М.Фәйзи, Г.Ибраһимов, Ш.Камал иҗатын, дөнья әдәбияты титаннарының әсәрләрен пропагандалауга зур өлеш кертте. Аңа кадәр дә, аннан соң да татар дөньясында шәрекъ поэзиясен һәм фикер байлыгын да, гареб классикларының әсәрләрен дә ун ел буена эзлекле рәвештә, тирән һәм мәгънәле итеп, ялкынланып пропагандалаган башка матбугат органы булмады. Р.Фәхреддин

әдәби мирасының бу өлеше дә безнең галимнәребез тарафыннан махсус тикшерелергә, югары бәяләнергә тиеш.

Ниһаять, сөйләнгәннәргә йомгак ясап, шуны әйтәсе килә. Р.Фәхреддин калдырган әдәби мирас гаять бай, катлаулы һәм күпкырлы. Ул XX нче гасыр татар мәдәниятенең һич тутыкмас байлыгын тәшкил итә.

Шуның белән бергә, Р.Фәхреддин планнарының һәм максатларының күбесе тормышка ашырылмавын да билгеләп үтү тиеш. Бу яктан ул, XX нче гасырның башка күп бөек шәхесләре шикелле, фаҗигале язмышлы галим. 1917 ел Октябрь инкыйлабы, канлы ватандашлар сугышы, большевикларның сугышчан атеистик сәясәте, репрессияләр - аның гуманистик карашларына һәм эшчәнлегенә җитди киртә булалар, идеалларын юкка чыгаралар. Ләкин фаҗигале шартларда да ул үзендә ныклы ихтыяр көче таба, иҗат эшен дәвам иттерә. Матбугат иреге булмау, мәчетләрне ябуы, милли мәгарифнең тамырларын өзүе өчен совет властен ачыктан-ачык тәнкыйтьләп чыга, гарәп имлясын алмаштыруга протест белдерә һ.б. Ә мөфти булып эшләү елларында Диния Нәзарәте архивын һәм китапханәсен, рухани уку йортларын саклап калу буенча фидакярләрчә хезмәт күрсәтә. Совет чорында иҗтимагый тормыштан күңеле кайткан Р.Фәхреддин фән белән шөгыльләнүен туктатмый. Әмма аның язган хезмәтләре басылмый, фәнни җәмәгатьчелеккә барып җитми, өстәл тартмаларында кала бирә. Ә бу галим өчен фаҗига түгелмени? Шуның өстенә, үзе власть органнары тарафыннан каты эзәрлекләнә. Шулай да ул, үзенең революциягә кадәрге кайбер хезмәттәшләре һәм фикердәшләре шикелле, туган илен ташлап китми. Һәм аның мондый карары өлкән яшьтә булуы белән генә аңлатылмый, күрәсең.

Риза Фәхреддингә илдә репрессияләрнең югары ноктасы булган фаҗигаләрне кичерергә туры килми, ә исән булса, аны нинди язмыш көтәсен күзаллавы кыен түгел. Галим 1936 елда вафат була.

Фидакяр интеллектуаль хезмәт кешесе, җаны-тәне, үзенең бөтен барлыгы белән явызлыкны кире кагучы бөек гуманист зыялы затның исеме татар һәм башка төрки халыкларының иҗтимагый фикер үсеше, мәдәният тарихына алтын хәрефләр белән язылырга хаклы. Аның әдәби мирасы - татарның дини, фәлсәфи һәм фәнни үсеш тарихының көзгесе буларак, һәрьяклап тирән өйрәнелергә, гадел бәясен алырга тиеш. Элекке СССРның күп кенә мөселман халыклары үз илләрен реформалаштыру процессында аның мирасына, аның идеяләренә дә таяналар. Р.Фәхреддин фикерләре, аның идеяләре XX гасыр азагы - XXI гасыр башы татар дөньясы өчен аеруча актуальләр. Аларда бик куәтле практик хәрәкәт егәре яшеренгән.

I БҮЛЕК. ТАРИХ
ГЛАВА I. ИСТОРИЯ

М.Г.Госманов

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘГЕ КАЙБЕР МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘР

XIX йөз ахыры белән XX гасыр башы татар мәдәни һәм иҗтимагый тормышының кабатланмас күренешләренең берсе булган Ризаэддин Фәхреддин (1859-1936) эшчәнлеге, аның иңләп алгысыз бай иҗади мирасы төрле яклап һәм җентекләп өйрәнүне таләп итә. Әйе, *төрле яклап* һәм *җентекләп*. Чөнки шул чордагы тормышыбыз гаҗәп дәрәҗәдә катлаулы, каршылыклы - һәм өметле якты, һәм трагик нәтиҗәле булган шикелле, Риза казый Фәхреддиннең эшчәнлеге дә искитәрлек дәрәҗәдә күптармаклы, ифрат бай җимешле, бер үк вакытта тирән фаҗигале дә иде.

Ризаэддин Фәхреддиннең эшчәнлеге һәм мирасы ни дәрәҗәдә олы, катлаулы икәнлеген чын-чынлап аңлар өчен бу бөек гуманист, фикер иясе калдырган хезмәтләрнең төп өлеше искерми торган, Галимҗан Ибраһимовның бер гыйбарәсе белән әйткәндә, «беренче кул» чыганакларга нигезләнгән булуын хәтердә тотыйк. Бер үк вакытта аның якты идеалыннан һич тә чигенмәгән мәгърифәтче, тәгълим-тәрбия, үгет-нәсыйхәт көченә ихлас ышанган моралист-педагог булуын искә төшерик. Аның үткен һәм зәвыклы каләмгә ия олуг журналист, мәсләгәндә нык торган мөхәррир-оештыручы, оригиналь әдәби әсәрләр тудырган киң колачлы язучы булганын да онытмыйк. Риза казыйның шулай ук дөньявилык белән охравилыкны, гади итеп әйткәндә, динилекне органик рәвештә бергә кушарга теләгән, үз иманында, үз гамәлләрендә шуңа ирешә язган, гел ирешергә омтылган киң карашлы дин галиме, сүзнең зур мәгънәсендәге чын идеалист икәнлеген дә хәтердән чыгармыйк. Ниһаять, туры сүзле шагыйребез Акмулла

«бер камил зат» дип олылаган Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннең пакь вөҗданлы шәхес, намуслы гражданин, бер үк вакытта гаҗәп тыйнак кеше - эш, иҗат Кешесе һәм шунда ук киң карашлы җәмәгать эшлеклесе булганлыгын да гел истә тотыйк.

XIX йөз ахыры белән XX гасыр башындагы мәдәни, рухи дөньябызны, иҗтимагый тормышыбызны азмы-күпме дәрәҗәдә белгән, белергә теләгән бер кеше дә, әгәр надан яки хөсет булмаса, бу бәяләмәләрнең берсен дә тулаемы белән инкяр итмәстер дип ышанам. Әлбәттә, бу очракта мин тар сәяси мәнфәгатьләрдән чыгып, галим эшчәнлеген каралтырга, аның исемен оныттырырга «тиеш» булган элекке махсус омтылышларны исәпкә алмыйм. Чөнки сәясәт дигән нәрсәнең никадәр актуаль, кирәкле, хәтта котылгысыз зарури нәрсә икәнлеген таныган хәлдә, аның шул ук дәрәҗәдә аумакай, мәкерле, пычраклыкларга да сәләтле күренеш булуы да яхшы мәгълүм. Моның шулай икәнлеген Русиядәге татар чынбарлыгы Р.Фәхреддиннең үз тормышы, мирасының язмышы белән дә әллә ничә кат раслады инде.

Дөрес, соңгы елларда вәзгыять бераз үзгәрә төште: Риза казый Фәхреддин эшчәнлегенә, аның мирасына карата элек бездә хем сөреп килгән агрессив мөнәсәбәтләргә чик куела башлады. Эшчәнлекнең, мирасның әһәмиятен азмы-күпме дәрәҗәдә яктыртырга мөмкинлек булдырыр өчен иң элек алардан гаепләр эзләү, безнең хәзерге карашларга туры килми торган сыйфатларын казып чыгару, тәнкыйтьләү «зарурлыгы» да, шөкер, бетеп бара (элек андый ташламалары булмаган фикерләр матбугатка бөтенләй узмый иде). Шуңа күрә бүген галимнән калган бай мирасны әтрафлырак, тулырак һәм, иң мөһиме, гаделрәк өйрәнүнең *кайбер* актуаль мәсьәләләренә махсус тукталу, беренче һәм икенче нәүбәттә торган юнәлешләрне билгеләү урынлы булыр дип исәплим.

Шуны да ачык итеп әйтү зарур: әгәр без Р.Фәхреддиннең күпкырлы, тирән фикерле хезмәтләренә аларның үзләренә лаеклы бәһа бирергә теләсәк, безгә галимнең үзе кебек үк

зур белемгә, киң карашка ия булырга кирәк. Мәсәлән, «Риза Фәхреддин - тарихчы» дигән бер генә теманы алып карыйк. Аның тарихка, тарих белеменең төрле тармакларына караган күпсанлы китапларында, дистәләгән-дистәләгән мәкаләләрендә бер татар халкының, бер төрки кавемнәрнең генә түгел, бәлки *бөтен шәрекъ дөньясының* (әлбәттә, мөселман дөньясы масштабында) узгандагы катлаулы дөньясы да төрле яклап яктыртылган булуын күрербез. Икенчерәк итеп әйткәндә, ул татар тарихын шәрекъ дөньясының аерылгысыз бер өлеше итеп яктырта. Димәк, галим мирасының бу тармагын өйрәнгән, бәяләгән очракта да безгә бер татар тарихы мәнфәгатьләре, бер Идел-Урал ягы, яисә соңгы чор Русия тарихы кысалары белән генә чикләнмичә, киң масштабта фикер йөртеп, хөкем чыгарырга кирәк булачак. Халыкара мөнәсәбәтләрнең, мәдәни-иҗтимагый бәйләнешларның элекке чорларда башкарак масштабта һәм бүгендән үзгәрәк мәнфәгатьләр белән икенчерәк юнәлештә барганлыгын онытмау шарт. Шулай булгач, үз халкыбызның узганын яхшы күзаллау өстенә, безгә кешелек тарихында тирән эз калдырган Урта гасыр мөселман цивилизациясеннән дә киңрәк хәбәрдар, бигрәк тә язма истәлекләр белән якыннан таныш ориенталистик белемгә дә ия булу зарур икән. Бер үк вакытта галимнең фикерләү үзенчәлекләрен, бәхәс һәм исбатлау алымнарын дөрес аңлар, дәлилле итеп аңлатыр өчен дини тәгълиматлар белән бергә шәригать кануннарыннан, ислам фәлсәфәсеннән, элекке чорларга хас социаль психологиядән дә хәбәрдар булу таләп ителә. Әлбәттә, өстән-өстән генә булса да башкарыла торган формаль күзәтүләр белән чикләнеп калырга теләмәсәк, мәсьәләгә шулай җаваплырак рәвештә якын килү таләп ителәчәк.

Табигый ки, идеаль омтылыш таләп итә торган мондый шартларның һәммәсенә дә җавап бирерлек тарихчы белгечне табу бүген бик үк җиңел эш булмастыр. Шуны да өстәп әйтергә кирәк, Р.Фәхреддиннең тарихчы буларак мирасын өйрәнгәндә туа торган төрле кыенлыклар аның башка юнәлештәге хезмәтләрен тикшергәндә дә килеп

чыгуы бик ихтимал. Әйтик, «Ризаэддин Фәхреддин - ориенталист» яисә «Р.Фәхреддин - журналист, мөхәррир» кебек махсус темаларны ерып чыгар өчен дә шул белгечлекләрнең үз өлкәләрендә киң эрудиция, этрафлы белем кирәк икәнлеге бәхәссез. Әгәр «Р.Фәхреддин - дин галиме», «Җәмәгать эшлеклесе, казый һәм мөфти буларак эшчәнлеге» дигән гаять актуаль проблемаларга тотына калсак, мәсьәлә тагын да катлауланыр иде. Мондый булуы ихтимал, хәтта килеп чыгуы бик реаль кыенлыкларга, котылгысыз хаталарга ишарә итүем һич тә очраклы түгел. Мәсәлән, китап исемендә «эзләр» яисә «истәлекләр» һәм «калдыклар» дигән махсус мәгънәдәге «асар» сүзен («асаре гатика»!) Уфада чыккан хезмәтләрдә примитив рәвештә «әсәрләр» дип тәрҗемәләп, «Шура» журналындагы мәкаләләр ахырына «тәмам» мәгънәсендә куелган «соң» сүзен автор исеме, яки аның псевдонимы рәвешендә аңлаулар һич тә очраклы булмаса кирәк. Шулай ук элекке чорларда яшәгән кешеләрнең психологиясен, менталитетын исәпкә алмыйча торып, аларга безнең бүгенге чор милләтчеләренең карашларын көчләп тагуны да эрудиция галәмәте, дип әйтеп булмый. (Мондый хаталарны, урынсыз тартып-сузуларны, кирәксә, дистәләп-дистәләп китерергә мөмкин).

Кыскасы, Риза казый Фәхреддин эшчәнлегенең кайсы ягына, нинди генә өлешенә кагылсаң да, киң колачлы эрудициягә нигезләнгән, мәгәр үзара мөстәкыйль булган махсус белемнәр - ориенталистик һәм дини-фәлсәфи гыйлемнәр кирәклеген күрәсең. Шул ук вакытта бездә бүген кадрлар әзерләүдәге булган реаль мөмкинлекләрне дә исәпкә алыйк. Әйтик, халкыбызның тирән тамырлы язма традициясеннән, димәк, иске әдәби теленнән, шулай ук рухи мәдәниятебез тукымаларына тирән һәм мул үтеп кергән гарәп-фарсы язма культурасы байлыгыннан ерак шартларда тәрбияләнгән бүгенге көн яшь белгечләрнең реаль мөмкинлекләрен исәпкә алсак, әлеге шик-шөбһәләрнең юкка булмавы аңлашыла төшсә кирәк. Әгәр Мәскәү һәм

Петербургларда ориенталистика буенча махсус белем алган яшьләрнең, кагыйдә буларак, татар әдәби теленнән, аның стильләреннән ерак торуларын игътибарга алсак, мәсьәләнең ул кадәр үк җиңелдән түгеллегенә тагын бер кат ышанырбыз. (Галимнең иҗтимагый һәм әхлак-әдәп өлкәләрендәге карашларын уңышлы гына өйрәнә башлаган мәрхүм Фәнил Баишев кебек, гарәпчәне үзләштерүдән тыш, Риза казый кулланган татар әдәби телен дә яхшы белгән яшьләр соңгы елларда бармак белән генә санарлык...). Шулай булгач, тагын бер сорауның алга килеп басуы бик табигый: безнең бүгенге реаль шартларда югарыда куелган таләпләргә тиз генә җавап бирерлек мөмкинлекләребез бармы соң?

Сорауга һәм «юк», һәм «бар», дип җавап бирергә туры килә. Дөресен ярып әйтсәк, Ризаэддин Фәхреддин дәрәҗәсендә ул кагылган мәсьәләләрнең һәммәсендә дә компетентлы рәвештә күп юнәлешләрдә эшли алырлык кешенең хәзерге яшьләрдән тиз генә табылуы ихтималдан ераграк. Дөньяви галимнәребез арасында да, руханилар даирәсендә дә юк хәзергә андый шәхесләр... Һәм бу аңлаешлы да. Аның тарихи объектив сәбәпләре дә бар. Бер яктан, безнең узган чорыбызда шартлы рәвештә «Ренессанс» дип атала торган дәвернең иң күренекле вәкиле булган Ризаэддин Фәхреддин, замана таләп иткән ихтыяҗларга муафикъ рәвештә, аң-белемнең мөһим бер өлкәсендә чыннан да энциклопедистларга хас рәвештә күп тармаклы белемгә ия иде. (Энциклопедизм күренеше, белгәнебезчә, Ренессанс чоры өчен хас). Икенче яктан, безнең хәзерге югары уку йортларында белем бирүнең, заман таләпләреннән чыгып, бик нык махсуслашкан, шуңа күрә «үз эченә йомылган, тарайган» булуын да исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, булачак тарихчыларыбызның махсус филологик белемнәрдән ерак торуларын (күбрәк социология, сәясәтчелек буенча укуларын), филологларыбызның исә тарихи белемнәрне, бигрәк тә аның методикасын чамалы рәвештә үзләштерүләрен күрсәтү дә җитеп торса кирәк.

Ике белгечлекне дә үзләштерер өчен фидакярләрчә түземлек, фанатикларча үҗәтлек, ниһаять, вакыт һәм мөмкинлек кирәклеген исәпкә алсак, мәсьәләнең бик үк җиңел түгеллеге аңлашылыр, дип уйлыйм.

Ләкин мондый «тоеклыктан» чыгу мөмкинлекләре бөтенләй юк дип әйтергә дә ашыкмыйм. Ягъни авыр мәсьәләне азмы-күпме дәрәҗәдә уңайрак юнәлештә хәл итү мөмкинлекләре дә бар. Болай дип, мин, мәсәлән, аспирантның белемен махсус өлкәдә күтәрү өстенә, аның алдына куела торган гыйльми проблемаларның күләмен, юнәлешен бик нык конкретлаштыру бурычын да атар идем. Әйтик, «Р.Фәхреддин- галим» дигән зур проблеманы да тарихчы күзлегеннән тулаемы белән түгел, бәлки «Р.Фәхреддиннең «Асар»ендә тарихи чыганаклар», «Р.Фәхреддин - текстолог», аннары «Р.Фәхреддин һәм мәгърифәтчелек тарихы», «Р.Фәхреддин һәм җәдидчелек», «Р.Фәхреддин иҗатында тарихи биографияләр», «Р.Фәхреддин хезмәтләрендә шәрекъ халыклары тарихы», «Р.Фәхреддиннең педагогия буенча эшчәнлеге», «Шура» журналында тарих (педагогика, әдәбият яисә мәктәп-мәгариф) мәсьәләләре», «Коръән аятләрен (яки: хәдисләрне) шәрехләү принциплары» һ.б. шулар ише максималь конкретлашкан темаларны эшләтү чагыштырмача җиңелрәк тә, нәтиҗәлерәк тә булыр иде.

Темаларны болай нык тарайтудан, минемчә, куркырга ярамый. Аспирантура аша белгечләр әзерләүдән максат билгеле бер мәсьәләне аннан-моннан гына капшап, өстән-өстән генә узучы саййөзәрләр әзерләү түгел, бәлки теманы җентекләп, һәръяклап өйрәнүгә сәләтле, шуңа өйрәтелгән гыйльми тикшерүчеләр үстерү булса кирәк. Шунысы да бәхәссездер, мондый конкрет темаларны ерып чыгу процессында, минем фикеремчә, яшь галимнең конкрет методика ягыннан чыныгуыннан һәм өстәмә белем дә үзләштерүеннән тыш, өйрәнелә торган катлаулы мирасның бер өлеше төгәлрәк, җентекләбрәк тикшерелер, димәк, гаделрәк бәяләнер иде. Ниһаять, максималь рәвештә конкретлашкан тема өстендә эшләү дәвамында тарихчы бел-

гечлеге алып чыккан студентка филология өлкәсендә белемен арттыруга, филология буенча белем алган кешегә тарих гыйлемен һәм аның методикасын үзләштерү өчен дә мөмкинлекләр артыр иде, дип ышанам.

Конкрет бер шәхеснең иҗатын, эшчәнлеген өйрәнү турында сүз чыкканда мондый гомум методик мәсьәләләргә тукталу һич тә очраклы түгел. Р.Фәхреддиннең мирасын иркенләп тикшерә башлауга иҗтимагый шартлар тууга шактый вакыт узса да, эшләрнең һаман бер урындарак таптануына шул методик принципларның ачыкланмаганлыгы да сәбәп булса кирәк. Милли амбицияләрдән генә чыгып, аннан-моннан чүпләп, сузып-тартып дигәндәй язылган кайбер «гомум» характердагы басмаларны исәпкә алмаганда, Риза Фәхреддин эшчәнлеген төпле итеп яктырткан хезмәтләрнең әлегә кадәр башкарылмавын шул методик ачыкланмауның чагылышы, дип исәпләргә мөмкин. Дөресрәге, конкрет мәсьәләләрнең җентекләп өйрәнелмәгән булуы гомум характердагы хезмәтләрнең дә барлыкка килүенә җирлек тудырмый икән. Һәрхәлдә бу очракта эшләр шулайрак тора. Чөнки, яшерен-батырын түгел дип әйтик, Риза Фәхреддин мирасын тикшерергә атлыгып торырлык әзерлекле яшьләр әлләни күп булмаган шикелле, аларга тәкъдим ителүе мөмкин темалар белән җитәкчеләр дә колач җәеп көтеп тормыйлар.

Шулай да бу юнәлештә соңгы елларда беркадәр боз кузгала башлады, дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, «Шура» журналында әдәбият мәсьәләләре» һәм «Җәвамигыль Кәлим шәрхендә» хәдисләр тәрҗемәләү принциплары» дигән темаларга диссертацияләр башкарылу (Р.Мәрданов һәм Г.Камалетдинова хезмәтләре), эшләренең сыйфатлары төрлечә булуга карамастан, һичшиксез, уңай күренеш, дөресрәге, уңай тенденция.

Тагын бер принципиаль мәсьәләгә тукталып узу зарур, дип уйлыйм. Бездә гадәттә берәр кеше бер темага алынса, башкалары аңа якын килмәскә, яисә «бу юнәлештә мин эшлим, син аңа тотынма» ише икенче берәү-

ләрне читкә тибәрергә тырышу күренешләре очраштыргалый. Киләчәктә мондый хәлнең - мирасның күләмен, иҗатның үзенчәлекләрен яхшы белмәгән очракта - Р.Фәхреддин хезмәтләрен өйрәнү буенча да килеп чыккалавы ихтимал. Чынлыкта исә Риза казый мирасы буенча берике, хәтта биш-алты түгел, бәлки дистәдән артык кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре, махсус монографияләр язар өчен дә материаллар җитәрлек. Бары алдан аңлашып, тема һәм максатны төгәлрәк билгеләү генә таләп ителә. Аннары мин бер үк темага ике-өч кеше тарафыннан эзләнүләр, тикшеренүләр башкарылуда да бернинди гаеп яки «исрафчылык» күрмим. Киресенчә, бер үк мәсьәләне төрле авторлар төрле яклап өйрәнсәләр, хакыйкать тулырак ачылып, гаделрәк хөкемгә тизрәк ирешер өчен җирлек туар иде. Табигый ки, чын объективлыкка омтылып, мәсьәләгә киң күңеллелек белән караганда гына. Бары шулай гына без Ризаэддин Фәхреддин иҗаты кебек бай, күпкырлы һәм катлаулы, каршылыклы мирасны өйрәнүдә идеалга якынрак нәтиҗәләргә тизрәк ирешә алыр идек. Әлбәттә, мәдәни һәм иҗтимагый тарихыбызның башка күренешләре белән фактларын да онытмаган, аларга да тиешле дәрәҗәдә игътибар биргән хәлдә генә мондый теләкләргә ирешергә мөмкин.

Р.У.Амирханов

РИЗАЭДДИН ФАХРЕДДИН КАК ИСТОРИК

На одной из эпитафий татарского кладбища г. Уфы выведены следующие строки: «Ученый-историк муфтий Ризаэддин Фахреддинов, 1859-1936».

Человек широчайшей эрудиции, огромного таланта, энциклопедических знаний, создавший сотни произведений в самых различных сферах духовной жизни, скромно называл себя лишь историком. В этом есть своя символика и закономерность. Да, выдающееся дарование Ризы Фахреддина, разносторонность и масштабность его общественных, научных интересов прежде всего и ярче всего проявились в его исторических исследованиях. А это наследие практически только начало изучаться.

Говоря о вкладе Р.Фахреддина в историческую науку, мы прежде всего имеем в виду его многотомное биобиблиографическое сочинение «Асар» («Следы»), труды по истории Волжско-Камской Булгарии, Золотой Орды, Казанского, Касимовского, Сибирского ханств и др. Думается, что эти труды для татарского (да и для других тюркоязычных) народов имеют такое же значение, как аналогичные произведения Н.М.Карамзина, П.И.Рычкова, В.Н.Татищева, С.М.Соловьева, Н.И.Костомарова, В.О.Ключевского и др. для русского народа. Поэтому было бы вполне логично и справедливо по примеру многотомных сочинений вышеназванных русских историков издать и исторические труды Р.Фахреддина, снабдив их соответствующими научными комментариями.

Труд Р.Фахреддина на поприще исторической науки можно назвать настоящим подвигом. Выходец из татарской глубинки, обучавшийся в самом заурядном сельском медресе,[1] лишенный возможности поступить в солидные по тем временам учебные заведения, благодаря своим выдающимся способностям, огромной работоспособности и прилежанию, он самоучкой стал одним из самых эрудиро-

ванных людей своего времени. Его личностью еще до революции интересовался М.Горький. В 1911 г. в письме к Гаязу Исхаки он подчеркивал необходимость помещения в предполагаемом сборнике «Татарская литература» биографии Р.Фахреддина и сведений о его деятельности.[2]

Не жалея ни времени, не сил, еще будучи юношей, он переписывал книги от руки, собрал богатую для своего времени библиотеку, самостоятельно изучил и превосходно знал, кроме родного татарского, арабский, персидский, турецкий языки.[3] Вспоминая о своих мытарствах в приобретении научных знаний, ученый впоследствии писал: «Положение Курсави, Марджани, Баруди и др., пожелавших стать учеными, было по сравнению с моим куда перспективнее. Потому что они с юных лет учились в знаменитых медресе Бухары, брали уроки у прославленных наставников, пользовались библиотеками; когда они из кладезя науки черпали ковшами, я копал колодец иголкой... Желая оставить ее у себя, я от руки переписывал любую подвернувшуюся научную книгу. Для меня не было ничего ценнее книги».[4]

«Болгары и чуваши»[8] дигән махсус китап чыгарган. Аның төп нәтиҗәсе түбәндә русча килеш китерелгән өзектән бик ачык күренә: «... современные нам чуваши представляют собой из себя не что другое, как прямых потомков волжских булгар, и что черемисы, обозначая их именем ***суас,*** впоследствии перенесли это имя и на татарских завоевателей края, которые, унаследовав то политическое значение, которое сначала принадлежало болгарам, и отчасти и их культуру и, приняв ислам, стали потом приписывать себе болгарское происхождение. Такое перенесение племенного наименования с одной народности на другую было тем более возможно, что слияние полудиких пришельцев с культурными болгарами (мусульманами) совершилось с медленною постепенностью, и прежнее болгарство совершенно незаметно подменилось татарством»[9]. Татарларның марилар тарафыннан ***суас*** дип аталулары, ***суас*** сүзенең, ***су-ас*** өлешләреннән торып, болгарларның бер өлешен атавы, һәм Н.И.Ашмариннан китерелгән бу өзекнең, буталчык булса да, болгар-чуваш концепциясен ныгыта алмавы турында безгә Я.Ф.Кузьмин-Юманади белән бергәләп язарга туры килгән иде[10], шуңа күрә ул фикерләрне биредә кабатлап тормыйбыз.

Татарны Идел-Уралда ярымкыргый килмешәк итеп күрсәтүнең миссионерларга ни өчен кирәк булуын әйткән идек инде. Бу - Идел буе халыкларын, мөселман татарлардан аерып, тизрәк христианлаштыру. Шушы максатны тормышка ашырабыз дип, миссионерлар өстәмә тарихи хаталар да җибәргәннәр, сәяси бозуларга да барганнар.

Миссионерлар чыңгызлыларның басып алган җирләрен максатчан кечерәйтеп күрсәткәннәр: татар-монголлар янәсе бары Идел-Урал һәм славян-рус төбәкләренә генә килгәннәр, шул тирәләргә генә күчеп утырып үскәннәр.

Чыгышымның башында ук әйтелгәнчә, Чыңгыз хан яулары иң элек Кытайны, аның тирә-ягын басып алганнар, аннан Үзәк һәм Урта Азия, Әфганстан җирләрен кулга төшергәннәр. Иран-Гыйрак илләрен буйсындырганнар. Бол-

гарның ул чорда иң көчле дәүләт төзи алуы, җиңелмәслек дип танылган чыңгызлыларны 1223 елда тар-мар итүе нәтиҗәсендә, Идел-Урал, славян-рус җирләре татар-монголларга бары 1237-1240 елларда гына буйсынган. Башта Чыңгыз хан кырган, соңрак чыңгызлылар явында, кытай, уйгур, фарсы, гарәп, төрки җирләренә сибелгән татарларның Идел-Урал регионына гына күпләп килеп утыруы, шулардан «ярымкыргый килмешәк» татар формалашуы чынбарлыкка гына түгел, әкияти күзаллауларга да туры килми.

Миссионерларның болгар варислары бары чуваш кына, татар - ул ярымкыргый басып алучы дип раслауларының нигезендә тагын бер мәкерле сәбәп ята. Бу түбәндәгедән гыйбарәт.

Рус дәүләте татар дәүләте дип саналган Алтын Урданың бик күп өлешен үз кулына төшергән, ләкин аның империалистик омтылышларын тагын да киңәйтү өчен, рус үсешенә каршы куела торган төп дошман кирәк булган. Һичшиксез юк ителергә тиешле мондый дошман буларак, рус идеологиясендә татар-монголлар алынган, боларның дәвамы итеп, болгар дип аталган җирле төркиләрдән формалашкан Казан татарлары күрсәтелгән. Менә шуның өчен миссионерлар ***татар*** исемен аның җисеменнән аерырга кирәк тапмаганнар. Идел-Урал татары, этник чыгышының татар булмавына карамастан, татар-монголның турыдан-туры дәвамы дип танылган, татар-монгол басып алулары өчен, хәзергә болгар-татар тулысынча җавап бирергә тиеш дигән караш үткәрелгән. Менә шундый көрәш барышында, миссионерлар, Казан татарын Монголстаннан килеп Җүчи олысын төзегән татарның турыдан-туры варисы дип танып, беренче «татардан татар» юнәлешен тудырганнар.

4. Р.Фәхреддиннең этногенетик карашлары. Миссионерларның болгар-татарны ярымкыргый килмешәк итеп күрсәтүгә юнәлтелгән бу төр карашларын татар зыялылары тәнкыйтьсез калдырмаганнар. Бу көрәшкә беренче чиратта Ш.Мәрҗани карашларын дәвам итүчеләрдән булган Ризаэддин Фәхреддин белән Гайнеддин Әхмәров[11] бик

актив кушылып киткәннәр. Аларның тәнкыйте миссионерларның исемнәрен әйтмичә генә алып барылган, Н.И.Ильминскийны, патша цензоры Н.И.Ашмаринны турыдан-туры тәнкыйтьләүнең ахыры ни белән бетәчәген алар күз алдына яхшы китергәннәр.

Ризаэддин Фәхреддин (Гайнеддин Әхмәров та) Идел-Урал татары формалашуны Ш.Мәрҗанигә ияреп алып барганнар. Мәгълүм булганча, Шиһабетдин Мәрҗани, көнбатыш һәм көнчыгыш чыганакларын анализлап, Идел-Урал татарларының ***болгар*** дигән гомуми исем йөрткән җирле төрки кабиләләрдән үсеп килүен исбат иткән, аларның татар-монгол булмауларын дәлилләгән, ләкин халык, элек ***болгар*** булса да, хәзер ***татар*** исемен кабул иткән инде, аны ташламауны хуп күргән, ***болгар*** исемен кире кайтаруны хупламаган. Халкыбызны хәзер башкалар ***татар*** дип атый, аны саклау хәерлерәк булыр дигән Ш.Мәрҗани. Бу караш Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан да кабул ителгән, һәм ул нәкъ менә шушы юнәлештә тарихи тикшеренүләрне тагын да көчәйткән. Миссионерлар карашының дөрес түгеллеген, аның халкыбыз тарихы һәм бүгенге тыныч, имин тормышы өчен зарарлы булуын фаш иткән.

Р.Фәхреддин татарның килеп чыгышын тикшерүне һуннар, болгарлар, Җучи олысы (Алтын Урда), Казан ханлыгы һәм Рус дәүләте эчендәге чорларга бүлеп үткәргән. Бу чорлардагы дәүләтләрне болгар-татар милләте формалашу чылбырының аерым буыннары итеп караган.

«Болгар вә Казан төрекләре» дигән хезмәтендә шушы фикерен тагын да конкретлаштырып, менә ничек язган ул: «Болгар һәм Казан төрекләренең дөньяда гомер сөрүләре түбәндәге дәверләргә бүленәдер: 1) мөстәкыйль хәлләрендә гомер сөрүләре; 2) татарларга тоткын булып, аларның хакимлекләре астында калулары; 3) руслар тарафыннан басып алынып, рус җәбере һәм золымы астында яшәүләре; 4) миссионерларның хакимлекләренә дучар булулары һәм һәртөрле чирканыч чаралар белән чукындырылулары; 5) коммунистлар кул астында юкка чыгулары»[12]. 5 нче

дәвергә Әнвәр Хәйри «бирелә Р.Фәхреддинов шәхес культы елларын күздә тота», - дигән аңлатма биргән.

Р.Фәхреддин дә, үзенең укытучысы Ш.Мәрҗани кебек үк, халык тарихын көнчыгыш һәм көнбатыш чыганакларын җентекләп анализлап, аңа болгар-татар тарихи материалларын да өстәп тикшергән. Үзенең тарихи ачышларын төрле чорларда, төрле чаралар аша халыкка җиткереп барган.

Аның әүвәлге тарихи күзәтүләре 1900 елда «Асар» әсәренең беренче китабында ук бирелгән. Монда ул Болгарга килгән гарәп сәяхәтчеләре Ибне-Фазлан, Әбүл Хәмид әл-Гарнатилар турында, Болгар иле, болгар галимнәре, ханнары турында төп мәгълүматларны биргән.

Татарның килеп чыгышына карата тәртипле итеп язылган һәм этногенез буенча үзенең төп фикерен игълан иткән беренче мәкаләсен Р.Фәхреддин Кырымда Исмаил Гаспралы нәшер иткән «Тәрҗеман» газетасында бастырган. 1906 елның 16, 18, 20 гыйнвар саннарында чыккан бу мәкалә «Безләр татармы - түгелме»? дип атала.

Татар этнонимын ул татар-монголлар белән килгән сүз дип аңлата. ***Татар*** кабиләләренең баштагы теле монголча булырга тиеш дигән фикер үткәрә. (Хәзер инде ачыкланды: монгол яуларында катнашкан татарлар - төрки кавеменә караганнар). Аңынча, менә шул татарлар, монгол яулары белән килеп, электән ***хазар***, соңрак ***болгар*** дип аталган кабиләләрне буйсындырганнар, ә үзләре, аз булганлыктан, болгарлардан төркичә өйрәнгәннәр, төркиләшкәннәр. Дәште Кыпчакта татар-монголлар төзегән дәүләтнең ***татар дәүләте*** дип аталуыннан чыгып, руслар һәм башка халыклар Идел, Урал буйларында, Кавказда, Кырымда яшәгән җирле төркиләргә ***татар*** исемен биргәннәр, ди ул. Аның фикеренчә, гарәпләрдә дә төркиләргә карата ***тәтәр*** атамасы бик иртә кулланыла башлаган. Шул рәвешчә, чит кабиләләрдән кергән ***татар*** дигән тышкы атама хазар-болгарларның үз атамаларына әйләнеп киткән.

Шушы ук мәкаләсенең ахырында Ризаэддин Фәхреддин хазар-болгар да үзенең этник тамырлары белән төркиләргә барып тоташа, дигән фикер үткәрә, һәм «Безләр татар түгел, чын түркләребез» дигән нәтиҗәгә килә, ләкин ул ***татар*** исеменнән баш тартырга кирәк дигән фикерне әйтми, аны кулланырга мәҗбүрбез дигән нәтиҗәгә килә.

Р.Фәхреддиннең бу мәкаләсенә «Тәрҗеман» газетасы да аңлатмасын бирергә кирәк тапкан. Ул аңлатма, килгән татарлар булса да, алар аз калганнар һәм җирле халык эчендә тиз эрегәннәр дигән фикергә кайтып кала. Редакция фикеренчә, Чыңгыз хан яулары белән Идел-Уралга уйгур төркиләре дә килделәр; менә шул язулы халык һәм культуралы җирле хазар-болгарлар арасында Монголиягә кайтып китмәгән татар сугышчылары бик тиз эределәр, төркиләштеләр, хазар-болгарча сөйләшә башладылар.

Болгар дәверенә кадәрге чорны Р.Фәхреддин «Тарихыбызга гаид» (Тарихыбызга карата) дигән хезмәтендә яктыртырга тырыша. Болгарны ул һуннарга бәйли, Һун империясен тасвирлый, аның Җаек, Дон буйларыннан алып, Адриатик диңгезгәчә җирләрне эченә алганлыгын аңлата. Монда скифләрнең күбесе төрки булып, менә шул төрки-искитләрнең (скифләрнең) һуннар белән тыгыз мөнәсәбәттә торуларын тасвирлый[13].

Скиф-сарматлардан соң дөньяга танылган һәм көнбатыш галимнәре тарафыннан иран телле дип саналган аланнарны да Р.Фәхреддин төрки телле булган дип аңлата. «Һун исемле һун (сөн) төрекләре хазар, фин, болгар, угыр (бөек Һунгария), абар (ауар), алан вә гайре исемнәр илә шөһрәт булдылар»[14], - дип яза ул. Димәк, скиф-аланнар арасында төрки кабиләләрнең төп урын тотулары турындагы фикер төрки-татар тарихчылары арасында күптән билгеле мәгълүмат булып саналган.

Р.Фәхреддин ***болгар*** атамасының киң мәгънәдә кулланылуын аерым басым ясап аңлата. Болгар халкы ***болгар*** дип аталган бер кечкенә кабиләдән тормый, бу төрки халык, башкорт, мишәр, чуваш һәм фин халыкларының

Болгар дәүләтендә бергә берләшкән берлекләреннән тора дип саный.

Конкрет болай яза ул: «***Болгар*** - күмәк мәгънәдә булган финнар белән һуннарның бергә кушылып, аралашып беткәннән соңгы исемнәредер. Мәгәр безнең шушы өлкәбездәге төркиләрнең ***болгар*** исемен алулары белән үз араларындагы төрек, чуваш, ар, чирмеш, башкорт, мишәр, типтәр кебек аерым исемнәре һаман да дәвам итеп киләдер»[15]. Шул ук әсәрендә Р.Фәхреддин болгарның формалашу юлын тагын болай аңлата: «***Болгар*** дигән кавем нинди халык буладыр?» дип сорауга каршы һиҗри белән 433 елда Багдад шәһәрендә булган болгар хаҗиларының берсе: «Төрек белән сәкълаблар катнашыннан һәм аралашуыннан хасил булган кавем», - дип җавап бирде. Шушы ук фикергә Р.Фәхреддин тагын шундый өстәмә төгәллек кертә: «Әлеге сүзнең мәгънәсе: шәрекъ тарафыннан килүче төрекләр (һуннар) белән җирле төрекләр катнашкан кавемнәр болгар дип аталдылар», - диюдер». «Чөнки сәкълаб чынбарлыкта үзе дә төрек иде»[16].

Шуннан соң ук Р.Фәхреддин болгар кабер ташларындагы чуваш сүзләре болгарның гадәти төркилеген инкяр итә алмый дигән фикерне әйтә. Бу - миссионерларга карата тәнкыйть тә булып тора. Башка бик күп төрле дәлилләр болгарның чуваш телле булуын исбатламый, киресенчә, аның гадәти төрки телдә сөйләвен күрсәтә. Шуңа күрә кабер ташларындагы чуваш сүзләрен һәм җөмләләрен генә күреп, болгарны чуваш телендә сөйләшкән дип әйтеп булмый, ди автор. Кабер ташларындагы чуваш сүзләренең күпләп очравын ул бу ташларны мөселман динендәге чувашларның үз җирле телендә язуы белән аңлата[17]. Бу карашка без үзебезнең шундый фикеребезне өстәгән идек: бу ташлар мөселман чувашларның әкренләп гадәти болгар телен кабул итүләре чорында язылганнар. Аларда чуваш теле болгар теле белән алмашынгач, кабер ташлары бары гадәти төрки телдә (болгар телендә) генә языла башлаганнар.

Хәзер инде Р.Фәхреддиннең ***татар*** этнонимы һәм семантикасы турындагы карашларына күчик. ***Татар*** этнонимының башлангыч мәгънәсен ул үзенчә аңлата: «Татар сүзе Чыңгыз гаскәрендә алда йөрүче бер төркем монгол гаскәренә махсус исем булып, нәсел-нәсәп исеме түгел, ул русларның «казачий»лары урынында, Чыңгызның «Татар» исемле гаскәри бүлегедер. ***Татар*** белән ***монгол*** арасында гомуми үзенчәлек шиксез булып, ***татар*** җәмгыятьнең югары катлавы булып, монгол гади, кара халык мәгънәсендә йөри»[18].

Татарларның Чыңгыз хан гаскәрендәге урыннары турында хәзер инде башкачарак караш формалашкан, шулай да Р.Фәхреддин фикере дә игътибарга лаек. Ул ***татар*** этнонимы семантикасын танып белүдә башлангыч этапның берсен тәшкил итә.

Р.Фәхреддин фикеренчә, электән ***болгар*** дигән гомуми этнонимны йөрткән җирле төркиләрне ***татар*** дип атау руслардан һәм башка күрше халыклардан кергән. Болгарны ***татар*** дип атый башлау гайре табигый булса да, без инде аны кулланырга мәҗбүрбез, ди ул. Бу турыда аның үз сүзләрен тыңлыйк: «... Нух пәйгамбәрнең иярченнәре заманнарыннан бирле (монда) яшәгән кавемне ***татар*** дип йөртү фарсыларны - рус, гарәпләрне - итальян, чирмешләрне - көтүче һәм чувашларны - йон тетүче дип йөртү кебек бер эштер. Монголстанда, ихтимал, ***татар*** исемендә берәр нәсел һәм кабилә дә бардыр. Ләкин Монголстан кайда да, Болгар кайда?.. Һәрхәлдә, без инде ялгыш булса да ***татар*** сүзен кулланырга мәҗбүрбез»[19].

Шулай итеп, Ризаэддин Фәхреддин карашынча, Идел-Урал, Көбатыш Себер регионына татар-монгол яулары белән Монголиядән татар дип аталган халык килеп утырмаган, аннан сугышчы буларак килеп, бу регионда теге яки бу сәбәп белән калганнары да тиз арада җирле төркиләр арасында эрегәннәр (өстәп әйтик: Кытайда - кытайлашканнар, фарсы җирләрендә - фарсылашканнар,

башка төркиләр яшәгән җирләрдә төркиләшкәннәр); яулап алган киң ***регионнарга*** татар исеме килгән, башта ул яулап алучылар исеме буларак, соңрак дәүләт исеме буларак кулланылган; шуннан чыгып Көнбатыш халыклары, рус, гарәп халыклары татар дәүләтләре эчендә калган җирле халыкларны да ***татар*** дип атый башлаганнар; алардан бу исемне Көнбатыш Себердәге, Урал-Иделдәге, Кырымдагы җирле төркиләр кабул итәргә һәм кулланырга мәҗбүр булганнар (өстәп әйтик: кытайлар да, фарсылар да, гарәпләр дә чыңгызлыларның башка татар империяләрендә яшәгән төркиләр дә, гарәпләр дә татар исемен кабул итмәгәннәр).

Җирле төрки кавемнәрдән тора торган халкыбыз, Р.Фәхреддин уенча, төрки-искит (скиф), җирле төрки-алан, җирле фин кабиләләренең көнчыгыштан килгән һуннар белән кушылуыннан барлыкка килгән; ул халык Хазар дәүләте эчендә яшәгәндә - гомуми ***хазар*** исеме, Болгар дәүләте эчендә яшәгәндә - гомуми ***болгар*** исеме белән аталган; басып алучы татарлар (чыңгызлылар) «татар» дип аталган дәүләт төзегәч, алар әкренләп татар исемен алырга мәҗбүр булганнар. Шулай итеп, бездә «болгардан татар» юнәлеше барлыкка килгән. Бу юнәлеш тарафдарлары, башка татарлардан аерым атарга кирәк булганда, халкыбызны ***татар*** дип кенә түгел, ***болгар-татар*** дип атыйлар.

5. Ш.Мәрҗани+Р.Фәхреддиннең - «болгардан татар», ә миссионерларның «татардан татар» юнәлешләренең дәвамы ни хәлдә? Бу карашлар бер-берсе белән һәрчак көрәшеп килделәр, һәм ул көрәш бүген дә бик кискен дәвам итә, көрәш барышында һәр караш үстерелә, тирәнәйтелә.

Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхреддиннең төрки-болгар-татар концепциясен алардан соң гыйлем мәйданына килгән барлык төп тарихчылар: Г.Әхмәров, Г.Гобәйдуллин, Һ.Атласи, М.Худяков, С.Максуди, Г.Исхаки, Н.Воробьев, Х.Гыймади, А.Таймас, А.Халиков, Н.Дәүләт, Т.Дәүләтшин, С.Алишев һ.б. яклыйлар һәм яңадан-яңа тарихи дәлилләр белән үстерәләр.

80 нче еллар ахырында Тел, әдәбият һәм тарих институтында тарихны комплекслы тикшерү (барлык төр дәлилләрне дә исәпкә алу) юлы белән халкыбызның килеп чыгышында Болгар һәм аннан да борынгырак чорларның әһәмияте аерым алып өйрәнелде. Көнбатыш Себердә, Казакъстанда, Урта Азиядә, Урал-Идел буйларында, Кавказ, Кара Диңгез тирәләрендә б.э. кадәр 1 нче меңьеллыкта яшәгән скифләрне (скитләрне) бары иран телендә генә сөйләшкән дип язуларга чик куелды. Скифне иран телле дип исбатлауда кулланылган барлык тарихи дәлилләр яңадан җентекләп тикшерелде, һәм шул ук дәлилләр нигезендә скифнең нигездә төрки телле булуы ачылды. Б.э.к. III йөзләрдә шул ук регионнарда яшәгән сармат, соңрак яшәгән алан материалларын өйрәнү дә боларның нигездә төрки булуларын ачты. Шулай итеп, безнең җирле төрки бабаларыбыз бу җирләрдә бик борынгыдан яшәгән икән дигән нәтиҗәгә киленде[20]. Бу халкыбызның җирле тамырларын бик борынгыга китә дип раслау иде.

Ә Идел-Урал татарларының татар-монголлар белән килгән халык булмавын антропологик, краниологик эзләнүләр ачык күрсәтте. Шулай итеп, татарның төп тарихчылары болгар-татар концепциясенең дөреслеген төрле чорларда төрле дәлилләр белән ныгытып килделәр.

Аерым тарихчылар тарафыннан тудырылган, миссионерлар тарафыннан ныгытылган һәм үстерелгән татар-татар концепциясе дә тарих сәхнәсеннән төшмәде. Идел-Урал татары монгол-татардан гына килә дигән бу юнәлешне бик күп көнбатыш һәм рус тарихчылары дәвам иттеләр. Татар тарихчыларыннан аны дәвам итүчеләр булмады.

Ләкин 80 нче елларда, үзгәртеп коруларга бәйле рәвештә, татар галимнәренең үз араларында да болгар-татар концепциясенә каршы, миссионерлар юнәлешен күтәреп чыгучылар күренә башлады. Алар советлар чорында яшәгән һәрбер карашны коммунистлар тудырган дип уйлый башладылар, һәм аларда коммунистик карашларның һәммәсен дә юкка чыгарырга кирәк дигән тенденция барлыкка килде.

Татар халкы тарихы өлкәсендә эзләнергә әзерләнгән аерым белгечләр халкыбызның килеп чыгышын көнчыгыштан татар-монгол яулары белән янәсе әзер килеш килгән татар халкы итәрәк аңлата башладылар. Алар уенча, менә шул әзер килеш килеп утырган килмешәк татарны янәсе «ниндидер бер кечкенә генә», «мәхлүк кенә» болгардан үсеп килгән дип әйтүне коммунистлар уйлап чыгарганнар имеш, бу теорияне татар-монгол яулары белән килгән көчле татарга янәсе Сталин һәм коммунистлар таккан. Юкса, Ш.Мәрҗанине дә, Ризаэддин Фәхреддинне дә бер дә коммунист дип әйтеп булмый кебек.

Элекке миссионерлардан килә торган бу карашны яңа караш, яңа концепция дип йөртүчеләр дә табылды. Алар фикеренчә, татар-монгол көчле булган, хәтта русларны да буйсындырган, халкыбызның килеп чыгышын шул көчлеләр белән бәйләү хәерлерәк, отышлырак, шуңа күрә монгол басып алулары халкыбыз өчен уңай күренеш булды, Алтын Урда гына халкыбызны татар итеп формалаштыра алды, диделәр алар.

Ризаэддин Фәхреддин татар-монгол агрессиясен болгар-татар халкы үсешендәге трагедия дип билгеләде, ***болгар*** дип аталган җирле халкыбызның көчсезләнүе, соңыннан әкренләп сүнүгә баруы чыңгызлылар агрессиясеннән башланды дигән карашны алга сөрде. «Һәрхәлдә, монголлар (татарлар) тарафыннан хөкүмәтләре җимерелгәннән һәм җәмгыятьләре таратылганнан соң, болгар төрекләре зәгыйфьләнделәр, түбән хәлгә төштеләр, моңлы маҗараларга һәм зур фаҗигаләргә очрадылар, ахырда руслар хөкемендә калдылар»[21], - дип язды галим.

Татар исемен аның җисеменнән аермау, электән кем тарафыннан булса да «татар» дип аталган һәр халыкны Идел-Урал татарларының бабасы дип уйлау гадәте барлыкка килде. Мәсәлән, XVI йөздә Көнбатыш Европада чыккан хатирәләрдә һәм латинча язылган кайбер хезмәтләрдә чыңгызлыларның Җучи, Чагатай, Хубилай, Хулагу империяләрен (аерым очракларда бу империяләргә карамаган

җирләрне дә) ***татар*** (аларча, ***тартар*** ˊтәмугъ кешеләре́) җирләре дип, ягъни Тартария дип атадылар. Боларның барысын да хәзерге татарларның бабалары җире дип горурланучылар, «менә бит татарның нинди зур дәүләтләре булган», дип шаккатыручылар күренгәләп алды.

Элекке миссионерлар Идел татары татар-монголларның Алтын Урдада гына утырып калуыннан үсеп киткән дип аңлаталар иде, безнең үзебезнең татар-татар концепциясен алга сөрүчеләр миссионерлар карашын тагын да үстерделәр.

Безнең халкыбызның этногенезы мәсьәләләрендә төрки-болгар-татар концепциясен инкяр итәргә, татар-татар концепциясен генә алга сөрергә тырышучылар, минемчә, халыкның килеп чыгышы буенча гына түгел, аның формалашуы хакында да хаталы фикердә торалар. Алар татар-монголлар Болгарны басып алып дөрес эшләделәр димәкчеләр. Янәсе бу басып алу булмаса, Алтын Урда төзелмәс иде, Алтын Урда булмаса, татар формалашмас иде. Чынлыкта татар-монгол килмәсә, болгар халкы, һичшиксез, формалашыр иде, ул бары ***татар*** исемен генә алмаган булыр иде.

Ләкин болгарга ***татар*** исемен бирүдә хәлиткеч рольне Алтын Урда гына уйнамаган, чыңгызлыларның Көнбатыш Европада һәм русларда ***татар*** дип аталулары моңа сәбәп булган. Алтын Урдага нинди халыклар кергән булса, Урда таркалгач та шул ук халыклар бүленеп чыккан. Бары сартлар - үзбәк, кыпчакларның бер төркеме - нугай исемен алганнар. Болгарлар исә бары XIX йөздә генә татар этнонимын үзатама итә башлаганнар.

Риза Фәхреддин һәм төп тарихчыларыбыз фикеренчә, халкыбызны формалаштыруда төп рольне Болгар дәүләте уйнаган. Болгарлар - татар-монгол агрессиясенә дучар булып, Алтын Урда эчендә калсалар да, алар Алтын Урданың үсешендә әйдәп баручы булганнар, Алтын Урда Болгар традицияләренә, тәҗрибәләренә таянып яшәгән һәм үскән. Болгар бик нык көчсезләнсә дә, аның элекке

халкы үз йөзен югалтмаган. Шуңа күрә Алтын Урда таркалгач та, аның барлык халкы да бер халык булып оешмыйча, элек ничек булса, шулай сакланып калган. Электән Болгар дәүләте эчендә яшәгәннәре, үз традицияләрен онытмыйча, бер халык булып оешуга ирешкәннәр, һәм нәкъ менә шулары XIX йөздә ***татар*** исемен алырга, аны кулланырга мәҗбүр булганнар, соңрак моңа шактый күнегеп тә киткәннәр.

Татарны татар-монголлар белән әзер халык буларак килгән дип уйлаучыларга русның һәм Көнбатыш халыкларының татар-монголны мыскыл итеп сүгүе бер дә ошамый, чөнки моны алар хәзерге татарга да нисбәт итәләр. Шуңа күрә алар русларны үгетләү эшенә керештеләр: татар-монгол агрессиясе янәсе ул тискәре күренеш түгел, ул болгарга да, руска да файдалы булган, аны мактарга, ул төзегән Алтын Урданы уңай яктан гына күрсәтергә кирәк, имеш.

Ләкин Көнбатыш тарихчылары да, рус тарихчылары да, болгар-татар концепциясен танымаган кебек үк, болгар-татарны татар-монголдан килә дип раслаган кебек үк, татар-монгол агрессиясе ул прогрессив күренеш, ул болгарны һәм русны үстергән дигән карашны да танымыйлар; Казан татарлары татар-монголлардан килгән, татар-монголлар руска шул дәрәҗәдә явызлык эшләгән, безнең бу явызлыкны аларның варисларына, ягъни хәзерге татарга кайтарырга омтылуыбыз - табигый күренеш, ләкин аны кайтарып бетергәнебез юк әле диләр аларның кайберләре. Бу - буш сүз булмасын өчен, бер мисал китерик.

1999 елда «Международные отношения» дигән нәшрият Казанга, тираж билгеләү өчен, В.В.Похлебкинның «Татары и Русь. 360 лет отношений» исемле китабының «Содержание», «Предисловие» һәм «Эпилог» дигән бүлекләрен җибәрде. Аның «Эпилог»ыннан күренә: автор хәзерге татарны турыдан-туры татар-монгол яулары белән тиңли һәм шул нигездә татар-рус мөнәсәбәтләренең перспективасы турында фикер йөртә.

«Спустя 150 лет непрерывного и нарастающего владычества над Русью татары-победители неожиданно сами стали жертвой еще более сильного агрессора, чем они - подверглись завоевательным нашествиям Тамерлана. Золотая Орда ослабела, стала приходить в упадок.

Этим немедленно воспользовались русские, хорошо усвоившие за 150 лет один несложный внешнеполитический урок: побеждает в международных столкновениях всегда сила, а не справедливость. Победителей не судят, им не предъявляют претензий, даже когда они творят жестокости, их не упрекают ни в каких грехах. Их слушаются и с ними - соглашаются. Слабых же, отсталых и зависимых - бьют. Поэтому, раз бывший победитель ослабел и уж не может отстоять свое привилегированное положение, - надо бить и добивать его. И чем быстрее, чем безжалостнее, - тем лучше. Отсюда и была принята, как основная военно-политическая тактика, - настойчивая нарастающая агрессивность в отношении с ослабевшими татарскими государствами. Уроки татарского ига не были забыты русскими: их применили в тех же масштабах, в тех же варварских формах» (С.166-167).

Хәзерге татарны этник яктан татар-монголдан килә, аның болгар белән бәйләнеше юк дигән караштан чыгып язылган мондый хезмәтләр, бердән, татарны ***татар*** исеменнән баш тартырга алып баралар: нагайбәкләр «татар» дип язылудан котылдылар инде, мишәрләр, керәшеннәр хәзер татар булмау белән горурлана башладылар. Икенчедән, шуны да яшерергә ярамый: миссионерларның һәм аларны тергезүчеләрнең карашлары татар халкын төзәлмәслек фаҗигаләргә китерергә мөмкин! Шуңа күрә безнең халыкның этногенезы сәясәткә буялмыйча, объектив рәвештә тикшерелсен иде. Безгә болгар-татарның җирле төркиләрдән болгар булып оешуын, болгарның, нигездә шул килеш калса да, соңрак ***татар*** исемен кабул итәргә мәҗбүр булуын онытмаска кирәк.

Ризаэддин Фәхреддиннең этногенетик карашлары турында сөйләгәндә, аны юкка чыгарып, болгар ул чувашча сөйләшә торган халык булган, татар ул әзер килеш татар-монголлар белән килгән, бары Алтын Урда чорында гына үсә алган дигән ялгыш һәм туры булмаган сәясәткә буялган карашның бүгенге көндә күзгә күренеп торган тагын бер ялгышын һәм тарихыбызны бозуга китерүен әйтмичә булмый.

1999 ел - Казаныбыз салына башлауга 1000 ел тулуны исбатлау елы булды. Әгәр без миссионерчыларга ияреп, татар халкы бирегә XIII йөздә генә татар-монгол яулары белән әзер килеш килгән, алар килгәнче, биредә болгарлар чуваш булганнар дигән концепция белән килешсәк, Казанның бер мең еллыгын үткәрүне дә чувашларга тапшырырга тиеш булабыз түгелме соң?!

Күренә ки, халкыбызның килеп чыгышы (этногенезы) мәсьәләсе гаҗәп катлаулы икән, бу мәсьәләдә төп тарихчылар билгеле бер караш урнаштырган булсалар да, аның бозылу куркынычы да бар икән. Шуңа күрә бүген татар халкының килеп чыгышы турында Ризаэддин Фәхреддин карашларын өйрәнү, ул карашларны халкыбызга җиткерү милләтебезне тергезү, саклау һәм үстерү эшендә гаҗәеп дәрәҗәдә актуаль булып кала.

ИСКӘРМӘЛӘР

* Харитә - карта. - Ред.

1. Хөсәйенов Гайса. Ризаитдин бин Фәхретдин /Тарихи-биографик китап. - Өфө, «Китап», 1997.

2. Хөсәйенов Гайса. Күрсәтелгән хезмәт. - 144 б.

3. Шунда ук. - 156 б.

4. Вакыт. - 1907. - 1 сентябрь.

5. Хөсәйенов Гайса. Күрсәтелгән хезмәт. - 155 б.

6. Известия Императорского археологического общества. Т.5. - СПб., 1865. - С.80-84.

7. Труды 4-го археологического съезда в России. Т.1. - Казань, 1884.

8. Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Т.XVIII. Вып.1, 2, 3. - Казань, 1902. - С.1-132.

9. Там же. - С.49-50.

10. Закиев М.З., Кузьмин-Юманиди Я.Ф. Волжские булгары и их потомки. - Казань, 1993. - С.79-93.

11. Г.Әхмәровның болгар-татар концепциясен миссионерлардан саклап язылган хезмәтләре проф. Риф Хәйретдинов тарафыннан җентекләп өйрәнелде һәм 1998 елда «Гайнетдин Ахмеров. Избранные труды» исеме белән бастырып чыгарылды. Г.Әхмәров монда беренче мәртәбә Болгар иленең Биарм иле традицияләрен дәвам итүе турында да мәгълүмат бирә (38 б.).
12. Ризаэддин Фәхреддинев. Болгар вә Казан төрекләре. - Казан, 1993. - 22 б.
13. Хөсәйенов Гайса. Күрсәтелгән хезмәт. - 145 б.
14. Шура. - 1909. - № 17. - 524 б.
15. Болгар вә Казан төрекләре. -24 б.
16. Шунда ук. - 27 б.
17. Шунда ук. - 28 б.
18. Шунда ук. - 49 б.
19. Шунда ук.
20. Закиев М. Проблемы этногенеза татарского народа //Материалы по истории татарского народа. - Казань, 1995. - С.3-94; Мухамадиев А. Туранская письменность //Проблемы лингвоэтноистории татарского народа. - Казань, 1995. - С.36-83.
21. Болгар вә Казан төрекләре. - 50 б.

И.К.Заһидуллин

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН ХӨКҮМӘТНЕҢ XIX ЙӨЗНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДАГЫ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕ ТУРЫНДА

Патша хөкүмәтенең мөселманнарга карата алып барган сәясәте милләтләр, җәмгыятьләр яшәешенә дә, аерым шәхесләр язмышына да кагыла, аларның тормышын көтелмәгән юнәлешкә борып җибәрерлек көчкә ия була. Моны без Ризаэддин Фәхреддин - 1859 елны Самара губернасы Бөгелмә өязе Кичүчат авылында дөньяга килгән күренекле милләттәшебезнең дини һәм дөньяви эшчәнлеге мисалында күрә алабыз.

1869-89 елларда Түбән Шәлчәле мәдрәсәсендә белем эстәгәннән соң, Р.Фәхреддин Илбәк авылына имам итеп сайлана. Сәясәт өлкәсендәге үзгәрешләр аның хезмәт юлын кинәт кенә яңа бер юлга борып җибәрә. Һәм бу, барыннан да элек, Диния Нәзарәтендә казыйлыкка сайлау тәртибенең яңарыш кичерүенә барып тоташа.

Мәгълүм булганча, Диния Нәзарәте казыйлары (алар өчәү) һәм казыйлыкка кандидатлар фәкать Казан губернасы мөселман дин әһелләре арасыннан һәм шулар тарафыннан сайлап куелырга тиешлек турындагы кагыйдә XIX йөзнең соңгы ун еллыгына кадәр көчендә кала. Самара губернасының кечкенә бер авылында имам вазифаларын башкаручы Р.Фәхреддиннең, әлбәттә инде, казыйлыкка сайлау һәм сайлану хокукы булмый. Ләкин тормыш һәр нәрсәгә, шул исәптән законнар һәм кагыйдәләргә дә үз тамгасын сала, аларны үзенчә камилләштерә.

Патша хөкүмәте 1888 ел 16 июль карары белән мөселман дин әһелләрен сайлау тәртибенә үзгәреш кертә: 1891 елдан урын дәгъвалаучыларның урыс телен белүе мәҗбүри саналачагын хәбәр итә. Әйтик, казыйлыкка сайланачак кешеләр гимназиянең беренче дүрт сыйныфы, Татар укытучылар мәктәбе, өяз һәм шәһәр яки ике сыйныфлы башлангыч мәктәп программасы күләмендә урысча һәм арифметиканы белергә; ахун яки хатыйп

урынын дәгъвалаучылар - бер сыйныфлы башлангыч мәктәп программасы чикләрендә белемнәрен күрсәтергә, ә авыл мәхәлләсе муллалары урысча сөйләшә һәм укый белүләрен раслап имтихан бирергә тиеш булалар[1].

Карар мөселманнар һәм дин әһелләре арасында зур ризасызлык тудыра. Урыннарга билгеләгәндә дини гыйлемлелекне түгел, урысча белүне генә исәпкә ала башларлар дигән курку була ул. Һәм Рәсәйнең төрле төбәкләреннән Диния Нәзарәтенә 1000 нән артык хат-гариза килә, мөселманнар әлеге карарны юкка чыгаруны үтенеп мөфтинең хөкүмәткә мөрәҗәгать итүен сорыйлар.

Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов Санкт-Петербургта вакытта Диния Нәзарәтендә утырыш уздырыла һәм 1888 ел 16 июль указын юкка чыгару яки кичектерү кирәклеге хакында карар кабул ителеп, эчке эшләр министрлыгына юллана.

Хөкүмәт кушканнарга буйсынып һәм шуны үтәп торырга тиешле казыйларның мондый «башбаштаклыгы» түрәләрнең ачуын чыгара: «гаепле»ләргә кисәтү ясала. Ә 1890 елның 9 январенда «О порядке замещения должности оренбургского муфтия и членов Оренбургского магометанского духовного собрания» дигән карар игълан ителә. Анда мөфтинең эчке эшләр министры тәкъдиме белән патша тарафыннан расланып билгеләнәчәге язылган була. Казыйларны исә мөфти үзе сайлап алып, эчке эшләр министрына расларга тәкъдим итү тәртибе кертелә. Шул рәвешле, Казан губернасында татарларның казыйлар һәм казыйлыкка кандидатлар сайлау хокукы юкка чыгарыла һәм яңалык казыйларның мөфти тарафыннан билгеләнүенә тиң була. Ел саен бер казый хезмәттән азат ителеп, аның урынына яңа кеше куелырга тиеш дип шәрехләнә[2].

Мөфти башта казыйлар А.Хисмәтуллин һәм З.Мәксүтовтан котыла. Ә 1890 елда Сембер губернасы Сингәләй өязе Тимошкино авылы мулласы Борһанетдин Насретдиновны Диния Нәзарәте әгъзасы ясый. (Бу кандидатурага кагылышлы, Б.Насретдинов хатыны белән мөфтинең киленә якын туганнар икән дигән хәбәр йөри)[3].

Икенче әгъза итеп Самара губернасы Бөгелмә өязе Илбәк авылыннан имам Р.Фәхреддин чакырыла. Кызы Әсма Шәрәф истәлекләренә караганда, имамның Казанда басылган биш китабы белән таныш мөфти М.Солтанов: «Бу яшь кешедә өмет зур, үзен табып чакырыгыз», - дигән фәрман бирә[4].

1890 ел 11 октябрь карары казый булачак кешеләрдән урысча укый-яза белүе хакында шәһәр училищесының педагогик советы тарафыннан бирелгән шәһадәтнамә таләп итә[5]. Ләкин Р.Фәхреддин бу сынауны узып тормый. Чөнки 1891 елның гыйнварына әле өяз шәһәрләрендәге училищеларда урысча имтихан алу оештырылмаган була. Шуңа күрә мәсьәләдә мөфти М.Солтановның протекциясе хәлиткеч роль уйный. Бәлки мөфти үзе дә 1890 елның көзендә Хәлил казый чакыруы буенча Уфага килгән Р.Фәхреддин белән очрашкан-сөйләшкәндә аның ни дәрәҗәдә урысча белүен искәрткән булгандыр. Ничек кенә булмасын, чит диннәрнең дини-рухани эшләре департаментына Самар губернаторының Илбәк имамының урысча укый-яза белүе, тәртипле һәм сәяси яктан ышанычлылыгы хакында 1891 елның 26 гыйнварында язылган хаты килгәндә[6] инде Р.Фәхреддин министрның 12 гыйнвар карары белән казый итеп билгеләнгән була[7].

Р.Фәхреддиннең гыйлемлелеген, кәгазьләр белән эшләүгә һәвәслеген, хәзерлеген исәпкә алып, мөфти М.Солтанов аңа Диния Нәзарәте архивын тәртипкә салу эшен йөкли. Мондый вазифа казый вәкаләтенә карамаса да, Р.Фәхреддин риза була. Сәбәбе:иске документлар белән танышу, борынгы кешеләр тормышы хакында мәгълүматка ия булган кәгазьләрне (тарихи чыганакларны) киләчәк буыннар өчен саклап язып кую теләге[8]. Күрәбез, йөз елдан артык кеше кулы кагылмаган документларны укып, аралап, билгеле бер системага салу эшенә Р.Фәхреддин тарихчы һәм архивист буларак та керешә. Әлбәттә, мондый катлаулы, күп көч һәм вакыт сорый торган хезмәтне казый үзе генә башкармаган. Галим язуынча, аның белән махсус белемле бер-ике дистә белгеч эшләгән. Ләкин

«көймәнең койрыгын йөртү вазифасы күп вакыт минем өстемдә булды» дигән сүзләре[9] аның үз эшчәнлегенә бик төгәл бәя булып яңгырый.

Р.Фәхреддин архив документлары белән таныша һәм аларны барлый башлагач, эшне өч юнәлештә җәелдерә. Беренчесе - архивта булган һәр эшнең өстенә эчендә нинди мөһим кәгазьләр булуын карандаш белән теркәп бара. Максаты - архив документлары турында бер дәфтәр булдырып, шуларны тәртипләп яздыру була[10]. Ягъни киләчәктә Диния Нәзарәте архивы тасвирламасын һәм һәр архив эшенең тасвирламасын төзү өчен җирлек әзерли. Икенче юнәлеш - Эчке эшләр министрлыгыннан килгән кәгазьләрне җыеп, төп эшләргә нөсхәләр яздыру һәм шуларны бергә туплап, Диния Нәзарәте компетенциясендәге мәсьәләләрне карау һәм гадел хәл итүне тизләтү һәм җиңеләйтү өчен кулланма төсендә файдалану[11]. Мәсәлән, 1836-1902 еллар арасында Диния Нәзарәте раслаган урысча-татарча циркулярлар һәм башка карарларны туплап, Р.Фәхреддин 1902[12] һәм 1903[13] елларда мәхәллә дин әһелләренә кулланма итеп бастырып чыгара.

1906 елда казыйлыктан китү Р.Фәхреддингә архивны тәртипкә салып бетерергә мөмкинлек бирми. Ләкин башлаган эшен галим яңа яссылыкта дәвам итә. Күчермәләрен алып барган архив кәгазьләренә нигезләнеп, 1907 һәм 1908 елларда ике кисәктән торган китап яза. «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» дип исемләнгән китапның беренче кисәгендә 1827-1899 елларга караган рәсми кәгазьләр урын алган (1905 елгы бер документны искә алмаганда)[14]. Икенче кисәгендә исә автор үзенең «Вакыт» гәзитендә басылган «Мәктәп вә шәкертләребез» мәкаләсен, татар мәгарифе хокукларына багышланган 1906 ел 31 март «Кагыйдәләрен» һәм шуңа бәйле милли матбугатта дөнья күргән материалларны китергән[15].

Р.Фәхреддиннең татар халык тарихын ике этапка бүлүе игътибарны җәлеп итә. Беренчесе - Рәсәй кул астына эләккәнче үз дәүләтләре белән көн күргән чор, икенчесе

(«яңа тарихлары») - аннан соң булган вакытлар[16]. Галим Рәсәй кулына төшүне татарның мәдәни үсешен туктатучы фактор дип саный. Бер гасыр узгач, кайбер татарлар Дагыстанга барып укып, туган якларына кайта, андагы «дини ысулны» аз-азлап тарата башлаганнар, ягъни мәдәни тормыш иске традицияләр юкка чыгарылган бер бушлыкта яңадан башланган, дип белдерә. Ләкин Бохарада белем алган дин әһелләре схоластика тарафдарлары була[17]. Шул рәвешле, туфракка кысыр орлыклар да чәчелә. Нәтиҗәдә татар халкы «бер гасырга якын схоластика белән гомер кичергән». Схоластика нинди кавем эченә керсә, шул кавемне бөтен тамыры белән корыта дигән фикерен раслау өчен, ул мисалга Рим империясе тарихын китерә[18].

Екатерина II идарә иткән вакытта вәзгыять бераз уңайлана, ләкин хөкүмәтнең мөселманнарга карашы үзгәрүне Р.Фәхреддин хаклы рәвештә «Волга һәм Урал исламнарына мәрхәмәтле булудан артык, шәрекъ исламнарын коралсыз буйсындыру теләгенә нигезләнгән сәяси эш өчен» кирәк булуда күрә. «Бу вакыт коралның куәте бетеп, хәтта Оренбург вә Урал ягында булган исламнарның Русиядән аерылулары, күз белән каш арасы кебек, аз калган иде», - дип ассызыклый[19].

Р.Фәхреддин фикеренчә, Рәсәйнең үз мәнфәгатьләрен күздә тотып милли изүне йомшатуы шунда ук үзен сиздерә: милли уку йортлары ачылып, шәкертләргә белем бирү эше җайга салына. Тарихчы 1860 елларга кадәр хакимиятнең мәктәп – мәдрәсә эшчәнлегенә кысылмавын уңай күренеш буларак бәяләп үтә[20].

XIX йөзнең икенче яртысында алып барылган сәясәткә Р.Фәхреддин «миссионерлык дәвере» дигән тамга сала. Миссионерлыкны да автор тулысы белән сәяси фактор итеп аңлата: «Миссионерларның күзләре иң элек ислам мәдрәсәләренә төшә, йөзләр вә меңнәр белән рус авылларында бер шкула вә бер язу белүче булмаган хәлдә, миссионерларның мәрхәмәтләре ташып чыкканына, мәҗбүри буларак исламнарга русча өйрәтү фикеренә керешкәннәр,

бу яктан, ислам мәдрәсәләренә русча укыту мәсьәләсе мәйданга чыккан»[21]. Төп максаты белән үк татарларга каршы булган бу хәрәкәтнең аерым этапларын, барышын хөкүмәтнең «яшерен» язулы документлары, милли мәгарифкә каршы юнәлтелгән фәрманнары ярдәмендә яктырта, шушы кәгазьләрне хәзерләү «пәрдәсен» күтәрә. «Исламнар хакындагы хөкүмәт тәдбирләре» китабының беренче кисәгендә ул Дәүләт Советы, Халык мәгарифе һәм Эчке эшләр министрлыгы, Диния Нәзарәте, губернаторлар, земство оешмалары язган тәкъдимнәрне укучыга ирештерә. Шулай итеп, Р.Фәхреддин үз фикерен рәсми документлар ярдәмендә дәлилли, хөкүмәт сәясәтен ачып сала торган кәгазьләрне максатчан сайлап, дөньяга чыгара. Аларны шәрехләү, аңлау ягыннан, «әмер вә фәрманнарда булган серләрне вә фәлсәфәләрне укучылар, әгәр дә көчләреннән килсә, үзләреннән-үзләре нәтиҗә чыгарырлар, көчләре җитмәсә, туганнарыннан сорарлар» дип саный[22].

Китапның беренче кисәгендә 30-35 документ файдаланылган. Рәсми кәгазьләрнең өчтән икесе 1865-1885 елларга - Сәлимгәрәй Тәфкилев мөфти булып торган чорга туры килсә, өчтән бере генә 1886-1899 елларга карый. Күрәсең, үзен казый итеп эшкә чакырган һәм китап басылып чыкканда да мөфти булып торучы М.Солтановка мөселманнарның тискәре карашын көчәйтергә теләмәгәндер. «Сүз башы»нда авторның: «Бу мәкаләне укып чыккан адәмнәрнең барысы ислам мәктәп вә мәдрәсәләре хакында, ислам халкы юаш вә илтифатсыз торуы белән хөкүмәт файдаланып, һәртөрле фәрманнар чыгарып торды вә ислам халкы сүз башлап, хәрәкәт итә башлау белән хөкүмәт юашланып, иләктән чыгарып торган фәрманнарны кайвакыт кире алып, кайвакыт туктатып торулары белән хөкем итәчәкләр. Чынлыкта бу хөкем дөрес хөкемдер», - дип белдерүе дә шуңа ишарәли сыман[23]. Ләкин XX гасыр ахырында бу юлларны укучыда китаптан андый ачык фикер калмый. Хикмәт монда, күрәсең, хезмәтнең XX йөз башы укучысына атап язылган булуындадыр.

Үз заманында мөфти М.Солтановның хакимияткә бил бөгеп торуы халыкта ризасызлык уята. Патшаның 1888 ел 16 июль указы, мәктәп-мәдрәсәләрдә кулъязма һәм чит илләрдә басылган китапларны файдаланмау һәм чит илләрдә белем алган дин әһелләрен татар мәктәпләрендә укытудан читләштерү хакында Халык мәгарифе министрлыгының 1892 ел 10 июль циркулярына каршы мөселманнар Уфа, Оренбург якларында да киң җәелгән милли хәрәкәт белән җавап бирә. Әлеге законнар халык арасында болай да дин кануннарын белмәгән мөфтинең абруен тәмам төшерә.

Р.Фәхреддин хезмәте үзенең төзелеше белән үк хөкүмәтнең милли сәясәтне уйлап һәм эзлекле алып барганлыгын күрсәтүгә юнәлтелгән. Мәсәлән, мөселманнарны рус теле аркылы урыслаштыру сәясәте рәсми рәвештә 1870 елда кабул ителсә дә, автор сүзне Оренбург генерал-губернаторының 1827 ел, 12 ноябрьдә язган хатыннан өзек китереп башлый. Анда: «Русча белмәгән кешеләргә мәсҗед һәм мәхәллә хезмәтләренә идәр өчен указ бирелмәс!» - дип язылган була[24]. Дәвам итеп, Р.Фәхреддин Казан уку-укыту округы попечителе тарафыннан 1866 елда әйтелгән, җирле халыкларны урыслар белән якынлаштыру өчен урысча укытырга кирәк дигән фикерен искә ала[25].

Автор, шулай ук, татарлар арасында русча өйрәнүгә караш мәсьәләсенә дә игътибар итә. 1868 елны Вятка губернасының земство управасы әгъзасы (гласный) Мирсәед Юнысовның (ул Малмыжда мировой посредник – җәмәгать арадашчысы булып эшли, Сарапул шәһәрендә вафат була)[26] татарларга русча укытыла торган класслар ачу тәкъдиме белән чыкканлыгын, земство собраниесенең аны куәтләп, мөселманнар өчен махсус укыту урыннары кирәк дип билгеләвен мисалга китереп, Р.Фәхреддин татарлар арасында урысчаны ирекле рәвештә өйрәнүгә теләк булганлыкны да ассызыклый[27].

Халык мәгарифе министры советы 1870 елның 2 февралендә кабул иткән «Кагыйдәләр»не Р.Фәхреддин үз китабына тулы килеш урнаштыра. Чөнки хөкүмәтнең сәяси

эшчәнлеге алга таба нәкъ менә шушы программаны тормышка ашыруга багышлана. Әлеге документта мөселманнар өчен казна хисабына рус башлангыч һәм шәһәр мәктәпләре төзү, гимназиягә керү өчен хәзерлек сыйныфлары оештыру һәм җиңел имтихан үткәреп алу, 16 яше тулмаган шәкертларне мәктәп һәм мәдрәсә хозурында булачак рус классларында укыту, ул классларны тоту чыгымнарын мәхәлләләргә йөкләү, аларның укытучыларын татарлардан яисә төркичә белгән рус кешеләреннән билгеләү, үз хисапларына рус классы ачарга риза булмаган очракта, мөселманнарга яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирмәү, яңа уку йортлары өчен педагогларны Симферополь һәм Уфа шәһәрендә Татар укытучылар мәктәпләре ачып, шуларда әзерләү хакында әйтелә. Дин әһелләре итеп земство, шәһәр, авыл җәмәгать оешмаларына сайланучы мөселманнардан урысча укый-яза һәм санау гамәлләрен белү турында шәһадәтнамә таләп итү тәртибе дә шушы «Кагыйдәләр»дә каралган була. Ә инде яңалыкларны гамәлгә ашыру вакытын билгеләү Халык мәгарифе министрлыгы һәм Эчке эшләр министрлыгы кулына тапшырыла.

Ләкин «Кагыйдәләр»нең эчтәлеге мәгълүм булуга ук, муллалар бу эшкә каршы чыга башлый. Эчке эшләр министры мөфтигә муллалар белән аңлашырга боера. Нәтиҗәдә 1873 елның февралендә[28] шушы хактагы фәтва игълан ителә. Р.Фәхреддин аны да китабына керткән. Әлеге юлламада дин әһелләренә урыс телен белү кирәклеге болайрак дәлилләнә: «Әгәр дә ватаныбыз булган бөек империянең телен белмәсәгез, падишаһның кануннарын нихәл белерсез? Чиновниклар илә ничек сөйләшерсез? ...Русча укытып, сезне чукындырырга тырышалар диючеләр дә бар имеш. ...Сез русча белергә тиешсез. Русча беләсе килмәгән кеше падишаһның сөймәгәне булыр. Һәр нәрсәнең гыйлеме файдалыдыр. Сезнең бәгъзеләрегез исә дин гыйлеме соңында иң кирәкле булган гыйлем русча икәнне хәтта аңларга да теләми. ...Ошбуның өчен мин сезгә боерам: русча укыр өчен халыкны өндәгез!»[29].

Әлбәттә, мөфти өндәве генә мәсьәләне уңай якка хәл итә алмый. Ризасызлык көчәя генә. Муллаларның күбесе халыкның мәхәллә хисабына көчләп урыс класслары, урыс-татар мәктәпләре ачуга каршы килүен фәкыйрьлектән күрә. Башкача аңлатулар да очрый. Мәсәлән, Вятка губернасы Малмыж өязе муллалары русча укытуны кирәксез, файдасыз, хәтта зыянлы саный[30].

Хөкүмәт фәрманын үтәргә тиешле кешеләр дә «төрле» позицияләргә баса. 1873 елда Вятка губернаторы Эчке эшләр министрлыгына мулла булачак кешеләрнең русча укытуга мөнәсәбәтләрен ачыклап, тикшереп кенә билгеләү уңай булыр, дигән тәкъдим кертә. Ә менә Казан уку-укыту округы попечителе П.Д.Шестаков үтә кискен кылана: булачак муллалардан русча белүләре хакында шәһадәтнамә генә түгел, мәдрәсәдә урысча укытачагына ышаныч язуы (подписка) да таләп итәргә кирәк дип белдерә[31]. Округның татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләре инспекторы В.Радлов та аннан калышмый. 1874 елның 1 июлендә Вятка губернаторына җибәргән хатында падишаһ фәрманына каршы чыккан муллаларны эшеннән алып, чит төбәккә сөрү тиеш дип яза[32]. Күрәсең, губернаторны үз фикеренә ышандыруга да ирешә: бер ел элек керткән тәкъдимен көчәйтеп, Вятка губернаторы мөфтидән муллаларга карата чара күрүне сорый[33].

Мөфти С.Тәфкилев, Малмыж өязе муллаларын урысча укырга өндәп, 1874 елның октябрендә фәтва җибәрә. Анда каршы килгән дин әһелләренең җаваплылыкка тартыласын да искәртеп китә[34].

Вятка губернаторына җибәргән хатында (1874 ел 18 октябрь № 3177) С.Тәфкилев земство эшчәнлеген тәнкыйть итә: школалар ачып, учительләр таратканга кадәр кешеләр аркылы мөселманнарга русча укуның файдасы хакында фикер таратырга кирәк иде. Яңа уку йортларын уйлап, байлыклары булган җирләрдә генә ачарга тиешләр иде, дип күрсәтә. Ахырдан мөфти: «Ихтимал ки, килер бер вакыт, халык үзе сорап укый башлар, ләкин ул вакыт

килеп җитмәгән әле, аңа кадәр исә русча уку кирәклеген белдереп торырга кирәк. Мин үзем, русча уку файдасын белдерү өчен, кулымнан килгән кадәр бу юлда тырыштым, моннан соң да тырышам, ләкин мин бер генә урында торуым сәбәпле, бөек даирәнең (округның) һәр җиренә җитешә алмыйм. Шуңа күрә минем өндәү һәм нәсихәтләрем белән бергә земство чиновникларының нәсихәтләре җирле халык өчен бик файдалы булыр»[35], - дип яза. Мондый тәнкыйтькә хәтере калган Вятка губернаторы Эчке эшләр министры А.Е.Тимашевка шикаять юллый.

1874 елда мөселман мәктәпләре Халык мәгарифе министрлыгына буйсындырыла[36]. Бу адым хөкүмәтнең урыслаштыру сәясәтенә каршы торучы муллаларны, Халык мәгарифе министрлыгына караган мәктәп-мәдрәсәләрнең мөдирләре һәм мәгаллимнәре буларак, җинаять җаваплылыгына тарту өчен дә эшләнә[37]. Бу бәйләнеш хакында Р.Фәхреддин, күрәсең, Диния Нәзарәте архивында чыганак тапмау сәбәпле, бер мисал да китерми.

Тарихчы хөкүмәтнең мәктәп-мәдрәсәләргә һәм дин әһелләренә кагылышлы тормышка ашмый калган бер проектына туктала. 1876 елда Халык мәгарифе министрлыгы, Эчке эшләр министрлыгы белән килештереп, түбәндәге закон проектын Дәүләт Советында раслауга куя: 1) билгеле бер вакыт җиткәч, земство , шәһәр һәм авыл оешмаларына эшкә керүче мөселманнардан башлангыч мәктәп программасы күләмендә русча белүләре хакында шәһадәтнамә таләп ителсен; 2) 1880 елдан башлап мулла, мөдәррис һәм мөгаллим, Диния Нәзарәтендә казый булачак кешеләрдән рус классы программасы күләмендә русча белүләре хакында училище педагогик советлары шәһадәтнамәсен сорау тәртибен кертергә. Аңарчы - 1878 елның 1 сентябреннән - мулла, мөдәррис урыннарын дәгъвалаучылардан русча укый һәм яза белүне таләп итәргә; 3) мәхәллә халкына яңа мәктәп-мәдрәсә һәм рус классы өчен кирәк булган чыгымнарны үз өстенә алу мәслихәт булыр. Шуның өчен акча яки милекләрне вакыф итәргә

рөхсәт бирергә[38]. Ләкин Дәүләт Советы мондый кырыс чаралар куллануны тиеш тапмый.

Патшаның 1882 ел 5 февраль указы белән Диния Нәзарәте буйсынуында булган мөселманнар яшәгән төбәкләрдәге мәктәп-мәдрәсәләр өстеннән күзәтчелек итү Халык мәгарифе министрлыгына тапшырыла. Эчке эшләр министрлыгы мөфти С.Тәфкилевкә шул хакта мөрәҗәгать белән чыгарга боера. Мөфти исә: «буйлә эшләр сәбәбеннән мөселманнарның миңа ышанулары бетте, әгәр дә шулай була торып, бу вакыйгада мөдахәләм улса, мөселманнар арасында куркыныч чуалулар булачактыр!»[39] - дип җавап бирә.

Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев эшчәнлегенә йомгак ясагандай, Р.Фәхреддин 1870-1885 елларда Рәсәй төбәкләрендә: Казан, Уфа, Самар, Пенза губерналарында җирле хакимият белән мөселманнар мөнәсәбәтен тасвирлап уза. Бөтен төбәкләрдә дә муллалар рус мәктәпләре ачуга пассив каршылык күрсәтәләр, мәгариф инспекторларын да, губернаторларны да тыңларга ашыкмыйлар[40]. Җирле хакимият үзе үк бу хәлдән чыгу юлын эзли башлый. Мәсәлән, Пенза губернаторы Татищевның патшага җибәргән 1883 елгы губерна хисабында: мөселманнарны русча укытыр өчен җиңел юл бар - мулла булачак кеше өчен русча белүне шарт итү, әгәр дә муллалар русча белсәләр, диндәшләре дә үз балаларын алардан русча укыттырырлар иде, дигән фикер әйтелә[41].

Самара губернаторы Санкт-Петербургка: «муллалар полиция хозурында түгел, бәлки җәмгыяте тәгълимия хозурында һәм мәгълүм бер программа буенча имтихан шарт булсын» - дип язып җибәрә[42]. Алда искә алган 1888 ел 16 июль указы шушы теләк-тәгъдимнәргә закон көчен бирүче документ була да инде. 1886 елда мөфти итеп Мөхәммәдьяр Солтанов билгеләнгәч, бу юнәлештә хөкүмәт эшчәнлегенең яңа этабы башлана.

Халык мәгарифе министрлыгының 1892 ел 10 июль циркуляры мәктәп-мәдрәсәләрдә кулъязма һәм чит илләрдә басылган китапларны кулланмау, фәкать Рәсәй цензоры

раслаганнары белән уку һәм чит илләрдә белем алган мөгаллимнәрне шәкертләргә белем бирүдән читләштерү турында белдерә. 1894 елда вакытлыча туктатылып[43], 1899 елдан кабат канун көчен алган[44] бу циркуляр мөдәррисләрдән ел саен май аенда шәкертләр турында хисаплар язып, инспекторларга тапшыруны таләп итә[45]. Кулъязма дәреслекләр һәм әдәбият мөселманнарны гаепләү чыганагына әверелә. Халык мәгарифе министрлыгы язган документтан Р.Фәхреддин аерып алган мондый сүзләр бар: «Ислам мәктәп вә мәдрәсәләрендә басма дини китаплардан башка язма дәфтәрләр дә файдаланылган икән. Бу дәфтәрләрдә ислам вә төркиләрне мактау, русларны гаепләгән шигырьләр язылган икән һәм мөселманнарның Русия кулына кереп, гаскәр буларак алынулары, көннәрнең берендә исламнар өскә чыгачаклары ачык бәян ителә. Югарыда әйтелгән шигырьләр мәктәп вә мәдрәсәдә белем алучы шәкертләр тарафыннан мәҗлесләрдә укыла. Моннан башка, мәктәп вә мәдрәсәләрдә Русия дәүләтенә каршы булган Истанбул басмасы әсәрләре файдаланыла. Мондый китапларда Истанбул солтанының бөтен ислам халкы падишаһы булуы бәян ителә»[46]. Күрәсең, бу материаллар хөкүмәтнең татарлар белән ислам дәүләтләре арасындагы элемтәләрдән, халыкка самодержавиенең кылган гамәлләре хакындагы фикерләр, милли азатлык идеяләре таралуын теләмәвен, шуңа күрә мөселманнарның Рәсәйдә дошманга әверелүен һәм эзәрлекләнүен күрсәтү өчен, автор тарафыннан махсус сайлап алынгандыр. Башка рәсми кәгазьләрдә мөселманнарны «фанатиклыкта» һәм башка гөнаһларда гаепләүләрне автор күрсәтеп тормаган.

Р.Фәхреддиннең урыслаштыру өлкәсендәге хөкүмәт сәясәтенә тискәре карашы тарихчының дәүләт теленә мөнәсәбәте тискәре булган дигән сүз түгел. Бу җәһәттән тарихчы үз фикерен бик ачык итеп әйтә: «Инсан дәүләтнең телен белмәсә, инсан бөтен саналмас. ...шәһәр вә авылларда халык илә берлектә тормыш иткән кеше өчен ана теленнән башка дәүләт телен белү бик мөһим икәнлеге шөбһәсез»[47].

Галим үзенең «Тәрҗемәи хәл»ендә искә алганча, Түбән Шәлчәле авылы мәдрәсәсендә укыганда, егерме яшьтән узгач, аның урыс телен өйрәнүгә «һәвәсе төшә». Ләкин атасы хәзрәт рөхсәт итмәү сәбәпле[48], Р.Фәхреддингә Уфага Диния Нәзарәтенә эшкә килгәч кенә рус телен чын мәгънәсендә ныклап өйрәнү мөмкинлеге туа.

Галим үз балаларына, милли мәктәптән тыш, урыс уку йортларында белем алдыра. Р.Фәхреддин бу адымын болай аңлата: «Әгәр дә атам кебек русча уку бозык әхлакка сәбәп булачак дип белсәм, балаларыма хәтта бер хәреф тә русча укытырга разый булмас идем»[49].

Р.Фәхреддин хезмәтләрендә татарларга каршы алып барылган сәясәтнең иң фаҗигале сәхифәләреннән берсе - мәкруһлар хәле дә читтә калмаган.

Милли аң үсү һәм капиталистик мөнәсәбәтләргә бәйле үзгәрешләр үткән гасырларда дәүләт тарафыннан төрле юллар белән чукындырылган керәшеннәр арасында ислам диненә кире кайту, дин, вөҗдан иреге өчен барган көрәшне көчәйтә, милли-азатлык хәрәкәтенең яңа формасын тудыра. Бу күренеш бигрәк тә XVIII йөздә чукындырылган керәшеннәр (мәкруһлар) арасында күзәтелә. 1905 елга кадәр Рәсәй империясендә яшәгән православие динендәгеләр, нинди милләт вәкиле булуларына карамастан, аларның дәүләт диненнән башка дингә күчү хокукы булмый. Кануннар мондый адымны җинаять дип бәяли.

XIX йөздә дин иреге өчен көрәш көчәя бара. Моңарчы яшерен рәвештә мөселманча яшәп яткан керәшеннәр, җирле православие чиркәү әһелләре һәм полиция кисәтүләренә карамастан, патшага ислам диненә күчерүне сорап гаризалар яза, ачыктан-ачык ислам йолаларын үти башлагач, хөкүмәтнең 1855 елгы 29 май указы пәйда була: «Ислам диненнән христиан диненә мөрәҗәгать итмәгән мәкруһлар Казанның духовная консисториясе хөкеменә җибәрелсеннәр, бармасалар, балалары ата-аналарыннан полиция көче белән алынып, чукындырылсыннар, христиан диненчә яшәмәгән мәкруһлар христиан руханилары тара-

фыннан яңадан чиркәүләргә йөртелсеннәр, әгәр бу эшкә риза булмасалар, ата-аналары аерылсын, ирле-хатынлы булып тормасыннар!»[50] дигән указны Р.Фәхреддин «Болгар төрекләренең дин вә мәзһәбләре» исемле хезмәтенә кертә. Фикерен дәвам итеп, шушы елларда мәкруһлар урыслашсын, чын христиан булсыннар өчен, гаиләләрне көчләп ялгыз-ялгыз рус авылларына таратып утырту, руслар белән аралашырга һәм барлык хәлләре русларның күз алдында булып торырга мәҗбүр ителгәннәрен дә күрсәтеп үтә.

Хөкүмәтнең мәкруһларга карата кулланган җәзалау чараларының бер чагылышы итеп, тарихчы керәшеннәрнең Казан губернасында 1865-1866 елларда киң җәелгән мөселманлыкка кайту хәрәкәтендә актив катнашкан, оештыручы булган, исламга кайтырга өндәгән 47 кешене 1867 елда Турухан якларына сөрү турында карар кабул ителүне атый[51].

Рәсәйдә дәүләт дине булган православие белән ислам диненең хокуклары тигез булмавын күрсәтү өчен галим «Төзелеш уставына» мөрәҗәгать итә. Мөселманнарга мәчет төзү фәкать авылда мәкруһлардан яки христианнардан бер гаилә дә яшәмәгән һәм, гомумән, исламның тирә-якта яшәгән христианнарга тәэсир итү көче булмаган очракта гына мөмкин икәнен ассызыклый[52]. Бу яктан Р.Фәхреддин хөкүмәтнең исламга булган мөнәсәбәтен тәнкыйтьләүдән дә курыкмый. Аерым алганда, көчләп чукындыру турындагы законнар императрица Екатерина II тарафыннан юкка чыгарылган һәм алыштырылган булса да, юкка чыгару һәм алыштырулар кәгазьдә генә булып, гамәлдә һаман үтәлеп кенә торуына игътибар итеп[53], моны нәкъ менә сәясәттәге икейөзлелек белән аңлата.

Рәсәйдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү эше губерна идарәләре карамагында була. Мөселманнар гаризасына православие архиерееннан ризалык алынгач кына, чиновниклар мәсьәләне уңай хәл итә ала. Әгәр консисториядән тискәре җавап килсә, мәчет төзү рөхсәт ителми. Гомумән, XIX йөзнең икенче яртысында православие һәм ислам

мөнәсәбәтләре сәясәтенә бәйле материалларны Р.Фәхреддин ачынып шәрехли. Мәсәлән, православие белән чагыштырганда ислам диненең хокуксызлыгын исбатлап болай бип белдерә: «Мөселманнарның соңгы мөфтиләре (М.Солтанов - И.З.) 25 ел гомерендә бер генә йомышны да патшага җиткештерә алмаган хәлдә, Сәвәләй авылындагы керәшен поп Ильминский үзенең теләгән йомышын Победоносцев аша патшага ирештереп тора иде»[54].

«Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» китабында тупланган материалларның эчтәлеге Р.Фәхреддиннең хөкүмәт алып барган милли сәясәтне татар тарихының мөһим бер өлеше итеп караганлыгы хакында сөйли. Чыннан да, 1552 елдан соң татар-мөселманнарының иҗтимагый-сәяси, икътисади, хокукый хәле, милли мәдәният һәм мәгариф үсеше патша самодержавиесенә нык бәйле була. Шуңа күрә татар халкы тарихын бербөтен һәм эзлекле рәвештә язуны максат итеп куйган Р.Фәхреддин бу мәсьәләгә махсус туктала. XVI-XVII йөзгә бәйле вакытларны тарихчы гадәттә русча басылып чыккан чыганаклардан һәм төрле кулъязмалардан өйрәнә. Ә XIX йөздәге, бигрәк тә гасырның икенче яртысындагы милли сәясәтне өйрәнү чыганаклардан файдалануда аерым кыенлыклар тудыра.

Диния Нәзарәтенә казый булып билгеләнү Р.Фәхреддингә кирәкле чыганакларга юл ача. «Инородец»ларның, бигрәк тә мөселманнарның хокукый хәлен өйрәнү рус тарихчыларының күз уңыннан читтә калганлыгы игътибарга алсак, «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» китабының Рәсәй историографиясендәге фәнни әһәмиятен һәм урынын ачык күрергә мөмкин.

Р.Фәхреддин телгә алган кайбер әһәмиятле рәсми кәгазьләр белән мөселманнар яшерен прокламацияләр аша таныш булалар. Тарихчы исә XX йөз башында яңа иҗтимагый шартлардан оста файдаланып, шуларны баетып, мәсьәләгә объектив карап халыкка ирештерә.

Диния Нәзарәте архивын өйрәнгәндә хөкүмәт оешмалары арасында йөргән рәсми кәгазьләрне анализлау татар тарихчы-

сына самодержавиегә карата үзенең гражданлык позициясен ачыкларга, халыкның иҗтимагый-мәдәни үсеш үзенчәлекләрен һәм аның сәбәпләрен күрергә ярдәм иткәндер. Ул хезмәтнең әһәмиятен аңлап һәм ничек кабул ителәчәген тоеп эшләгән, татарга берләшү һәм милли үзаң уяту өчен тарихка мөрәҗәгать итү кирәклеген, мөһимлеген күз уңында тоткан.

Р.Фәхреддиннең әлеге хезмәтендә телгә алынган һәм XIX йөзнең 60-70 нче елларына караган рәсми кәгазьләрнең күбесе 1936 елда басылган «Материалы по истории Татарии второй половины XIX века» исемле документлар җыентыгында дөнья күрде. Ә 80-90-нче еллар белән бәйле документларның бер өлеше әле һаман да фәнни әйләнешкә кертелмәгән. Күрәбез, китапның фәнни әһәмияте бүген дә югалмаган. Моның сәбәпләренең берсе - «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре»нең үзенчәлекле стильдә язылуы. Мәгълүм булганча, халыкка барып ирешә торган китапларны цензура бик дикъкать белән укып, хөкүмәткә, аерым чиновникларга карата әйтелгән тискәре фикерләрдән «чистартып» гына басарга рөхсәт итә. Р.Фәхреддиннең китабында рәсми кәгазьләрдән өзекләрне аларның номерларын, даталарын күрсәтеп, төгәл тәрҗемә итеп ураштыруы цензорны бик уңайсыз хәлгә куйгандыр. Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре буларак, цензор дәүләт чиновниклары: министрлар, губернаторлар, Диния Нәзарәте мөфтиләре һәм башка түрәләр – кул куйган кәгазьләрдә язылганны, әлбәттә, төзәтә алмаган. Рус чиновникларының татарларга «инородец», ислам динен тотучы «фанатиклар» («фанатизм» беренче нәүбәттә милли изүгә каршы тору булса да) дигән үги карашы документларда ярылып ята, чөнки Рәсәйдә бу гадәти күренеш булган. Документлардан җирле хакимият вәкилләренең руслаштыруны көч кулланып үткәрергә омтылуы күренә.

«Дөньяда яшәргә һәм башкалар рәтендә гомер сөрергә теләгән үзенең үткән көннәрен белсен һәм үз тарихы белән дус булсын» - диләр. Бу сүз бик дөрес. Һәр кавемнең үзенең тарихын, үзенең язуын үз халыкларына

белдерүе кирәк. Ләкин моның өчен монгол һөҗүме астында калмау һәм руслар хөкемендә булмау шарт. Башкалар хакимияте астында яшәүче милләтләр өчен тарих белән шөгыльләнергә мөмкинлек юк»[55], - дип сызланган. Тарихчы хезмәтләре белән шушы бушлыкны тутырырга омтылган, шуңа үз өлешен керткән.

Бүген Р.Фәхреддин мирасы халыкка кайта башлады. Аның тарихи хезмәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләрне дә өйрәнеп, яңа фәнни эзләнүләр башларга вакыт җитте. Бу фикер XIX йөзнең икенче яртысында рус самодержавиесенең татарларга карата сәясәтен өйрәнүгә дә карый.

ИСКӘРМӘЛӘР.

1. Полное собрание законов Российской империи (ПСЗ). - Собр.3. - Т.XVII. - № 5419.
2. ПСЗ. - Собр.3. - Т.X. - Отд.1. - № 6512.
3. Азаматов Данил. Заседатели Оренбургского магометанского духовного собрания в XIX веке//Мир ислама. - 1999. - № 1-2. - С.123-134.
4. Ризаэтдин Фәхретдин:Фәнни-биографик җыентык. - Казан: «Рухият» нәшрияты, 1999. - 47 б.
5. ПСЗ. - Собр.3. - Т.X. - Отд.1. - № 7120.
6. Азаматов Данил. Указанная работа. - С.132-133.
7. Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни биографик җыентык... - 31 б.
8. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. - 1 нче кисәк. - Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов шөрәкясы» матбагасы, 1907. - 2 б.
9. Шунда ук.
10. Шунда ук. - 3 б.
11. Шунда ук.
12. Сборник циркуляров и иных руководящих распоряжений по округу Оренбургского магометанского духовного собрания. 1841-1901гг. /Сост.Р.Фахретдинов. - Уфа, 1902.
13. Сборник циркуляров и иных руководящих распоряжений по округу Оренбургского магометанского духовного собрания. 1836-1903 гг. /Сост. Р.Фахретдинов. - Уфа, 1905.
14. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 1-нче кисәк.
15. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 2 нче кисәк. - Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов шөрәкясы»ның паровой типографиясе, 1908.
16. Шунда ук. - 4 б.
17. Шунда ук. - 5 б.
18. Шунда ук. - 8 б.
19. Шунда ук. - 9 б.
20. Шунда ук. - 9-10 бб.
21. Шунда ук. - 10 б.
22. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 1 нче кисәк.

- 4 б.
23. Шунда ук.
24. Шунда ук. - 5 б.
25. Шунда ук.
26. Шунда ук. - 29 б.
27. Шунда ук.
28. Материалы по истории Татарии второй половины XIX века. - Ч.1. - М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1936. - С.301-302.
29. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 1 нче кисәк. - 12 б.
30. Шунда ук. - 15 б.
31. Шунда ук.
32. Шунда ук.
33. Шунда ук.
34. Шунда ук. - 17 б.
35. Шунда ук. - 18 б.
36. Шунда ук. - 19 б.
37. Загидуллин И.К. Татарская школа и русификаторская политика царизма во второй половине XIX в.//Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. - Казань, 1992. - С.70.
38. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 1 нче кисәк. - 20-21 б.
39. Шунда ук. - 23 б.
40. Шунда ук. - 24-26 б.
41. Шунда ук. - 25-26 б.
42. Шунда ук. - 26 б.
43. Загидуллин И.К. Татарская школа... - С.68.
44. Риза Фәхреддин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. 1 нче кисәк. - 30 б.
45. Шунда ук.
46. Шунда ук.
47. Ризаэддин Фәхреддин: Фәнни-биографик җыентык... - 22 б.
48. Шунда ук. - 21 б.
49. Шунда ук. - 22 б.
50. Ризаэддин Фәхреддинев. Болгар вә Казан төрекләре. - Казан: Таткитнәшр, 1993. - 56 б.
51. Шунда ук. - 54 б.
52. Шунда ук. - 56 б.
53. Шунда ук. - 57 б.
54. Шунда ук. - 225 б.
55. Шунда ук. - 52 б.

М.И.Әхмәтҗанов

РИЗАЭДДИН БИНЕ ФӘХРЕДДИННЕҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ ҺӘМ НӘСЕЛЕ ХАКЫНДА

Соңгы елларда атаклы татар мәгърифәтчесе, язучы һәм дин эшлеклесе Ризаэддин бине Фәхреддиннең иҗаты һәм тормышына кагылышлы монографик хезмәтләр,җыентыклар һәм мәкаләләр басылгалап тора.[1]

Аларда аның әдәби-фәнни эшчәнлеге, биографиясе һәм милли чыгышы хакында капма-каршы фикерләр күренә. Уфада басылган әдәбиятта Ризаэддин бине Фәхреддинне - башкорт язучысы, башкорт галиме, башкорт нәселеннән чыккан кеше итеп күрсәтергә тырышалар, тарихны фальсификациялиләр. Бер төркем галимнәр Ризаэддин бине Фәхреддиннең татарлыгын дәгъвалыйлар.

Хакыйкать кайда соң? Әлеге сорауга тарихи язма чыганаклар белән җавап бирергә мөмкин.

Тарихи чыганаклардан Ризаэддин бине Фәхреддиннең ата-бабаларыннан калган мәгълүматлар нигезендә үзе төзегән шәҗәрәсе, фәнни хезмәтләрендә язылган фактлар, шәхси документлары, ул туган Кичүчат авылындагы татарларның тарихи хәтере һәм кайбер архив документлары нигезле дәлилләр булып торалар.

Галим үз нәселенә кагылышлы шәҗәрә материалларын беренче башлап Оренбургта басылган «Асар» хезмәтендә файдалана.[2] Ул үз нәселенең шәҗәрәсен тулы килеш матбугатка чыгарырга өлгерә алмаган, яки моның өчен мөмкинлеге булмагандыр. Ихтимал, соңгы фикер дөресрәк булса кирәк. Галимнең Петербургтагы Шәрекъне өйрәнүчеләр институты архивында саклана торган фондында аның үз кулы белән төзелгән зур күләмле кулъязма шәҗәрәләр җыентыгы саклана.[3] Бу җыентыкта гына да 41 нәсел шәҗәрәсе язылган. Гомумән, галимнең Петербургтагы кулъязмалары арасында йөздән артык татар һәм беркадәр башкорт шәҗәрәләре кулъязмалары тупланган.

Югарыда искә алынган генеалогик җыентыкның 18а -18б битләрендә Ризаэддин бине Фәхреддиннең үз нәселе шәҗәрәсе дә бирелә. Аның нәсел башы булган иң ерак бабасы Тансар исемле, аның улы Кармыш, Кармышның улы Бакшанды, аның улы Кайбула, Кайбула улы Җангилде абыз, аның улы Түмәкәй, аннан туган Ишкай, Ишкай улы Юлдаш (1690 елда туган, 1762 елда 72 яшьтә үлгән), аның улы - Мөхәммәт (1726 елда туган), аның улы Сөбханкол, аның улы Сәйфеддин, аның улы Фәхреддин, аның улы Ризаэддин (1859 - 1936). Шәҗәрәдә күрсәтелгән Юлдаш бабаны галим үзенең иптәшләре, туганнары, балалары белән Тау ягындагы Шырдан авылыннан чыгып, соңра Кичүй елгасы буенда Юлдаш (Кичүчат) авылын нигезли, дип саный. Шырдан авылы Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәрендә мишәрләр авылы дип язылган.[4] Бу факт галимнең туган авылы булган Кичүчаттагы тарихи хәбәр белән дә туры килә. Кичүчат авылында Ризаэддин бине Фәхреддин туган урамны - «Мишәр очы» дип бүген дә бик яхшы беләләр. Аларның телләрендә мишәр сөйләменең эзләре бүгенге көндә бик ачык чагылмый. Әлеге проблема телче-диалектологлар тарафыннан система буларак өйрәнелергә тиешле.

Галимнең якын туганы Нәҗип Зыятдин улы Фәхреддинов (1898-1989) шулай ук аның фикерләрен үзенең шәҗәрә текстында куллана: «Юлдаш бабабыз 1556-57 елларда чукынудан куркып, «Шырдан»ны калдырып китәргә мәҗбүр була. Бөтен гаиләсе берлән хәзерге Татарстан җөмһүрияте Әлмәт районы, Кичүчат авылына килеп ике су арасына, далага «Юлдаш» аулын тәшкил итә (ягъни сала). Бәгъзе мәгълүматларга караганда, аның белән һиҗрәт кылучы Мөхәммәт тә булган. Моның аулының исеме бүген дә «Мәмәт» дип йөртелә. Бу аул Кичүчатка ике чакрым гына. «Безнең ерак бабаларыбыз «Шырдан»нан күчеп килгәннәр», - дигән 80-90 яшендә булган бер апа бүген дә Мәмәттә яши. Юлдаштан башлап Фәхреддин һәм бу ике арасында булган бабалар барысы Кичүчаты зиратына җирләнгәннәр.

1918 нче елга кадәрле аулының чын исеме Юлдаш булып, кемдер Кичүчатка үзгәрткән. Безгә мәгълүм түгел.

Нәҗип бине Зыятдин Фәхреддинов
Казан, 1976, 15 ноябрь».[5]

Китерелгән бу фикерләр халык арасында шактый ныгып бара иде. Ләкин соңгы елларда тарихчы Таһир Кәримов тарафыннан табылган билгесез архив мәгълүматлары галимнең нәсел тарихына аерым төзәтмәләр кертү кирәклеген шәрехлиләр.[6] Архив чыганаклары күрсәтүенә караганда, Юлдаш баба Ишкәев Әлмәт төбәгенә 1556-1557 елларда түгел, шактый соң күчеп килгән. Ул башта хәзерге Лениногорск төбәге Керкәле авылында яшәгән, 1747 елда Кичүчат авылына күчеп килгән. 1762 елда ул Кичүчатта яши һәм шул елда аңа 72 яшь тулганлыгы күрсәтелгән. Таһир Кәримов Кичүчат авылының беркайчан да Юлдаш дип аталмаганлыгын искәртә. Аның тапкан документы, ягъни 1762 елгы ревизия материаллары хәбәренә караганда, Юлдаш баба типтәр сословиясендә торган.

Таһир Кәримов Ризаэддин бине Фәхреддиннең типтәр сословиясендә булган бабаларының 1855 елда башкорт сословиясенә күчерелүе, шуннан соң Кичүчат халкын рәсми документларда «башкорт» дип атау очраклары булуын яза. Бу проблема XX гасыр башларыда да документларда чагылып үтә. Мәсәлән, мәгърифәтче галим 1919 елның 31 гыйнварында тутырылган рәсми формулярда социаль хәл күрсәтелергә тиешле графада үз кулы белән үзен типтәр (башкорт) дип күрсәтә (документның бу өлешенең копиясе бирелде).[7]

Таһир Кәримов тапкан документта Юлдаш Ишкәевнең хәлле кеше икәнлеге (бер ташлы су тегермәне тоткан) һәм 1762 елда Аккол (43 яшьтә), Бикмәт (36 яшьтә), Морадын (34 яшьтә), Мөхәммәт (21 яшьтә) исемле дүрт улы булуы теркәлгән була. Аккол белән Бикмәт инде өйләнгән булалар, беренчесенең Рахманкол, икенчесенең Сөбханкол исемле 17шәр яшьлек уллары булган. 1795 елгы ревизия вакытында Сөбханкол Бикмәтов документта типтәрләрнең 4 нче командасы старшинасы буларак теркәлгән.

Таһир Кәримовның бу табышлары фән өчен бик мөһим. Алар ярдәмендә без Ризаэддин бине Фәхреддиннең үзебез тапкан башка шәҗәрәләренә дә аныклык кертәбез. Безнең тарафтан 1980 елның җәендә Лениногорск төбәгендә археографик эзләнү эшләре алып барылды. Шул вакытта Керкәле авылында без «Кармыш баба» шәҗәрәсе фрагментларын тапкан идек. Аларның Ризаэддин Фәхреддинов нәселенә мөнәсәбәтле булуын тойсак та, безгә ул вакытта аның нәкъ шулай икәнен белдерергә бер деталь җитми иде. Әлеге кирәкле яңа информация Таһир Кәримов тапкан архив материалында сакланган булып чыкты. Түбәндә Керкәледә табылган шәҗәрәләрнең күчереп алынган фрагментларын урнаштырабыз.

Хәлиулла Фәхреддин улы (1891 елда туган): «Безнең бабайлар Чистай ягы Нөркәй авылыннан килгән. Керкәле авылы - мишәр, типтәр, башкорт таифәләренә бүленгән. Алар тирә-якта авыллар барын белмичә килеп утырганнар. Эт, әтәч тавышлары ишетеп, Сугышлы авылы утырганын белгәннәр».

Бер искәрмә: бу Сугышлы авылын 1730 елларда старшина Нәдер Уразметов салган була, аны «Иске Нәдер» дип атап йөртәләр.[8]

Шәҗәрә

«1580 елдан Русия кулында торабыз. Керкәле шул вакытларда булган. Шул вакытта Казанда бунт булып, Кармыш бабайның атасы бунтта катнашып югала.

Кармыш бабай урманда әби белән торган. Әби Кармыш бабайны биләүсәдә урманда үстерә, мунча коесында. Тора торган өйләре бер куыш имән эчендә булган. Аларның монда килеп чыгулары Иван Грозный вакытында була. Аларны ул вакытта көчләп чукындырган булалар. Кармыш бабайның әтиләре «тип тәресен» дип киткәннәр, шуннан типтәр булып калганнар безнең бабайлар...»

Һади Галимов (1900 елда туган) шәҗәрәсеннән өзек.

«1580 елда туды Кармыш. Кармыш углы Мортаза.

1640 елда туды Мортаза.

Мортаза углы Гобәйдулла 1733 елда туды.

Гобәйдулла углы Сафиулла.

Сафиулла углы Миңнегалим 1862 елда туды.

Кармыш углы Мортаза, Мортаза углы Гобәйдулла, Гобәйдулла углы Байбүре.

Мортазаның тагын Сөбханкол исемле углы була. Сөбханколдан Габделвәли туган...»

Керкәле авылында табылган Кармыш нәселе шәҗәрәсе фрагментлары безнең Лениногорск төбәгендә тупланган мәгълүматлар теркәлгән экспедиция журналында саклана-лар. Кайбер мәгълүматларга, телдә йөргән хәбәрләргә караганда, Юлдаш бабайлар Федотовка авылында яшәп, аннан Керкәлегә килгәннәр. Бу авылда табылган Кармыш баба шәҗәрәсе, һичшиксез, Ризаэддин бине Фәхреддин бабалары тарихына карый. Ул материал Юлдаш бабаның Кичүчатка килгәнче Керкәледә яшәгәнлеген раслаучы татар халкы кулында сакланган документ. Ул документ Юлдашның Шырданнан китүенең чукындырылу куркынычы белән бәйле булуын, башта Федотовкага, аннан Керкәлегә килгәч тә аларның авыр шартларда качып йөрергә мәҗбүр булуларын раслый. Моннан тыш Керкәледә галимнең билгесез булып кала килгән йөзләрчә кан кардәшләренең яшәгәнлеге раслана. Алар арасында Кармышев фамилиясен йөрткәннәре дә булган. Керкәле материалында Кармыш бабаның ятим калуы, аның ниндидер Казан бунты вакытында югалуы кебек хәбәрләр дә мөһим. Алар Тау ягында Кармыш баба хакында сакланган генеалогик риваятьләргә өстәмә мәгълүматлар бирәләр. Мәсәлән, аның атасының Казанда булган ниндидер бунт вакытында югалу факты мөһим.

Ризаэддин хәзрәтнең кызы Әсма ханым Шәрәф безгә әйтүенә караганда, аның әтисенең кулында Кармыш әл-Болгари исемле бабасы тарафыннан XVII гасыр башларында күчерелгән кулъязма китап була. Шул фактка таянып, галим үзен «болгар» нәселе дип санап йөргән. Якынча исәпләп караганда, Кармыш баба 1580 елларда, чынан да, Казан илендә татар һәм мариларның колонизаторларга каршы көчле восстаниесе барган вакытларда

туган булса кирәк. Бу тарихның тулырагы Тау ягы шәҗәрәләрендә күбрәк чагыла.

Нәселнең Тау ягында калган борынгы бабалары турында

Ризаэддин бине Фәхреддин шәҗәрәсенең төп бабалары булып Тансар, Кармыш, Бакшанды, Кайбула, Җангилде исемле кешеләр санала. Бу шәхесләр турында рәсми тарихи документларда, шәҗәрәләрнең үзләрендә, Каюм Насыйриның язып алган тарихи генеалогик легендаларында байтак хәбәрләр сакланган. Аларны хәзер нәсел тарихы материалы яктылыгында бер тәртипкә китереп бәян итәрбез. Санап үтелгән бабалар исемлеге галим үзе төзегән текста һәм Нәҗип Фәхреддинов,[9] Әсма Шәрәф,[10] Арслан Шәрәф,[11] Самдун Фәхреддиновлар тарафынан эшләнгән[12] шәҗәрәләрдә бар.Ләкин аларның нәсел легендасы бары баштагы авторда гына күрсәтелә. Боларның эчтәлеге югарыда беркадәр искә алынды инде.

Тау ягында узган гасырлардан калган «Чирүче», «Кармыш баба»ның Татар Танаенда һәм Каюм Насыйриның «Зөя өязе» хезмәтендә сакланган шәҗәрә текстлары Ризаэддин бине Фәхреддиннең ерак бабалары тарихына яңа хәбәрләр өстиләр. Шулай ук XVII-XVIII гасырлардан калган урыс телендәге документлардан да файдалы хәбәрләр табарга мөмкин.

«Чирүче шәҗәрәсе» Тау ягының Тәтеш, Олы Тархан, Маныт, Буа төбәкләре белән бәйле.[13] Шәҗәрәдә Казан алынганда алтын бишектә ятим бала табу, патша баласы хакындагы риваять кызыклы. Алтын бишектә табылган балага Чирүче дигән исем кушыла һәм ул бик галим кеше булып үсә. Татар Танае авылында табылган иске кулъязма җыентыкта Нурыш, аның улы Кармыш, аның улы Туктар... шәҗәрәсе теркәлгән. Андагы легендада: «...Кармыш бине Нурыш. Бу Нурыш падишаһ баласы, алтын бишектә табылган дип риваять бар».[14] Ризаэддин бине Фәхреддиннең үзе төзегән зур кулъязма шәҗәрәсендә Кармыш бабаның (автор аны Курмыш дип яза) уллары

Җангилде белән Җанҗегет биләгән җирләргә урыслар Сенбер каласын корганнар (1648 елда) дигән хәбәр китерелә.[15] Болар бәрабәренә алар Шырдан якларыннан бүләккә җирләр алганнар. Кармыш белән Җангилденең чуаш арасында җир алып, авыл корып йөрүләре шул тарихның чагылышы дип санарга нигез бар.

Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның соңгы елларда гына нәшер ителгән, әүвәлдә ни сәбәптәндер басылмый яткан «Зөя өязе» исемле тарихи археографик хезмәтендә Кармыш нәселенә караган күп хәбәрләр бар.[16] Шулай ук аның бу хезмәтенә чыганак булган бер кулъязмасы (Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә 815 т (8) шифры белән саклана) өстәмә мәгълүматларга ия. Түбәндә кулъязманың төп текстын китерәбез:

«Кармыш баба Йангилде исемле углы илә Тәтеш өязеннән, Тәтеш диян авылдан күчеп килеп, Чынчас чуашларыннан бер өй урны сорап алыр икән. Ничә елларга кадәр Тәтешкә һәм монда ашлык чәчкән икән. Җәмәгатьләре күбрәк Тәтештә булынлар икән. Балалары күп булгач, монда хатынлар алганлар икән, шуннан үрчегәнләр. Кармыш урнына күчеп ултырганлар, йир һәм биргәнләр.

Чынчас, Әлмән искеләр икән. Кармыш баба ничә йирләр йоклап караган икән, мондан җайлысын тапмаган икән. Әлмән берлә ике йоклаганлар икән, әнвагъ хәшәрәтләр күргәнләр икән.

Сәмигулла Ишмөхәммәд дигәндән.

Чуашлар Буа буенда, Кавал юлы җанында. Җамаш кырыенда. Җамаш ул мөселман казак булганлар икән. Шуларның зияраты икән. Сәмигулла Ишмөхәммәд дигәндән».

Каюм Насыйриның «Зөя өязе» исемле хезмәтендәге шәҗәрәсенең мәгълүматларын караганда исә, Кармыш баба Тәтештән, Янгилде (Җангилде) һәм Заид исемле уллары белән килеп, Кармыш авылын нигезли. Аларның нәсел шәҗәрәләре сакланган: Кармыш бине Янгилде бине Актаби бине Арслан мулла бине Габдерәхим мулла бине

Мөрсәлим мулла бине Нигъмәтулла бине Мөхәммәтвәли бине Нигъмәтҗан (Кармышта). Бу нәселдән Габдерәхим бине мулла Арсланның һиҗри 1184, миляди 1770 елда язган бер документы сакланган.

Кармышның икенче улы Заид берничә вакыт Җуынчы авылында имам була, аннан Кошманга күчә. Анда аның нәсел шәҗәрәсе түбәндәгечә: Кармыш бабаның бабаларының бабасы Нәреш, аның углы Туктар, аның углы Кармыш баба, аның углы Заид, аның углы Гомәр, аның углы Сәйфеддин, аның углы Фәхреддин, аның углы Шәрәфеддин (хәзер дә Кошманда имам) аның углы Хәйреддин.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең Петербургта сакланучы архивында аның Тау ягында калган кардәшләре тормышыннан кечкенә күләмдәге бер урысча шәҗәрә саклана. Ул нәсел Бәрлебаш авылында (хәзер Апас районына керә. - М.Ә.) Енайдаров фамилиясе белән мәгълүм була. Кармышның улы Җангилде, аның улы Җанҗигит Енайдаров - генерал. Аның улы Суки Җанҗигитов - генерал. Аның улы Дмитрий Сукиев - майор. Аның улы Усман Бектимиров - прапорщик. Аның улы Мәхмүт Усманов - прапорщик. Аның улы Вәлиша Мәхмүтов - мулла. Ул 1810-1811 елларда вафат була. Аның улы Сәгдетдин Вәлишев - правной.[17] Ул 1868 елның 10 октябрендә 59 яшьтә вафат булган. Аның улы Шәмсетдин Сәгдетдинов - исән. 47 лет. Потомки мурз.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең басар өчен хәзерләнгән «Шәҗәрәләр җыентыгы»на кергән үз нәсел язмасына бу русча текст та татарчага тәрҗемә итеп кертелгән. Димәк, галим үзенең Тау ягында кардәшләре калганны яхшы белгән булып чыга.

Күзәтү ясалган генеалогик материаллар Тау ягында Ризаэддин бине Фәхреддин нәселдәшләренең XX гасыр башында да яшәүләрен күрсәтәләр.

Инде галимнең нәселе Казан арты төбәкләренә дә таралганмы икән, дигән сорауга «әйе» дип җавап бирергә мөмкин. Казан өязенең 1603 елгы «Писцовая кенәгәсе»-

нең хәбәрләренә караганда, анда инде 1581 елда ук Тау ягы мирзалары һәм князьләре яулап алынган җирләрдә үзләренә өлеш ала башлыйлар. Мәсәлән, князь Бакшанда Нурышев һәм аның атасы Нурыш Урсеков Арча юлында бер авылны бер-бер артлы биләгәннәр. Бу исемнәрдән Бакшанда һәм Нурыш Тау ягындагы Кармыш шәҗәрәсенең башында торалар. Кармыш нәселе дә, Нурышевлар да - князьләр (патша нәселләре булып саналалар). Бакшанда Нурышевны Кармыш нәселеннән аерып булмый.

Янә дә Кармыш нәселенә караган Янайдаров фамилиясен йөртүче йомышлы татарларның 1646 елда Казан бистәсендә яшәгәнлекләре билгеле: «Ишейка Янайдаров з детьми, с Утейком да с Уразмаметком да с Ахмаметком да с Московком».[18] Бу тармакларны архив чыганаклары белән тикшереп өйрәнергә кирәк.

Казанда һәм Казан артында Тау ягыннан чыгып утырган татар мирзаларының тарихлары махсус өйрәнелмәгән. Ул мәсьәләне өйрәнү күп кызыклы ачышларга кирер иде һәм моның өчен җирле чыганаклар да юк түгел.

Без Ризаэддин бине Фәхреддиннең хәзерге Әлмәт, Лениногорск районнарында, Тау ягы төбәкләрендә, искедән калган тарихи чыганакларда сакланып калган шәҗәрәләренә, аларны өйрәнүгә ярдәм иткән беренчел кул тарихи чыганакларга һәм галимнәрнең архив материалларына таянып язган әсәрләренә анализ ясадык.

Бу мәгълүматлар күрсәткәнчә, галимнең нәселләре кай тирәләрдә яшәсәләр дә, үзләренең нәсел тарихлары буенча бик тулы ук булмаса да, шактый мәгълүматлы булганнар һәм ул информацияне, шәҗәрәләр төзеп, киләчәк буыннарга тапшырырга тырышканнар. Ризаэддин Фәхреддин үзенең шәҗәрәсен кулъязма чыганаклардан өйрәнеп үзе төзегән. Бүгенге көндә туганнары тарафыннан галимнең шәҗәрәсе тагын да тулырак рәвештә төзелә бара. Соңгы вакытта Кичүчаттан чыккан инженер Самдун ага Фәхреддиновның бу өлкәдәге хезмәте аеруча бәрәкәтле төс алды. Ул төзегән шәҗәрәдә исемнәр саны 400 чамасына җиткән, һәм

бу эшчәнлек дәвам итә. Бу өлкәдә Дамир Гарифуллин һ.б. эзтабар галимнәр үзләренең өлешләрен кертеп торалар.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең Керкәледә, Тау ягы төбәкләрендә калган кардәшләре тарафыннан XIX гасырда берничә шәҗәрә төзелгән. Аларның кайберләрен күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри 1870 елларда Зөя өязенә оештырган археографик эзләнүләре вакытында күчереп алган. Аның кайбер чыганаклары XVIII гасырга да карыйлар.

Бу материаллар Ризаэддин бине Фәхреддиннең XVI гасыр урталарыннан ук килгән атаклы татар бикләре, мирзалары нәселеннән килгән татар булуын исбатлыйлар. Аның бабалары да барлык татар-мөселманнар өчен зур афәт булган көчләп чукындыру кампанияләрен күреп, аннан зур авырлыклар кичереп котылганнар.

Аның нәселе, кайберәүләр уйлаганча, беркайчан да башкорт дигән милләткә катышы булмаган, ә саф мөселман татар булып килгән һәм калачак.

Русиядә 1920 елларга кадәр документларда «милләт» дигән графа булмаган, анда социаль хәл һәм дини нисбәт кенә күрсәтелгән. Шунлыктан Ризаэддин бине Фәхреддиннең милләтен башкорт итеп күрсәтүнең бер мәгънәсез дәгъва икәнлеге көн кебек ачык. Аның балалары Зәйнәп, Әсма, туганнары Салих Фәхреддинов, Нәҗип Фәхреддиновлар үзләренең нәселләрен татар дип санап йөрделәр һәм татарча сөйләшә, яза, укый иделәр. Паспорт графаларына да татар милләтеннән дип язылган. Аларның язмалары моңа өстәмә дәлил һәм архивларда ышанычлы документлар булып сакланалар.

Галимнең нәсел шәҗәрәсе белән дә кызыксыну арта бара. Нәҗип Зыятдин улы Фәхреддинов һәм Әсма Шәрәфләр башлаган эшне бүген Кичүчат авылында туып үскән Самдун Фәхреддинов, Сарманнан Дамир Гарифуллин, Әлмәтнең Ризаэддин Фәхреддин исемендәге татар гимназиясе укытучылары һ.б. дәвам итә. Аларның күчермәләре, автографлары музейларга, академик архивларга туплана бара.

Бу эшкә Лениногорск төбәгенең Керкәле авылы һәм Тау ягы эзтабарлары да кушылып, бөек галимебезнең

тормыш юлын, нәселен өйрәнүгә кыйммәтле өлеш кертә алырлар иде. Ә моның өчен ышанычлы нигез бар.

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР

1. Әхмәтҗанов М. Риза Фәхреддинов шәҗәрәсе //Казан утлары. - 1984. - № 1.- 164-168 б.; Творчество Ризы Фахретдинова. Исследования, материалы. - Уфа, 1988; Кәримов Таһир. Р.Фәхретдинов шәҗәрәсе // Казан утлары - 1994.- № 4. - 144-145 б.; Баишев Ф.Н. Общественно-политические и нравственно-этические взгляды Ризы Фахретдинова. - Уфа, 1996; Хөсәйенов Гайса. Ризаитдин бин Фәхретдин. - Өфө: «Китап», 1997; Ризаэтдин Фәхретдин. Фәнни-биографик җыентык. - Казан: «Рухият» нәшрияты, 1999; Башкортостан. Краткая энциклопедия. - Уфа: Научное издательство «Башкирская энциклопедия», 1996, - 604 б.; Татарский энциклопедический словарь. - Казань: Институт татарской энциклопедии. 1999. - 610 б. һ.б.

2. Асар, 2 нче җөзьэ. -Оренбург, 1901. - 70-73 б.

3. 131 фонд, 1 тасвир., 50 сак. берәмлеге.

4. Мөслими. Тәварихе Болгария. - Казан: «Иман» нәшрияты, 1999. - 30 б.

5. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсе (моннан ары: ТӘСИ Мирасханәсе): 99 кол. 1 тасвир., 26 сак. бер.

6. Кәримов Таһир. Р.Фәхреддинов шәҗәрәсе //Казан утлары. - 1994. - № 4. - 144-145б.

7. ТӘСИ Мирасханәсе: 125 ф., 1 тасвир., 19 сак. бер.

8. Шунда ук: 99 кол., 1 тасвир., 340 сак. бер; Рәхимов Җәмит. Шөгер төбәге - хәзинәләр чишмәсе. - Изготовлено фирмой «СТАР». 1997. - 70-71 б.

9. ТӘСИ Мирасханәсе: 99 кол., 1 тасвир., 26, 122 сак. бер.

10. Ризаэддин Фәхреддин. Фәнни-биографик җыентык. - Казан: «Рухият», 1999. - 39-41б.

11. ТӘСИ Мирасханәсе: 125 ф., 1 тасвир., 23-24 сак. бер.

12. Шунда ук: 99 кол., 1 тасвир., 332 сак. бер.

13. Шунда ук: 99 кол., 1 тасвир., 69,329,330,331,337 һ.б. сак. бер.

14. Шунда ук: 99 кол., 1 тасвир., 62 сак. бер.

15. Ризаэддин бине Фәхреддин. Асар. 2 җөзьэ. - Оренбург, 1901. - 71 б.; Әхмәтҗанов М. Риза Фәхретдинов шәҗәрәсе // Казан утлары. - 1984. - № 1 - 165 б.

16. Насыйри Каюм. Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1975. - 7-44 б.

17. ТӘСИ Мирасханәсе: 99 кол., 1 тасвир., 339 сак. бер.

18. Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги города Казани 1565-1568 гг. и 1646 г. - Л.: Изд-во АН, 1932. - С.116-119.

Каюм Насыйри материаллары буенча төзелгән Кармыш шәҗәрәсе



Кармыш - Чуаш республикасы Козловка районы, татар авылы
Сенбер - Ульяновск шәһәре.
Бакырчы - Татарстанның Кайбыч төбәгендәге татар авылы.
Җуынчы - Кайбыч төбәгендәге авыл.
Кошман - Кайбыч төбәгендәге татар авылы.

Р.Г.Хәйретдинов

ТАТАР РУХАНИЛАРЫ ҺӘМ СӘЯСӘТ (РИЗА ФӘХРЕДДИНОВ МИСАЛЫНДА)

Татар халкының барлыкка килүе һәм яшәеше гаять катлаулы тарихи шартларда барды. Аны шактый этапларга, борылышларга бүләргә мөмкин. Аларның һәркайсы халкыбыз яшәешенә яңа эчтәлек бирде, уңай яисә тискәре йогынты ясады. Ләкин татар халкы нинди генә кыен шартларда гомер сөрсә дә, үзендә яшәү көче тапты, үз милләтен, динен, мәдәниятен саклап кала алды.

Халкыбызның Европа тарихына кереп калырдай иң зур казанышларының берсе - Идел-Урал җирләрендә беренчеләрдән булып үз дәүләтенә нигез салуы булды. Аның икенче зур адымы - халкыбызның ислам динен кабул итүе, дип әйтә алабыз.

Дәүләт һәм дин берничә гасырлар буе милләтне берләштерү юлында зур эш алып бардылар. Дәүләт эшлеклеләре һәм руханиларыбыз, кагыйдә буларак, бер-берсен аңлап, үзара теләктәшлек иттеләр. Ләкин бу юлда барысы да тиешле дәрәҗәдә булды, дип әйтеп булмый.

Нәтиҗәдә милли дәүләт юк ителде. Дәүләткә төрле варисларның дәгъвасын, аерым этник төркемнәрнең каршы якка чыгуын һ.б. шундый тискәре күренешләрне абруйлы руханиларыбыз, кызганычка каршы, үз вакытында гамәлдән чыгаруга ирешә алмадылар. Әлбәттә, мондый аяныч хәлләр безнең милләткә генә хас нәрсәләр түгел иде. Ләкин татар язмышында бу тискәре күренешләр фаҗига төсен алды.

Дәүләтнең җимерелүе милләтебезне гаять авыр шартларга куйды. Аның табигый үсеш мөмкинлеге нигездә киселде. Әлеге чорларда милләтнең бердәнбер таянычы, аны рухи яктан ныгытучы, берләштерүче көч булып динебез һәм ислам нигезләрен халык зиһененә сеңдерүче руханиларыбыз булды. Алдынгы карашлы, иҗади фикер йөртергә сәләтле руханиларыбыз халкыбызга алга таба бару юлларын күрсәттеләр.

Милләтебез үткән юлда татар руханиларына үзләрен үгет-нәсихәт белән дә, кулга корал тотып та, белем-мәгърифәт тарату юлы белән дә күрсәтергә туры килде.

Дәүләтне җимерү чорларында яулап алучылар иң беренче бурыч итеп халкыбызны диннән аеру максатын куя. Аның изге йортлары-мәчетләре, мәдрәсәләре туздырыла, дин сагында торучы каһарманнары кырыла. Кыскасы, ислам динен юкка чыгару, халыкны христианлаштыру максаты куела. Ләкин берничә гасыр буена алып барылган әлеге сәясәт тиешле нәтиҗәләрне бирми.

XIX йөзнең икенче яртысында - XX гасыр башында инде Рәсәй хөкүмәте ислам динен «терпимый» диннәр төркеменә кертәргә мәҗбүр була. «Терпимый» («түзеп торырлык») төшенчәсе әле хакимиятнең ислам дине белән килешүе дигән сүз түгел иде. Бу аның фәкать яңа ысулларга мөрәҗәгать итүен генә күрсәтә. Яманаты чыккан Ильминский күрсәткән юл шушы ысулларның берсе булды. Рәсәйнең XIX йөз ахыры - XX йөз башларындагы эчке хәле гаять катлаулы, каршылыклы иде. Бу чорда киң халык массалары теләктәшлек күрсәткән оппозицион сәяси фиркаләр һәм агымнар барлыкка килә. Патша хөкүмәте белән күп гасырлар дәвамында хезмәттәшлек иткән чиркәү әһелләре дә хәтта өч агымга бүленә. Алар арасында да кайбер радикаль агымнарны күзәтергә була. Әлеге факт Рәсәй җәмгыятенең гаять катлаулы үзгәрешләргә юлыгуын күрсәтә.

Ислам динен тотучылар арасында патша хакимиятенә каршы оппозиция шактый ныгый. Бу хәрәкәт бигрәк тә җәдидчелек юнәлеше белән барган мәдрәсә шәкертләре һәм хәлфәләре, алдынгы мөселман зыялылары арасында тарала.

Югары дәрәҗәле татар руханиларының патша хөкүмәтенә булган мөнәсәбәте аерым игътибарга лаек. Мәгълүм булганча, аларның күбесе Идел-Урал төбәкләрендәге мәдрәсәләрне тәмамлаганнан соң, үзләренең белемнәрен Истанбулда, башка чит ил мәшһүр уку йортларында үстергәннәр. Кагыйдә буларак, киң карашлы, дин өлкәсендә дә, дөньяви фәнннәрдән

дә нык хәбәрдар шәхесләр булганнар. Алар арасында Рәсәй университетларын тәмамлаучылар да очраган.

Совет чорындагы тарихи әдәбиятта дин әһелләренә карата тискәре караш хөкем сөреп килде. Революцияне алгарышның бердәнбер юлы дип фикер йөртү кагыйдә булганлыктан, башка төрле фикерләр, дәлилләр, кызганычка каршы, исәпкә алынмый иде. Шуның аркасында безнең әдәби һәм фәнни мирасыбыз, интеллектуаль байлыгыбыз бик нык тарайтып каралды.

Югары дәрәҗәле татар руханилары арасында Ризаэддин Фәхреддиновның эшчәнлеге аеруча бай һәм үзенчәлекле. Шунысы игътибарга лаек: кайбер танылган татар руханиларыннан аермалы буларак, ул олы, мәшһүр мәдрәсәләрдә укымаган. Шәрекъ илләрендә дә булмаган, дөньяви уку йортларында да аңа белем алырга туры килмәгән. Асылда ул үз өстендә бик нык эшләве, тырышлыгы, зур табигый таланты аркасында гына мәшһүр галим, дин белгече булып җитешә алган. Аның энциклопедик белеме безне бүген дә таң калдыра.

Риза Фәхреддиновның сәясәткә мөнәсәбәте турында сүз алып барганда аның тормыш юлын өйрәнү шактый фикерләр уята. Бер караганда, ул сәясәттән ераграк торырга омтыла кебек. Дәкин аның гаять зур абруе, фәнни, публицистик эшчәнлеге күпләргә үзенең йогынтысын ясамый калмый.

Әйтик, аның «Вакыт» газетасында, бигрәк тә үзе нигез салган «Шура» журналындагы бик күп санлы мәкаләләрен алыйк. Аларда дөньякүләм мәшһүр тарихи шәхесләр тормышы, аларның эшчәнлеге, татар халкының тарихи юлы, аның күренекле уллары һ.б. проблемалар киң яктыртыла. Әлеге мәкаләләр үзләренең фәннилеге, төплелеге, яшәешнең төрле якларын колачлавы белән киң катлам укучыларга шифалы йогынты ясыйлар, аларда гуманистик караш тәрбиялиләр. Шул ук вакытта галим татар халкының күренекле шәхесләре белән хат алыша, аларның иҗатына уңай тәэсир итә, яңа эзләнүләргә рухландыра.

Шул уңайдан бер мисал китерү урынлы булыр.

XIX гасырның икенче яртысында һәм XX йөз башында, Рәсәйдә патша хакимиятенә каршы торучы сәяси көчләр активлашкан чорда, татар зыялылары үз халкының милли аңын үстерүдә шактый кыю эш башкаралар. Бу юлда әһәмиятле адым - милләтнең үткән тарихын өйрәнү, аңа фәнни бәя бирү булды. Шундый шәхесләрнең берсе - Гайнеддин Әхмәров иде. Ул Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы буларак, әлеге оешма чыгарган журналда күп кенә мәкаләләрен бастыра.

Риза Фәхреддинов Әхмәров язмалары белән танышып барган, күрәсең. Җәмгыять әгъзасының 1903 елда «Мишәрләрнең теле һәм милләте» исеме астында рус телендә чыккан күләмле мәкаләсен игътибар белән укыганнан соң Риза казый тарихчыга хат белән мөрәҗәгать итә. Ул үзенең Әхмәров хезмәтеннән бик канәгать булуы хакында яза. Шул ук вакытта мөселманнар арасында тагын бер - «типтәр» атамасын йөрткән төркем булуын һәм аның турында моңарчы тиешле дәрәҗәдә фәнни хезмәт булмавын күрсәтә.

Гайнеддин Әхмәров күренекле мөселман руханиеның һәм, автор язганча, шул ук дәрәҗәдә «язучы һәм тарихчы булып танылган» шәхеснең тәкъдимен зур җаваплылык белән кабул итә. Нәтиҗәдә, 1908 елда инде телгә алынган Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләр»ендә «Типтәрләр һәм аларның килеп чыгышы» исеме астында рус телендә күләмле фәнни хезмәт басылып чыга. Махсус әдәбиятны җентекләп тикшерү, тел, фольклор һәм һәртөрле башка чыганакларны тәфсилләп өйрәнү үз нәтиҗәләрен биргән. Бу мәсьәләгә багышланган башка әсәрләреннән әлеге хезмәт фәнни югарылыгы, тирән дәлиллеге белән аерылып тора. Гайнеддин Әхмәров татар халкының үз дәүләтен фаҗигале төстә югалтканнан соң килеп чыккан ясалма бер этник төркемен тасвирлый. Төгәлрәге, Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан вәхшиләрчә

җимерелгәч, Урал якларына китәргә мәҗбүр булган зур бер өлешенең тарихын торгыза. Бу төркемнең ни өчен «типтәр» исемен йөртүен дә, аннары ни сәбәптән «яңа башкорт» дип аталуны кулайрак күрүен дә ышандырырылык итеп дәлилли.

Җыеп әйткәндә, югарыда китерелгән мисал, ике күренекле шәхеснең кулга-кул тотынып үз халкының милли аңын үстерү, аны берләштерү юлында алып барган гаять әһәмиятле эшләре турында сөйли. Ә мондый гамәлләрнең Рәсәй империясендә иҗтимагый-сәяси күтәрелеш шартларында кылынуы - аларның юнәлешен һәм эчтәлеген анык билгели.

Совет чоры мөселман руханилары өчен тагын да авыррак булды. Ил башында торучы фирка һәм хакимият дәһрилекне идеологик эшенең нигезе дип санап, динне даими рәвештә кысрыклау сәясәте алып барды. Шундый шартларда шактый зур руханиларыбыз чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр булды. Кайсылары кулга алынды, кайберләре мәҗбүри төстә диннән ваз кичте.

Риза Фәхреддин 1922 елдан башлап мөфти булып торды. Ул зур түземлек белән фәнни эшен, мөфтилек вазифасын җиренә җиткереп башкарды. Шик юк ки, ул иртәме-соңмы илдә уңай үзгәрешләр булачагына ышанды. Аның түземлелеге, кыйбласына тугрылыгы хәзерге заман кешеләренә үрнәк булып тора, фәнни хезмәтләре - халкыбыз рухи мирасының әһәмиятле сәхифәләрен тәшкил итә. Катлаулы сәяси вәзгыятьтә гомер сөргән һәм иҗат иткән Риза Фәхреддинов кебек олпат, түземле, сынмас рухлы шәхесләребез халкыбыз өчен якты маяк хезмәтен үти.

А.А.Арсланова

Р.ФӘХРЕДДИНОВ ИҖАТЫНДА КӨНЧЫГЫШ ЧЫГАНАКЛАРЫ («ШУРА» ЖУРНАЛЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ БУЕНЧА)

Күренекле мәгърифәтче, галим-энциклопедист Р.Фәхреддинов иҗаты XIX гасыр ахыры - XX гасыр башына, ягъни татар халкының милләт булып калыплашу, милли хәрәкәт нык көчәйгән чорга туры килә. 1905 елгы революция бу процесска куәтле этәргеч бирде. Татар зыялыларының алдынгы вәкилләре актив иҗтимагый эшчәнлек җәелдерде, гомумән алганда, милли үзаң дәрәҗәсе үсте, шуның нәтиҗәсе буларак, милли тарих белән тирән кызыксыну уянды. Гасырлар чигендә татар тарих фәне өлкәсендә бик күп яңа исемнәр пәйда булды. Рухи остазларның, элгәрләрнең берсе, әлбәттә, Ш.Мәрҗани иде. Билгеле булганча, үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле мәшһүр хезмәтендә ул төрле чыганакларга, шул исәптән, көнчыгыш галимнәренең гарәп, фарсы, төрки телләрдәге хезмәтләренә нигезләнеп, татарлар арасында беренчеләрдән булып милли тарихны өйрәнүне чын фәнни нигезгә салуга юл ачты[1]. Аның иҗаты, соңрак Р.Фәхреддинов иҗаты кебек үк, урыс һәм Европа галимнәренең хезмәтләрен тирәнтен өйрәнү һәм алар белән аралашу нәтиҗәсендә үсте. Бу очраклы хәл түгел. Чөнки бу чорга кадәр үк урыс ориенталистлары Көнчыгыш галимнәренең фәнни хезмәтләрен җыю, өйрәнү һәм системага салу, аларны урыс тарих фәне хаҗәтләренә туры китереп куллану өлкәсендә гаять зур эш башкарган иделәр. Ләкин, гомумән алганда, революциягә кадәр Россиядә көнчыгыш илләр тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү күп очракта филология өлкәсе белән чикләнеп килде. Чыганакларны өйрәнү, фәнни аңлату ысулларын һәм методологиясен эшләү асылда беренче планда торды. Бу эш белән Мәскәү, Петербург, Казан шәһәрләрендәге көнчыгыш тарихын һәм культурасын өйрәнүче эре фәнни үзәкләр шөгыль-

ләнде. Н.Н.Фирсов язганча, «...татар галимнәре үз төбәкләренең тарихын өйрәнү мәсьәләсендә башка халык галимнәреннән артта калмадылар гына түгел, бәлки хезмәтләренең күплеге белән узып та киттеләр дияргә була»[2].

Өстәп шунысын да әйтергә кирәк, бу хезмәтләрнең кайберләре гаять зур фәнни әһәмияткә дә ия иде. Ш.Мәрҗанинең инде әйтеп үтелгән «Мәстәфадел-әхбар...» дигән хезмәте үзе генә дә бер тарихчы галим дә читләтеп үтә алмаслык кыйммәтле фәнни чыганак ул. Галим бу хезмәтендә татар халкы тарихына кагылышлы һәм урыс галимнәренә мәгълүм булган тарихи чыганакларны җыюны максат итеп куя. М.Г.Госманов язганча, «...аңардан фәнни чыганакларга без аңлаганча анализ һәм төзек бер классификацияне эзләү дөрес булмас, аның фәнни чыганакларны өйрәнү эшен, гомум алганда, эзләп табу, җыю дип бәяләргә кирәк. Бу өлкәдә ул үзен тынгысыз галим итеп күрсәтте»[3].

Р.Фәхреддинов мәдрәсәдә укыган елларда ук Ш.Мәрҗани йогынтысына «эләгә» һәм аны мәгълүм дәрәҗәдә Мәрҗани шәкерте, Мәрҗани фикердәше дип әйтергә була. Мәрҗанинең бөтен хезмәтләрен үзенә җыярга омтылуы да әнә шул хакта сөйли[4].

Ш.Мәрҗани фәнни чыганаклар белән эшләү принципларын махсус шәрехләмәсә дә, Р.Фәхреддинов иҗатында, аның хезмәтләренең эчтәлегендә олуг галимнең эш ысулы сизелә. Үз чорының талантлы, алдынгы вәкиле һәм гыйлемгә ихлас бирелгән кеше буларак, Р.Фәхреддинов фәннең төрле тармаклары белән тирәнтен кызыксына. Философия, тарих, педагогика, тел гыйлеме, әдәбият, сәнгать, этнография, медицина һәм башка күп төрле фәннәрне өйрәнә һәм чын энциклопедистларга хас рәвештә һәр өлкәдә сизелерлек эз калдыра.

Гарәп, фарсы, төрек, урыс телләрен яхшы белү дә аңа татар халкы һәм Урта Идел төбәгендәге башка халыклар тарихын язарга нык ярдәм итә. Мәдрәсәдә укыган чорда ук төрле кулъязмалар җыю һәм күчерү гадәте дә бик

ярап куя. Уфа шәһәрендә Диния Нәзарәте архивында эшләү еллары да бу җәһәттән ифрат файдалы була. Ул анда кулъязмаларны өйрәнү, системалаштыру, тәртипкә салу белән шөгыльләнә. Мәгълүм булганча, Октябрь революциясенә кадәр татар кулъязмаларын җыю һәм саклауга зур әһәмият бирелмәгән. Шул елларда галимнең шәхси китапханәсе үзе күчергән кулъязмалар белән байый. «Шура» журналында басылган мәкаләләре аның милли язма мираска никадәр сак, игътибарлы булуын тагын да ачыграк күрсәтә. Бай милли мираска ваемсыз караш яшәп килүгә ачынып, ул: без борынгы кулъязмаларның кадерен белмибез, аларны саклау чарасын күрмибез, бездә борынгы китаплар саклардай бер китапханә яисә музей да юк, дип яза. «Кулда булган язмаларны да яшерәбез, күчереп язарга да рөхсәт итмибез. Халкыбызның күпчелеге авылларда яши, ә анда еш кына янгыннар чыга... Шул сәбәпле ата-бабаларыбыздан андый мирас аз калган. Мондый хәл дәвам итсә, бездән соңгы киләчәк буыннарга нәрсә булса да калуы шикле», дип янә борчылуын белдерә[5].

1908 елның 10 январеннан үз редакторлыгында чыга башлаган либераль юнәлештәге «Шура» журналының һәр санында (барлыгы 240 сан) тарихчы күп төрле темаларга багышланган мәкаләләрен бастыра. Уебызча, үзләренең фәнни әһәмиятен алар бүгенгәчә югалтмаган, чөнки укучыны көнчыгыш авторларының ул вакытта әле дөнья күрмәгән, әмма безнең як һәм халкыбыз тарихына да кагылышлы әсәрләре белән таныштыра. Бу игелекле эшне башлап җибәрүче шәхес нәкъ менә Р.Фәхреддинов булды. «Шура» журналы аркылы тарих белемен киң татар җәмәгатьчелеге арасында популярлаштыру белән беррәттән, ул, галим буларак, шушы төбәк халыклары тарихын язды. Аның фикерләре күп яктан Ш.Мәрҗани язганнарга аваздаш. «Ата-бабаларыбызның узган тарихы, аларның кайда, ничек яшәүләре турында ватандашларыбызның аз гына күз алдына да китерә алмавы нинди кызганыч хәл. Алар бары тик шәһре Болгар һәм Казан-

дагы изгеләр каберләрен дә, хан мәчетен (Сөембикә манарасын) беләләр. Борынгы заман турында сөйләгәндә «И, бу хан заманында ук булган хәл» диләр, бу вакыйганың бик күптән булуын гына аңлаталар, - дип билгеләп үтә галим[6].

Көнчыгыш тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче академик В.В.Бартольд «Шура» журналын прогрессив юнәлештәге басма дип атый һәм аны чыгаручы Р.Фәхреддинов хезмәтен югары бәяли.

Бу мәкаләдә без «Шура» журналында Көнчыгыш Европа һәм Алтын Урдада монгол чоры тарихы мәсьәләләре яктыртылган мәкаләләргә нигезләнеп, аларда файдаланылган кайбер көнчыгыш тарихи чыганакларга тукталабыз. Мәгълүм ки, XIX гасырда, Рәсәйдә Көнчыгышны өйрәнү фәненә нигез салынган чорда, гомумән, монгол явы тарихын, Алтын Урданың оешуын, дәүләтнең иҗтимагый һәм социаль төзелешен өйрәнүгә аерым бер урын бирелә. Бу юнәлештә кайбер игътибарга лаек эшләр башкарылса да, урыс ориенталистика фәне XIX-XX гасырлар чигендә әле Алтын Урда тарихын гомумиләштергән хезмәт бирә алмый[7]. Андый хезмәтләр бары тик совет чорында гына языла. Әмма XIX гасырда күптөрле фактик материал туплана, оригиналь яңа тарихи чыганаклар фәнни әйләнешкә кертелә.

Татар галимнәренең бу өлкәдәге хезмәтләре еш кына традицион урта гасыр дини трактатлары рухында, Коръән, хәдисләргә ишарәләп язылган. Ләкин шуңа да карамастан, аларны ул заман культурасының бер чагылышы дип бәяләргә кирәк. Ш.Мәрҗани үзенең тарихи хезмәтләрендә урта гасыр көнчыгыш чыганакларына гаять зур әһәмият биргән һәм, нәтиҗәләр ясау өчен, тарихчы чыганаклар белән бик яхшы таныш булырга тиеш, дип санаган. Мәсәлән, «Мөстәфадел-әхбар ...» исемле хезмәтендә ул болай дип яза: «Башка илләрнең галимнәре китаплары эченә кергән, кайбер китаплар һәм язмаларда телгә алынган һәм ата-бабалардан ишетелеп, халык авызында риваять булып сөйләнеп йөргән аерым, таркау хәбәрләр бар. Бу

хәбәрләргә тикшерми-нитми ышанырга ярамаса да, бернинди дәлилсез ялган дип тә хөкем итеп булмас, бәлки замананың хәлләрен, аның маҗараларының нинди икәнлеген белеп, хәлләрнең агышына, замананың теләгенә яраштырып, вакыйгаларның күрсәтүләрен шаһит итеп фикер йөртә белергә кирәк булыр»[8]. Ш.Мәрҗанинең әлеге фикерләре аның хезмәтләрендә ачык чагыла һәм ул тарихчыларны чыганакларга тәнкыйди күзлектән карарга өнди.

XX гасыр башында Р.Фәхреддинов һәм башка галимнәр Ш.Мәрҗани үрнәгендә урта гасыр шәрекъ тарихы традицияләре белән чикләнмичә, Европа тарих фәне ысулларын кабул итәләр, урыс елъязмалары һәм Европа телләрендәге хезмәтләрдән файдалана башлыйлар. Татар халкы тарихының аерым дәверләрен:монгол яуларына кадәрге Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы һ.б. чорларга аерып өйрәнү гадәткә керә. Бер үк вакытта алар, урта гасыр татар тарихи язмаларының күбесе сакланмаганлыктан, көнчыгыш телләрдәге мәгълүматларның никадәр әһәмиятле чыганак булуын яхшы беләләр. Шуның белән бергә галимнәр Ш.Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар...»ында чагылыш тапкан карашларны үзләренә өлге итеп алалар.

XX гасыр башында татар галимнәре арасында Казан татарларының килеп чыгышы мәсьәләсенә берничә төрле караш яшәп килә. Зәки Вәлиди, Һ.Атласи һәм башкалар Казан татарлары турыдан-туры монголларның варислары дигән фикердә торалар[9]. Алар Чыңгыз хан һәм аның варисларына дан җырлыйлар. Без Х.Гыймадиның Ш.Мәрҗанине, Р.Фәхреддинов һәм башка кайбер галимнәрне шушы төркем тарихчылар белән янәшә куюын[10] кабул итә алмыйбыз.

Алдынгы татар галимнәре (шул исәптән Р.Фәхреддинов, Х.Фәезханов) бу теориягә каршы чыгалар, Казан татарларының монгол яулары белән бернинди этник бәйләнеше юк, дип раслыйлар. Алар Казан татарларын Идел буе болгар халкы, аның куәтле дәүләте һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә өйрәнәләр, бу теорияне яңа материаллар һәм фактлар белән баеталар[11].

Болгар дәүләтенең һәлакәтен Р.Фәхреддинов, әлбәттә, XIII гасырда монголларның басып алуында күрә. «Болгар төрекләренең җиңелүе монгол-татар басып алуы белән бәйле. 1236 елда Бату күп санлы гаскәре белән болгар төрекләренә каршы һөҗүм башлый. Болгар төрекләре бәрелешкә әзерләнеп өлгерә алмыйлар һәм тар-мар ителәләр. Шәһре Болгарны татарлар ут төртеп яндыралар, халкын суеп, бөтен йортларын җимерәләр, калган халыкка бик күп ясак салалар, Болгарларны үзләренә буйсынучы дәүләт итәләр. Әгәр болгарлар руслар белән сугышлар алып бару урынына үзара союз төзегән булсалар, татарларны куган булырлар иде», - дип ассызыклый галим[12]. Фикерен дәвам итеп, Р.Фәхреддинов монгол яуларының болгар һәм урыс культурасына тискәре йогынты ясавын билгеләп үтә. «Монгол-татар хакимлеге чорында, - дип яза ул, - өстен катламнан кала бар халык һәммә хокуклардан мәхрүм булган. Ил халкы караңгылыкта, наданлыкта яшәгән. Идарәчеләр бары тик корал көченә генә таянган. Монгол-татарларның нинди дә булса инанган нәрсәсе булмаган: үзләренә файдалы очракта ислам диненә күчкәннәр, башка шартларда исә, үзенә бертөрле (яса) хокукына таянып эш иткәннәр. Алар фәннәргә өйрәнмәгәннәр, тынычлык, иминлек сөймәгәннәр, һөнәрчелек белән кызыксынмаганнар, иген икмәгәннәр. Таш өстенә таш та салмаганнар. Бөтен гомерләрен үзара бәрелештә, берәр табыш хакына дау оештырып үткәргәннәр. Үзләрен һәм үзәкләре Каракорымны бик олыдан күргәннәр. Бу як халыклары Бату явының фаҗигале чорын йөзләрчә еллар буена оныта алмаганнар...»[13]. Әүвәлге мөселман тарихчылары Чыңгыз хан турында кыскача мәгълүматлар биреп, ул хакимлек иткән чорны мөселман халыклар өчен олы фаҗига дип юкка гына атамаганнар.

Чыңгыз хан заманында яшәгән тарихчы Ибне әл-Әсир болай дип язып калдырган: «Хыялга чуму чорлары узып китте. Исламга Чыңгыз хан тарафыннан көтелмәгән афәт килде, көн дә төн дә охшашы булмаган һәлакәт бар

бәндәләрне, аеруча мөселманнарны чолгап алды. Әгәр берәү Аллаһе Тәгалә бәндәне яратканнан бирле шушы көнгәчә дөньяда моңа охшаш хан булганы юк дисә, хаклы булыр. Чыннан да елъязмаларда да андый хәл тасвирланмаган. Аларда язылганнардан иң коточкычы Навуходоносорның Иерусалимда израильлеләрне кыру, җимерү турындагы мәгълүматлар»[14].

«Оставив в стороне арабов и франков, поговорим в этом разделе об османах и русских. У русского народа есть всем известные писатели, среди которых можно упомянуть такие имена: Ломоносов, Державин, Фонвизин, Карамзин, Жуковский, Крылов, Александр Пушкин, Грибоедов, Лермонтов, Гоголь, Гончаров, Тургенев, Лев Тостой. Но и у османов есть не менее достойные люди и это - Синан паша[22], Физули[23], Кучи бек[24], Недим[25], Кани[26], Асым (автор «Окйануса»)[27], Акиф паша[28], Решид паша[29], Фуад паша[30], Пертев паша[31], Шинаси паша[32], Зия паша[33], Сагидулла паша[34], Кемаль Намык[35], Сами бек[36], Ахмед Мидхат[37], Абуль Зия Тауфик[38]. Каждый ребенок, посещающий школу, знает их имена, любит и уважает. Почитая каждого, дети учат наизусть их стихи и в дальнейшем следят за жизнью и творчеством этих писателей и поэтов. Впоследствии благодаря им дети становятся преданными своей нации, отсюда же возникает идея дружбы и единения.

Почему русские и османы любят своих ученых? Ответ на этот вопрос прост: вышеупомянутые личности оставили своему народу, в особенности будущим поколениям, прекрасные произведения и великие мысли.

А наша литература до настоящего времени слишком несовершенна. В школах не изучаются правила родного языка. Мы не написали биографии достойных людей и полные сведения о них остались погребенными вместе с ними. Наша нация не устойчива к невзгодам, но, несмотря на это, мы один из самых высокомерных и многословных народов мира. Вздор и болтовня, звучавшие на меджлисах, могли бы заполнить весь свет и об этом невозможно не печалиться.

Как уже упоминали, деятельность наших предков скрыта от нас в потемках. Вызывает сожаление тот факт, что от них после падения Казанского ханства не сохранилось ни одного произведения, и если даже они сохранились, то до нас не дошли. Если бы до наших дней дошло хотя бы одно правильно описанное событие или биография, изложенные учеными прошлого, то, несомненно, это было бы бесценным подарком для будущих поколений.

Так неужели эта темнота останется в таком же состоянии и распространится в будущем? Или же ученые каждого века должны снова собирать сведения, которые потом останутся в наследство потомкам?! Поиск ответа на этот вопрос падает на плечи достойных людей, а не на тех, кто якобы распространяет благочестие и вносит смуту в среду верующих.

Однако наше бедное сознание понимает: надо прилагать как можно больше усилий, чтобы улучшить отношение к народам, труды которых распространены по всему миру, а также к наукам, книги которых неисчислимы. Дело обстоит таким образом: мир не совершенен и будет неправильным, если народ, не имеющий ни одного произведения, перестанет изучать свою историю и беспокоить-

ся о состоянии дел ученых. Неприлично говорить: «Предки не оставили нам ни одного труда, поэтому и мы вам ничего не оставим». Тому, что предки не оставили нам своих трудов, возможно, есть причины, но это не служит нам оправданием. Мы пожинаем горькие плоды из-за отсутствия великих мыслей наших дедов и если мы будем продолжать так относиться к своему прошлому, то плохи наши дела!

Так же сильно, как пожелаем узнать о своем народе и предках, возможно, и наши потомки будут жаждать узнать о нас.

Отсутствие положительной оценки в этом разделе не может служить нам помехой. Похоронив в могиле недостатки, нельзя добиться хорошего результата. Сколько бы ни было, надо представить все имеющееся.

Как мир не создавался в течение одной минуты, так и все созданное в мире не станет сразу совершенным. Совершенствование идет медленно и понемногу. Недостатки одного будут исправлены другим, ошибки одного времени будут устранены другим временем».

Как видно из вышеизложенного, автор стремился привлечь внимание своих современников, а также будущие поколения к изучению истории. Он исходил из того посыла, что, не зная своего прошлого, трудно думать о будущем. Ученый призывает не обращать внимания на помехи и недостатки в работе, ибо все изъяны будут постепенно исправляться. Но в словах Р.Фахретдинова чувствуется и горечь, когда он говорит, что не сохранились источники, что литература не совершенна. Очевидно, неспроста были упомянуты выдающиеся русские и османские писатели и поэты. Скорее всего, это должно было послужить толчком для пробуждения татарского народа, у которого есть все возможности, чтобы и имена татарских писателей стояли в одном ряду с самыми великими людьми других народов.

Но эти поучительные слова не дошли до народа, для которого они были предназначены. Во-первых, царская Россия чуралась просвещенных «инородцев», к тому же имеющих богатое историческое прошлое и высокую духовную культуру. Во-вторых, в государстве всегда были чиновники типа В.Д.Смирнова, которые, сообразно своим убеждениям, стремились глушить развитие «инородцев» и прикрывали свои амбиции законами и уставами государства, которые давали им полную свободу действий.

ПРИМЕЧАНИЯ

1. Харисов А.И. Коллекция рукописей Р.Фахретдинова в Научном архиве Башкирского филиала АН СССР//Южноуральский археографический сборник. - Уфа, 1973. - Вып.1. - С.270.

2. Госманов М. Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр// Казан утлары. - 1966. - № 7. - С.118-120.

3. Харисов А.И. Там же. - С.270-273; Хәйруллин Ә. Галимнең кулъязма мирасы// Казан утлары. - 1984. - № 1. - С.157-164; Хайруллин А.Н. Рукописное наследие Р.Фахрутдинова как источник изучения истории татарской общественной мысли //Проблема преемственности в татарской общественной мысли. - Казань, 1985. - С.73-84.

4. Шараф А. Воспоминания об отце//Ризаэтдин Фахретдинов. Научно-биографический сборник. - Казань, 1999. - С.119.

5. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. Беренче җөзьә. - Оренбург, 1907. - С.2-4.

6. Открытое письмо Уфимскому горисполкому, татарской молодежи, всем, кто стоит во главе дела //Идель. - 1991. - № 8/9. - С.95.

7. Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. - Казань: Тат.кн-.изд-во, 1974. - С.11.

8. Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. - Казань: Тат.кн.изд-во, 1983. - С.110.

9. Гордлевский В.А. Памяти В.Д.Смирнова //Избранные сочинения: В 4 т. - Москва: изд-во «Наука», 1968. - Т.4. - С.413.

10. Там же. - С.408.

11. Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. - С.132.

12. Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. - С.188.

13. Усманов М.А. Наследие Ризы Фахретдинова// Советская Татария. - 1989. - 14 февраля.

14. Фәхретдин Р. Асар. Беренче жөзьә, 1899 г. - ОРРК НБ им.Н.И.Лобачевского, ед.хр. 1496-Т. - 32 с.

15. Фәтхи А. Ризаэтдин Фәхретдин //Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Беренче бүлек. - Казан, 1960. - Вып.5. - С.39-43.

16. Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. - С.101.

17. Фәхретдин Р. Асар. Беренче җөзьә. - Казан, 1900. - С.5.

18. Устав о цензуре и печати//Мсерианц Р. Законы о печати. - Москва, 1899. - С.65.

19. Там же. - С.67.

20. Там же.

21. Гордлевский В.А. Там же. - С.413.

22. Синан паша (1440 -1486) - известный турецкий прозаик, сын ученого и поэта Назыр бея. Синан паша больше известен прозаическими произведениями, чем поэтическими.Проза написана на темы: религия, мистицизм, нравственность, семья. Писал на арабском и турецком языках (Islam ansiklopedisi [далее Islam...]. Gild 10.- Istanbul, 1966.- с.666-670).

23. Физули (1498 -1556)- родился в городе Кербеле. Был одним из крупных ученых своего времени. Поэтические поизведения писал на фарси, арабском и азербайджанском языках. Вершина творчества - поэма «Лейли и Меджнун». Крупнейший лирик (Большая советская энциклопедия [далее БСЭ], 2-ое изд., т.45. - С.81-82).

24. Кучи бек - ?

25. Недим, Ахмед (? - 1730)- турецкий поэт, один из последних придворных поэтов периода упадка турецкой феодальной литературы. В соей поэзии Недим проповедует философию наслаждения. Стремился преодолеть подражания персидским образцам и писать более простым языком (БСЭ, 2-ое изд., т.29. - С.359.).

26. Кани, Мухаммед Рафик (1885 - ?)- афганский писатель и филолог, собиратель фольклора. Автор первой афганской бытовой повести морально-этического содержания «Два любящих брата» (Краткая литературная энциклопедия [далее КЛЭ], т.3. - Москва, 1966. - С.363).

27. Асым эфенди (1755 - 1820)- языковед, историк и поэт. Родился в Газиантепе. «Окйанус» (*океан* - Б.Л.) - перевод с арабского языка словаря Фирузабади (Turk ansiklopedisi [далее Turk...]. Gilt 3.- Istanbul.- с.448).

28. Акиф паша (1787 - 1845)- турецкий писатель и политический деятель. Министр иностранных дел при Махмуде II. Писал газели, касыды, мерсие, шаркы. Сыграл заметную роль в развитии турецкой литературы (КЛЭ, т.1.- Москва,1962. - С.118).

29. Решид паша (1799 - 1858) - турецкий государственный деятель и дипломат, выразитель интересов феодально-бюрократических кругов. Великий визирь, министр иностранных дел, посол в Англии и Франции (БСЭ, 2-ое изд., т.36.- С.458).

30. Фуад паша - ?

31. Пертев паша, Мехмед Саид (1785 - 1837)- османский министр внутренних дел и поэт. Будучи государственным деятелем, он был и признанным придворным поэтом (Islam ... Gilt 9. - с.554).

32. Шинаси, Ибрахим (1826 - 1871) - турецкий писатель, публицист. Родоначальник новой турецкой литературы. Видный представитель эпохи Танзимата. С именем Шинаси связано появление первого в турецкой литературе драматургического произведения - комедии «Женитьба поэта». Автор одного из первых сборников турецких пословиц и поговорок (КЛЭ, т.8.- Москва,1975.- С.722).

33. Зия паша (1825 - 1881)- турецкий поэт, публицист. Видный представитель литературы эпохи Танзимат. Пропагандист европеизации турецкой литературы, Зия паша стремился придать ей народный характер, ратовал за демократизацию языка (КЛЭ, т.2.- Москва, 1962.- С.123).

34. Сагидулла паша - ?

35. Кемаль Намык (1840 - 1888)- турецкий писатель, публицист, общественный деятель. Крупный представитель Танзимата. Намык Кемаль способствовал становлению и развитию турецкой литературы, выступал за просвещение, обновление турецкого языка. Положил начало турецкому роману (КЛЭ, т.5. - Москва,1968.- С.95).

36. Сами бек, Шемсетдин (1850 - 1904)- турецкий писатель, лексикограф, составитель словарей (БСЭ, 3-е изд., т.29.- Москва, 1978. - С.379).

37. Ахмед Мидхат (1844 - 1913)- турецкий писатель, просветитель. Основоположник короткого рассказа и романа в турецкой литературе. Ахмед Мидхат - автор 80 произведений (КЛЭ, т.1.- Москва,1962. - С.371).

38. Абуль Зия Тауфик - ?

II БҮЛЕК. МӘДӘНИЯТ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ
ГЛАВА II. КУЛЬТУРА И ПРОСВЕЩЕНИЕ

Х.Й.Миңнегулов

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН: ӘДИП ҺӘМ ӘДӘБИЯТЧЫ

I

Ризаэддин Фәхреддиннең эшчәнлеге энциклопедик характерда: ул әдип, тарихчы, дин һәм хокук (фикъһе) белгече, мөфти, педагог, журналист, шәрыкшенас (ориенталист), тюрколог, философ, археограф, тәрҗемәче, библиограф, архивчы, китапханәче һ.б.[1] Бу шәхес безнең алда күптармаклы гыйльми-тикшеренү институты, Академия рәвешендә күзаллана. Аның тикшерү объекты һәм эшчәнлегенең төп адресаты - кеше, кавем, җәмгыять. Инсани башлангыч, инсани эчтәлек бу олуг зат хезмәтләренең, эш-гамәлләренең төп асылын билгели.

Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») исемле мәшһүр китабында (1884) шушындый хикмәтле сүзләр бар: «Әгәр берәүгә гыйлем өйрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне өйрәт, изге гадәтләреңне тот, башкалар күреп гыйлем алсыннар»[2]. Бу яктан Ризаэддин Фәхреддин мөгаллим-остазның классик өлгесе. Шәхси сыйфатлар белән язган, сөйләгәннәрнең табигый ярашуы аның киңәш-теләкләренең, вәгазь-нәсыйх хәтләренең әһәмиятен, бәясен тагын да арттыра, тагын да күтәрә.

Р.Фәхреддин, гомумән, әдипне, язганнары - әдәбиятны хәтерләтә.Чөнки ул һәрчак иҗади, үзенчә фикерли, кешене үзәккә куя, инсанны тәрбияләүне һәм камилләштерүне үзенең асыл максаты итеп саный. Р.Фәхреддин шәхесенең һәм мирасының мондый үзенчәлеге, «әдәби»леге шактый дәрәҗәдә элеккеге традицияләр белән дә бәйле. Чөнки урта гасыр Шәрекъ, шул исәптән татар сүз сәнгатендә, аеруча чәчмә әдәбиятта эстетик, фәнни, дини,

әхлакый, тарихи һәм башка төр башлангычлар еш кына үзара үрелеп, табигый бер синтез рәвешендә бирелгәннәр. «Кәлилә вә Димнә», «Кабуснамә», «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗелфәрадис», «Нәсыйхатес-салихин», «Җәмигъ әт-тәварих», «Тәварихе Болгария», «Рисаләи Газизә» һәм башка бик күп ядкярләр - әнә шундыйлардан. Боларда, әлбәттә, әдәби башлангыч, тел-стильнең чагыштырмача нәфислеге һәм үтемлелеге, фикерләүнең образлылыгы өстенлек итә. Әмма шуңа да карамастан, бу төр ядкярләр бүтән вазифаларны да үти һәм әдәбиятчылар өчен генә түгел, ә кайбер башка инсани фәннәр өчен дә мөһим чыганак, материал булып та хезмәт итә.Р.Фәхреддиннең тарихи, дини, педагогик, фәлсәфи, библиографик китапларында, күп санлы мәкаләләрендә мавыктыргыч стиль үрнәкләрен, җанлы, кызыклы сурәтләрне күпләп очратырга мөмкин. Аның, мәсәлән, татар ханнары турындагы язмалары, мәшһүр ирләр һәм хатыннар сериясендәге хезмәтләре әдәби әсәр, тарихи очерк һәм роман кебек укыла.

Кыскасы, Р.Фәхреддин, гәрчә ул төрле тармакларда эшләсә дә, иң беренче чиратта киң мәгънәдә әдип дип аталырга лаек. Мәгълүм ки, әдип, әдәбият сүзләре әдәп белән бер тамырдан. Р.Фәхреддиннең шәхси сыйфатлары, язган хезмәтләре, кылган гамәлләре барыннан да элек нәкъ әнә шул сүзләргә, язучы, тәрбияче, мөгаллим төшенчәләренә туры килеп тора.

II

Ризаэддин Фәхреддин киң төшенчәле әдип исеменә генә түгел, ә заманча мәгънәле әдип атамасына да лаеклы зат. Ул - ике роман авторы да. Аларның беренчесе - «Сәлимә, яки гыйффәт» (ул «Гафил бине Габдулла» тәхәллүсе белән язылган) - тәүге мәртәбә Казанда 1898 елда басылып чыга (80 б.). Икенчесе - «Әсма, яки гамәл вә җәза» романы - 1903 елда Оренбургта нәшер ителә (130 б.). Боларның башка басмалары да бар (мәсәлән, «Сәлимә...» 1904 елда дөнья күрә). Шунысын да искәртик: совет чорында нәшер ителгән текстларда аерым кыскартулар,

төгәлсезлекләр дә күзгә ташлана. Шуңа күрә һәр ике роман да тулы, гыйльми басмаларын көтә.

Р.Фәхреддиннең һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» әсәрләре, гәрчә аларга госманлы теле йогынтысы көчле булса да, үз вакытында да, хәзер дә яратып укыла, әдипләр һәм галимнәр тарафыннан уңай бәяләнә. Г.Тукай 1912 елда язган хатларының берсендә Р.Фәхреддин хакында болай ди: «Ул «Әсма», «Сәлимә» кебек китаплары белән куәи тәхририясе (язу көче. - Х.М.) вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән ифадәсе ачык, язу тарызы (стиле. - Х.М.) садә вә гүзәл бер язучыдыр»[3]. Мөһаҗирлеккә төшеп, Ерак Шәрекъта гомер кичергән татар зыялысы Хатыйп Халиди «Милли Байрак» гәзитендә басылган бер мәкаләсендә[4] Р.Фәхреддин әсәрләренең тормышчан булуын, «Идел-Урал төрек-татарларының иҗтимагый вә мәдәни хәрәкәтләре кузгалышына баглы» рәвештә «бик матур әдәби тел берлә язылуын», тәрбияви яктан әһәмиятле булуын искәртә. М.Гайнуллин, «Сәлимә...» һәм «Әсма...» әсәрләрен күздә тотып, «татар проза жанрын үстерүдә Р.Фәхреддиновның зур өлеше бар»[5], - дип яза.

Мәгълүм булганча, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбиятында хикәяләүгә корылган күп кенә эпик һәм лиро-эпик әсәрләрне «хикәят» дип йөрткәннәр. Р.Фәхреддин дә, элеккеге традицияләргә тугрылыклы калып, үз язмаларын шушы термин белән атаган. Әмма хәзерге әдәбият фәнендә һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» әсәрләрен роман дип йөртү гадәткә кергән. Чыннан да һәр ике ядкяр дә (аеруча икенчесе) образларның бирелеше, вакыйга - хәлләрнең бәян ителеше, идея эчтәлекләре белән роман исеме белән аталырга лаек.

«Сәлимә...» әсәренең композициясе сәясәт, юл йөрү алымына корылган. Казан мәдрәсәләренең берсендә ун еллап белем алган хәлле генә бер шәкерт егет, дөнья күрү максаты белән, сәфәргә чыга. Пароходта Сәлимә исемле бер гүзәл, акыллы, укымышлы кыз белән таныша. Бу туташ - Тыйһран шәһәрендәге бер мәшһүр сәүдәгәр

кызы. «Сәлимә туташ гади кызлардан дәгел иде, - ди автор. - Бәлки «яшь гомердә тырышканнар картлыкта рәхәт күрерләр» диелгән сүзгә муафыйк лязим тәхсилне (белемне. - Х.М.) вә хаҗәте тәрбияне алмыш иде. Ана деле улган фарсычаны Тыйһранда укып, соңра Мисрыл-Каһирәгә вармыш, анда исә кызлар дарелфөнүнендә (университетында. - Х.М.) биш ел укымыш, гарәп, француз, инглиз делләрене мөкәммәл сурәттә белмеш, кул һөнәрләрене, йорт итмәк вә мәгыйшәт кылмак гыйлемнәренә гүзәл үгрәнмеш...» Әтисе үлгәч, Тыйһранга кайта. Бераздан әнисе белән Петербургка бара. Хәзерге вакытта ватаннарына кайтып барышлары икән. Егет белән кыз аралашып торалар, төрле темаларга әңгәмәләр корыла. Пароход туктаган арада Самарадагы бер танышларына да кереп чыгалар. Танышуларына ике атналап вакыт үткәч, егет белән кыз Баку шәһәрендә гаилә корып та җибәрәләр.

«Сәлимә...» әсәре билгеле бер дәрәҗәдә сәяхәтнамә жанрын да хәтерләтә. Анда сәфәргә мөнәсәбәтле шәһәркалалар (Казан, Болгар, Самара, Баку...), географик һәм этник төшенчәләр (төрки кавемнәр, Итил...) хакында мәгълүматлар, тарихи-этнографик белешмәләр бирелә. Әмма юлъязмалардан үзгә буларак, биредә төп сюжет шактый дәрәҗәдә уйланма, хикәяләүче (сәяхәт кылучы) «мин» белән автор язмышы туры килми. Мәгълүм ки, Р.Фәхреддин Казанда бөтенләй укымаган, Иран кызы белән гаилә дә кормаган. Авторның үзен Гафил бине Габдулла дип тәкъдим итүе, «хикәят»нең чынлыгына кат-кат басым ясавы да реалистик әдәбиятның тернәкләнүе, хосусияте, үсеше белән бәйләнешле сәнгати чаралар.

«Сәлимә...» романында әле уй-фикерләрне вакыйгалар, конфликтлы вәзгыять, сурәтләү аша гәүдәләндерү йомшаграк. Анда авторның турыдан-туры сөйләве, мәгълүмат бирүе өстенлек итә. Шуның нәтиҗәсендә әсәрнең эчке динамикасы, мавыктыру көче кими. «Әсма...» романында исә бу сәнгати кимчелек шактый дәрәҗәдә бетерелә. Биредә сюжет катлаулана, каршылыклар көчәйтелә төшә. Каһарман-

нар язмышы белән бәйләнешле эчке конфликт әсәрнең бөтенлеген, композицион яктан чагыштырмача төзеклеген тәэмин итә. Персонажларны индивидуальләштерү дә камилләшә төшкән. Исем алыштыру, «үлгән» дигән кешенең «кабат терелүе» әсәргә маҗаралылык төсмере дә өсти.

«Әсма...» романы «базары», «почтасы», «сәүдәгәрләре» булган зур гына бер авылда имамлык вазифаларын башкаручы Габбас гаиләсен тасвирлау белән башланып китә. Гайшә абыстай ирен, кызын тәрбияләүгә күп көч түгә. Авылның Хикмәт хаҗи дигән кешесе бу гаиләгә үчлек тота, йорт хуҗасына төрле ялалар яга. Хаҗ сәфәреннән Габбас мелланың «үлем хәбәре» килгәч, озакламый хатыны Гайшә дә күзләрен йома. «Унынчы яшенә чыккан» Әсма тәмам ятим кала. Аның өчен газаплы көннәр башлана: төрле кешеләрдә тору, теләнчелек, хастаханә... Әмма кыз (ул бу вакытта Зәйнәп исеме белән йөртелә) үзенең тәрбиялелеге, тырышлыгы аркасында, хәят корбанына әйләнми, алга бара, тәрбияханәгә эләгә, анда белем, һөнәр туплый һәм шул уку йортында мөгаллимә булып эшли башлый. Әсманың зирәклеге, уңганлыгы, матурлыгы күпләрне сокландыра. Ул үсмер чагында ук танышкан егетенә кияүгә чыга. Әтисенең дә исәнлеге ачыклана. Әсмага, аның ата-анасына начарлык, хөсетлек кылучылар исә төрле җәзаларга дучар була: комсыз Хикмәт хаҗи ачлыкта, фәкыйрьлектә үлә; йөзәрләгән хатын-кызларның аһ-зары мәкерле Зәйнүш абыстайга да төшә... Татар әдәбиятында элек-электән эшкәртелгән «ни чәчсәң - шуны урырсың», «һәр гамәл өчен тиешле рәхмәтен яки җәзасын алырсың» мотивлары биредә янә бер конкрет гәүдәләнеш таба. «Никадәр орлык сачмыш исә, җөмләсене үзе урды вә кешегә хәзерләмеш чокырларга кәндесе төште», - дип автор моны үзе дә искәртеп куя.

Р.Фәхреддиннең һәр ике романы да, гәрчә аларның сюжетлары, каһарманнары, төзелешләре үзгә булса да, идея-проблематикалары, персонажларга салынган мәгънәви йөкләмәләре белән үзара шактый якын, охшаш.

Мәгълүм булганча, Урта гасыр сүз сәнгатен еш кына әхлакый әдәбият дип йөртәләр. Белем төшенчәсе белән дә тыгыз бәйләнешле бу сыйфат XIX йөздә үзенең әһәмиятен тагын да арттыра. (Аңа карата фәндә «мәгърифәтчелек» атамасын куллану гадәткә кергән). К.Насыйри, Г.Чокрый, М.Акмулла... язмалары - моның ачык мисалы. Шунысы мөһим: XIX гасырның соңгы чирегендә әхлак, белем – мәгърифәт, милләт мәсьәләләре шактый тормышчан образлар, вакыйгалар ярдәмендә, чынбарлыкка тапкыр шәкелләрдә гәүдәләндерелә башлый. Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Габдрахман Ильяси нигез салган бу хәрәкәткә Р.Фәхреддин дә килеп кушыла. Аның романнары милли хәят, тарихи чынбарлык белән тыгыз бәйле. Сюжет-вакыйгаларның конкрет төбәкләргә, билгеле бер вакыт аралыгына нисбәт ителүе дә - авторның реализмга хәерхаһлыгын күрсәтүче аяклы дәлил.

Р.Фәхреддинне барыннан да элек инсан һәм халык язмышы борчый. Бөтен җанын, барлыгын биләгән бу проблеманы ул төрле яктан, төрле аспектларда гәүдәләндерергә омтыла. Автор фикеренчә, милләтнең ниндилеге, аның тәрәкъкыяте, иң беренче чиратта, хатын-кызга бәйле. Игътибар итегез: һәр ике әсәр дә хатын-кыз исеме белән аталган, һәр ике романның да төп каһарманнары - хатын-кызлар. Бу - юкка гына түгел, ә автор инанычының мантыйкый гәүдәләнеше. Сәлимә - кечкенәдән үк белем, тәрбия алган зат. Тормышын да ул көйли белә. Бу гүзәл, гыйффәтле инсаннан үзгәләргә, тирә-юньдәгеләргә нур, игелеклелек бөркелеп тора. Бөтенләй үзгә шартларда үсеп җиткән Әсма да Сәлимә образы белән каршылыкка керми. Чөнки аның өчен дә тәрбиялелек, белем, һөнәрне өстен күрү, гыйффәтлелек хас. Әсманың мөгаллимә булып эшләве дә символик. Автор карашынча, милләтнең киләчәге - бүгенге хатын-кызлар, мөгаллимәләр кулында.

Һәр ике роман да төп каһарманнарның үзләре яраткан, үзләренә рухи һәм фикри яктан тиң булган кешеләргә кияүгә чыгулары белән тәмамлана. Р.Фәхреддин мәхәббәткә,

хөрмәт-ихтирамга, үзара җаваплылыкка корылган гаилә тормышын, андагы инсани тәрбияне милләт яшәешенең нигезе, төп шарты дип саный. Автор фикеренчә, «ирләрнең һиммәте (тырышлыгы; дәрте. - Х.М.) урыннарыннан тауларны күчерер, диерләр. Ләкин хатыннарның һиммәте боннан дәхи бәләндтер (артыктыр. - Х.М.)». «...Гаилә, - ди ул, икенче бер урында - кечкенә бер дәүләт кебидер». Андагы тәртип һәм тәрбия - «җөмләсе гаилә башлыгы улган хатын вазифасыдыр». Биредә иң төп таләпләрнең берсе - балаларга кечкенәдән үк тиешле белем һәм тәрбия бирү. «Инсанның яшьлегендә алмыш тәрбиясе та каберенә кадәр берлектә улыр, аерылмас», - диелә «Әсма...» романында.

Автор кешеләрне һәм, гомумән, кавемне ислам дине рухында, моңа кадәр тупланган инсан һәм әхлакый тәҗрибә-казанышлар нигезендә тәрбияләүне яклый. Шуның белән бергә Р.Фәхреддин - заманчалык тарафдары да. Аның әсәрләрендә Шәрекъ һәм Гареб телләрен өйрәнүнең, фән-техника казанышларын белүнең зарурилыгы, чынбарлыкка тапкыр килерлек фикерләү һәм хәрәкәт яклана. Автор болай ди: «Бер милләт вә кавемнең тәрәккыйсы укымак, һөнәр вә санагать белмәккә мәүкуфтыр (бәйледер - Х.М.). ...Бабаларымыз гакыл яшьтә улмаз, башта улыр димешләр. Русча, төркичә җөмләңез (барыгыз - Х.М.) яхшы белдекеңез кеби, араңызда аз улса да француз, немец, гарәп, фарсы делләрене белүчеләр һәм вардыр. Бу делләрне белмәк олуг сәрмаядыр (байлыктыр. - Х.М.). Бу делләр сәбәбеннән кәрәк Россиядә, кәрәк Европада вә Америкада, кәрәк Иран, Әфган, Һинд тарафларында сәүдә итмәк мөмкин улачактыр».

Р.Фәхреддин үзенең әдәби әсәрләрендә һәм башка төр язмаларында дини наданлыкны, тәгассыбны (фанатизмны) кискен тәнкыйтьли, дин исеме белән нәфесен, шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгыртучыларны фаш итә. Шуның белән бергә бөек мәгърифәтче ислам диненә ихлас ышана, аның сафлыгын, тәрбияви процесстагы олуг вазифасын сакларга омтыла.

Әйткәнебезчә, совет чоры басмаларында Р.Фәхреддин романнары теге яки бу дәрәҗәдә кыскартып басылды. Мәсәлән, мин «Сәлимә...» романының 1898 елгы басмасын «Татар мәгърифәтчелек әдәбиятында» (Казан, 1979) бирелгән текст белән чагыштырдым. Бер гыйбрәтле нәрсә ачыкланды: баксаң, кыскартуларның күпчелеге динне мактаган, аңа уңай мөнәсәбәт белдергән өлешләргә карый икән. Тәүге басмада, мәсәлән, мондый юллар бар: «Мөселманларга хезмәт итмәк өчен иң элек ислам гыйлеме илә белеш вә шәригать кагыйдәләре илә ашна (таныш. - Х.М.) улмак тиешледер. Буйлә (мондый. - Х.М.) улмаганда мөселманлар инабәт итмәзләр (ышанмаслар. - Х.М.)... Үз динене, үз делеңне, үз гореф-гадәтене белмәгән кемсәнәгә ялгыз әһле ислам дәгел, һичбер кавем игътибар әйләмәз (ышанмас - Х.М.)...» (24 б.). Кызганыч ки, бу мөһим фикерләр 1979 елгы басмада күзгә ташланмый.

Һәм «Сәлимә...», һәм «Әсма...» романнарында автор башлангычы гаять көчле. Ул үзенең уй-кичерешләрен, теге яки бу күренешкә мөнәсәбәтен турыдан-туры да, каһарманнарның эш-гамәлләре, сөйләмнәре аркылы да нык сиздереп тора. Чөнки әдәби иҗат аның өчен бер мөһим мөнбәр, үтемле чара. 1917 елда язылган бер мәкаләсендә[6] Р.Фәхреддин болай ди: «Сәлимә...» берлә «Әсма...» - минем яшь вакытларымның ядкярләре һәм дә эчемдәге зар-моңнарымны вә хәсрәт-кайгыларымны уртаклашкан сердәшләремдер...»[7]. Инде менә XX гасыр буена бу ике роман - киң катлам укучыларның да күңел сердәше. Чөнки аларда тормыш тәҗрибәсе, инсани әхлак казанышлары, кеше психологиясенең аерым яклары гәүдәләнеш тапкан. «Сәлимә...» һәм «Әсма...» әсәрләре, тәрбияви яктан тыш, әдәбиятыбызның реалистик нигездә үсешенә, роман жанрының камилләшүенә дә билгеле бер өлеш кертте.

III

Ризаэддин Фәхреддин - сәнгати әсәрләр иҗат иткән әдип кенә түгел, ә әдәбиятны өйрәнгән, тикшергән галим дә. Аның әдәбиятчы булуы бу мөхтәрәм затның бөтен

эшчәнлегендә, әдәби һәм гыйльми китапларында, публицистик язмаларында, «Шура» журналындагы сәхифәләрендә ачык күренә. Ул сүз сәнгатенең текстологы да, тарихчысы һәм теоретигы да, методисты һәм библиографы да, әдәби багланышларны тикшерүче дә... Бу зат - гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларның олуг белгече дә... Р.Фәхреддин - әдәбият фәненең төрле тармакларында үз сүзен әйткән, билгеле бер эз калдырган галим. Аларның һәрберсе махсус һәм җентекле тикшеренүләргә мохтаҗ. Биредә исә без гомуми күзаллау тудыруны гына максат итеп куябыз.

Камил кеше тәрбияләү - Р.Фәхреддин эшчәнлегенең асылы, арка сөяге. «Инсан улмак өчен, - ди ул, - гыйлем илә күркәм холык кирәктер. Һәм дә бонларны берберләреннән аермак дөрест улмаз». Әдип фикеренчә, күркәм, гүзәл холык ул «әдәп, гыйффәт, сабыр, тәхәммелдән (түзүдән - Х.М.) гыйбарәттер...» Камил инсан тәрбияләүдә Р.Фәхреддин сүз сәнгатенә төп авырлык төшүен искәртә. «Әдәбият илә иштигаль (шөгыльләнү; мавыгу - Х.М.), дип яза ул «Әсма...» романында, - күңелне сафламак вә нәфсене тәрбия итмәк бабында иң әсәрле улган дәвадыр». Икенче бер урында автор: «...Гарәпләрнең вәзенле көйләреннән әсәрләнеп, дәвәләр ашыгып-ашыгып китәрләр», - ди.Сүз сәнгатенең кеше тормышында, тәрбияви процесста биниһая көчкә ия булуын тирәнтен аңлап, Р.Фәхреддин элеккечә әдәби ядкярләрне туплауга, кирәк икән, текстологик эшкәртүгә, халыкка җиткерүгә җитди игътибар итә. Ул XVIII йөзгә мөнәсәбәтле «Исмәгыйль сәяхәте»н 1903 елда тиешле шәрех-аңлатмалар белән бастырып чыгара. Ш.Мәрҗани хаҗнамәсенең дөнья күрүе дә Р.Фәхреддин эшчәнлеге белән бәйле. Бу мөхтәрәм зат Ш.Зәки, Акмулла һәм күп кенә башка шагыйрьләрнең әсәрләрен дә укучыларга ирештерүгә зур өлеш кертте.

Р.Фәхреддин үз чоры рухи тормышының, әдәби процессының үзәгендә кайнады, аның катнашы, игелекле сүзе, таләпчәнлеге белән күп кенә кешеләр әдәбият юлына кереп китте. Ул мөхәррирлек иткән «Шура» журналы-

ның тәүге санында шушындый юллар бар: «Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итмәк хакында мөшавәрәт (киңәш - Х.М.) мәҗлесе улачакдыр». Чыннан да журнал үзенең мәсләгенә тугрылыклы калды. Аның һәр саны сүз сәнгатенең, төрле-төрле фикер-карашлар көрәшенең бер мөнбәре булды. Менә мин аның 1908 елгы саннарын гына актарам. Никадәр хәзинә, никадәр байлык! Һәр санда диярлек Дәрдемәнд шигырьләре басылган. Шунысы кызыклы: бередәге текстларда аерым үзгәлекләр дә күзгә ташлана. Мәсәлән, «Караб» шигырендәге «җилкәнен», «дулкын» сүзләре журналда «йилкәнен», «тулкын» рәвешендә басылган (1-нче сан. - 31б.). «Шура»да әдәби, гыйльми яңалыклар даими рәвештә бирелеп бара. 5-нче санда, мәсәлән, Заһир Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәре басылуы хәбәр ителә, аның авторы һәм китабы хакында фикерләр әйтелә (148-149 б.). Яшьли үлсә дә, - «Заһир әфәнде хакыйкать хальдә бәхтиярдер, әсәр укылырга вә һәр тарафда нәшер иделенергә лаек...».

Шушы ук 1908 елгы саннарда урыс, госманлы, гарәп, Европа әдәбиятлары хакында җитди эчтәлекле, күләмле язмалар бар. 18-нче санда мәшһүр «Котадгу белек» (1069) нөсхәләре хакында белешмә бирелә (575 б.). 21-нче санда «Кыйссаи Йосыф» дастанының «назмы гаять тә мәүзүн (төзек - Х.М.), лөгате ачык вә фәсыйх (килешле; ятышлы - Х.М.) улыб, өслүбе (стиле - Х.М.) һәм мәргуб (сыйфатлы, затлы - Х.М.) вә әсәрле» булуы искәртелгән (673 б.). Шушында ук моңа кадәр аерым китап рәвешендә басылган 34 әдәби әсәрнең исемлеге урнаштырылган (673-674 б.). Журналның тәүге саннарында Сократ, Ибне Фазлан, Әл-Мәгарри, Физули, Л.Толстой, Пушкин, Гаспралы, Й.Акчура, Ф.Кәрими һәм башка күренекле затларга мөнәсәбәтле язмалар бар. «Шура» 1908 елда 24 сан чыккан. Барлыгы - 784 бит. Ә бит ул 10 ел буена нәшер ителеп килгән. Аларда тәүге елның тәҗрибәсе, традицияләре тагын да баетылган, үстерелгән. Ризаэддин Фәхреддиннең тормышын, иҗат мирасын өйрәнүгә

һәм пропагандалауга гаять зур өлеш керткән Мәдинә апа Рәхимкулова исәпләвенчә, баш мөхәррир «Шура»да үзе 312 мәкалә бастырган[8]. Бу санга әле төрле белешмә-мәгълүматлар, кечерәк рецензияләр керми. Журналда басылган 4 меңнән артык мәкалә-публицикациянең дә бит күпчелеге Р.Фәхреддин кулы, зиһене аша уза. Аларның зур өлеше әдәбият һәм сәнгать турында, яисә сүз сәнгате белән бәйләнешле. «Шура» журналында әдәбият мәсьәләләре» темасына яшь галим Раиф Мәрданов академик Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә бай эчтәлекле кандидатлык диссертациясе язды. Шәт, аның бу хезмәте аерым китап рәвешендә дә дөнья күрердер.

«Шура» - иң беренче чиратта, Ризаэддин Фәхреддин журналы. Чөнки ул - аның баш мөхәррире, төп авторы, оештыручысы, кыскасы, анасы һәм атасы да. 1928-1939 елларда Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналында да без шундый ук хәлне күрәбез. Аны да шуңа күрә еш кына Гаяз Исхакый журналы дип йөртәләр. Һәр ике журнал татар рухи тормышының мәркәзе, үзенә күрә бер штабы булдылар.

Р.Фәхреддиннең әдәбият фәнен яңа чыганаклар белән баетуда, әйткәнебезчә, роле гаять зур. Әмма ул әдәби ядкярләр, факт-мәгълүматларны эзләү, эшкәртү, бастыру белән генә чикләнмәде, алар нигезендә үзе дә җитди мәкаләләр, хезмәтләр тудырды. Аның «Шура» журналында, күптомлык «Асар»да басылган материаллары элекке әдип-галимнәребезнең тормыш юлларын һәм иҗатларын өйрәнүдә бәһаләп бетергесез чыганак. Шунысын да искәртик: ниһаять, XX гасырның соңгы елында «Татар энциклопедик сүзлеге» дөнья күрде (Кызганыч ки, анысы да урыс телендә). Ә бит бу изге эшнең нигезе Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин тарафыннан салынган. Галимнең басма һәм кулъязма хәлендәге «Асар» томнарын тулы килеш хәзерге укучыларга җиткерергә иде.

Ризаэддин Фәхреддин - җиһан әдәбиятының, иң беренче чиратта Шәрекъ сүз сәнгатенең бөек затларын өйрәнүгә,

аларның әсәрләрен халыкка җиткерүгә зур өлеш керткән галим дә. Мондый шәхесләр арасында әл-Мөкәффәгъ, Ибне Сина, Сәгъди, Хафиз, Нәваи һәм башка бик күп мәшһүр исемнәр бар. 1917 елда XIV йөз сәяхәтчесе Ибне Баттутаның Алтын Урдага сәфәре хакында язмасын тәрҗемә итеп бастыра. Р.Фәхреддиннең әл-Мәгарри, Имам Газали, Ибне Гарәби, Ибне Рөшд, Әхмәд Мидхәд һәм башка классик әдип-галимнәр хакында махсус монографияләре дә бар.

Бу төр язмалар өчен гыйльми тирәнлек, факт-мәгълүматларга муллык, комплекслылык, инсанилык, тугрылык хас. Үзенең тикшерү ысулын аңлатып, Р.Фәхреддин «Әбүл Галя әл-Мәгарри» монографиясенең (Оренбург, 1908) «Хатимә» өлешендә болай яза: «Бән бер кемсәнең тәрҗемәи халене үгрәнмәк эстәдекем вакыт, шу(л) адәмнең хосусый әхвалендән башка, гаиләсене, тәрбия алмыш адәмләрене, йөрмеш йирләрене, сохбәт итдеке әкъран вә әмсалене (якыннарын һәм чордашларын - Х.М.), хәтта ки гасырыны һәм берлекдә үгрәнәм. Бу шәй (әйбер; нәрсә - Х.М.) бәндә гадәтдер. Бу шәйләрдән мөҗәррәд (ялгыз - Х.М.) уларак (аерылып - Х.М.) язылмыш тәрҗемәләрең (биографияләрнең - Х.М.) сахибләрене (ияләрен - Х.М.) сахра уртасында үсмеш бер агач кеби күрдекем сәбәбендән, алар хакында бер хөкем чыгара белмәкдән гаҗизем. Бәнем өчен бер агачның юанлыгы, нечкәлеге, озынлыгы вә кыскалыгы, төзеклеге вә кәкрелеге илә хөкем итмәк өчен, мотлакан күб агачлар арасында улынырга вә шунлара (шуларга - Х.М.) кыяс иделенергә (чагыштырылырга - Х.М.) мәүкуфдыр («тиештер» - Х.М.)... Бән мөмкин кадәр тугры язарга сәгый итдем (тырыштым - Х.М.)» (69-70 б.). Бу - декларатив юллар гына түгел, ә мөхтәрәм галимнең һәр язмасында, бөтен эшчәнлегендә кулланылган методология, иман-ышаныч.

Р.Фәхреддиннең шәрыкшенаслык (ориенталистика), тюркология буенча хезмәтләре Төркиядә, Үзбәкстанда, Әфганыстан һәм кайбер башка илләрдә хәзер дә бик теләп кулланылалар, аларның абруе, фәнни ышанычлылык дәрәҗәсе югары.

Ризаэддин Фәхреддиннең әдәби мирасы, сүз сәнгате белән бәйле хезмәтләре - татар әдәбиятының һәм фәненең кыйммәтле сәхифәләре. Аларда олуг затның йөрәк тибеше, дөнья, тормыш турында уйланулары, тарихка, киләчәккә карашлары. Бу язмалар өчен бөек инсанилык, күркәм әхлаклылык, фидакяр милләтпәрвәрлек хас. Күренекле милләтәшебез Рәшит Рәхмәти Арат («Казанлы») 1936 елның 17 маенда Анкарадан язган мәрсияи мәкаләсендә болай ди: Р. Фәхреддин «безнең өчен үлмәс үлемнең бередер. Үзен мәңге яшәтәчәк эзләр калдырмышдыр...»[9]. Әйе, бу мөхтәрәм зат, үзе күптән үлсә дә, безнең арабызда замандашыбыз, остазыбыз, киңәшчебез рәвешендә яшәвен дәвам итә... «Инсаннар, - ди ул, - тормыш юлында туктап торыр өчен килмәгәннәр, әмма һәмишә (һәрчак - Х.М.) алга барырга, югары үрмәләргә омтылырга килгәннәр». Ризаэддин Фәхреддиннең шәхесе, гыйбрәтле эшчәнлеге, бай мирасы безне тәрәкъкыятькә этәрә, хәтеребезне баета, иманыбызны ныгыта, милләткә хезмәт юлында дәрт вә илһам, көч вә куәт биреп тора.

ИСКӘРМӘЛӘР.

1. Бу олуг затның шәхесе, күпкырлы эшчәнлеге, әдәби иҗаты хакында Әлмәт шәһәрендә уздырылган ике гыйльми-гамәли конференциядә (22 январь, 16 апрель 1999 ел), Татарстан радиосы аша (январь 1999 ел) һәм «Ватаным Татарстан» гәзитендә («Милли каһарманнарыбыз: Р.Фәхреддиннең тууына 140 ел тулу уңаеннан» - 21 январь 1999 ел), «Татарстан» журналында («Буй җитмәс шәхес: Ризаэддин Фәхреддин турында уйланулар» - 1999. - № 5. - 55-57 б.) инде безгә чыгышлар ясарга туры килгән иде. Биредә исә аларны бик кабатламаска тырышып, кайбер фикерләр әйтү белән генә чикләнербез.

2. Мирас. - 1995. - № 4. - 38 б.
3. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. - Казан:Таткитнәшр., 1977, IV т. - 324 б.
4. Милли Байрак. - 1936. - № 30.
5. Татар әдәбияты тарихы. - Казан: Таткитнәшр., 1985, II том. - 322 б.
6. Шура. - 1917. - № 23/24 - 540 б.
7. Өзек «Татар әдәбияты тарихы»ның II нче томыннан алынды. - 329 б.
8. Ризаэддин бин Фәхреддин. Юбилей чыгарылышы: Тууына 140 ел тулу мөнәсәбәте белән. - Оренбург: Пресса, 1998. - 250 б.
9. Яңа милли юл. - 1939. - № 7/8. - 26 б.

Мәсгуд Гайнетдин

РИЗА ФӘХРЕДДИНОВ - ПУБЛИЦИСТ

Иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен игътибар үзәгенә кую Р.Фәхреддин иҗатының беренче адымнарыннан ук билгеләнә. Шәкертлек көннәрендә язылып, 1888 елда басмадан төшкән «Китабел-игътибар» әсәрендә үк инде кайнар сәяси-иҗтимагый көрәш гөрелтеләре яңгырый. Биредә яшь автор халыкның мәгариф системасын тамырдан яңарту проекты белән чыга.

Р.Фәхреддиндә үткен публицист фикере формалаштыруда 1883 елда Кырымда чыга башлаган татарча «Тәрҗеман» гәзитенең өлеше зур. Соңрак ул үзе дә, бу гәзиткә кыска хәбәрләр юллап, журналистлык каләмен чарлый. Ул 1903-1904 елларда Тифлистә әзәрбайҗанча нәшер ителгән «Шәркы Рус» гәзитендә дә актив язышa. Бу гәзиттә, күп саннарга бүлеп, аның хәтта «Ибне Рөшд» - «Аверроэс» - дигән китабын бастырганнар. Күрәсең, әдип үзен гәзит-журнал сугышчысы - журналист дип хис итә. 1906 елның 21 февралендә Оренбургта «Вакыт» гәзите чыга башлагач, үзенең Диния Нәзарәтендәге казыйлык хезмәтеннән баш тартып, ул шул гәзиткә хезмәткә күчәргә карар кыла. «Вакыт» ның 22 санында (6.5.1906) аның казыйлыктан китәргә җыенуы, № 24 тә (11.5.1906) инде эшеннән китүе хәбәр ителә. № 25 (14.5.1906) аның «Вакыт»ка эшкә киләчәген яза. Шул май аенда ук ул Оренбургка күчеп килә, «Вакыт»ның үз хәбәрчесе булып эшли башлый, мәкаләләрен «Ризаэддин», «Ризаэддин Фәхреддин», «Р.», «Морад», «Мөслим» имзалары белән бастыра.

1908 елның 10 январеннан, «Вакыт» кебек үк, Рәмиевләр акчасына Оренбургта «Шура» («Киңәш») исемле әдәби журнал чыгарыла башлый. Журналга редактор итеп Р.Фәхреддинне билгелиләр. Ун ел шушы журналны җитәкләп, Риза хәзрәт анда Алып батыр гына йөкли алырлык публицист һәм журналистлык хезмәтен башкара. Бүген инде аның язган китапларын, мәкаләләрен, журналга,

әдәбиятка, җәмгыятькә күрсәткән хезмәтләрен барлау, күз алдына китерү хәтта мөмкин булмаган бер нәрсә булып күренә. Безнең татар мәдәниятенә, дөресрәге, мәдәниятсезлегенә хас рәвешчә, аның публицистик эшчәнлеге бөтенләй өйрәнелмәгән, яктыртылмаган, хәтта барланмаган хәлдә кала. Кызганыч, бүген ул эшне йөкли алырлык куәт тә, сәләт тә инде татарда калмаганга, бөтенләй юкка чыкканга охшый. Өйрәнүне сорамаган, «Риза казый», «Риза хәзрәт» дигән исеменә, бер-ике китабы атамасына, ун-унике ел мөфти булып эшләвенә карап кына, бу тиңдәшсез журналист, ялкынлы публицистыбызны күренекле руханиларыбыз, дини реформаторларыбыз исемлегенә генә кертеп йөртәләр. (Дөрес, ул анда да күренекле урын тота). Публицистикабыз тарихы өлкәсендә безнең бар белемебез күп еллар Г.Тукай мирасыннан гыйбарәт булды һәм шул Г.Тукай мирасы белән чикләнде, 50 нче елларның икенче яртысыннан башлап, аңа акрынлап Г.Ибраһимов мирасы өстәлде. Тулылана барган Г.Тукай белән алар безнең көннәрдә инде охшашы күренү ихтималы һәм мөмкинлеге югалган (юкка чыгарылган) ниндидер могҗиза, хыялый әкият дөньясы булып күренә иде. Соңгы елларда аларга Г.Исхакый кушыла башлады. (Болар да Г.Тукайда булган төгәлеккә якынлаша алсалар икән?! Аһ, татлы хыял...). Ә бит ул чор публицистикасында Габдерәшит Ибраһимов, Ф.Кәрими, Р.Фәхреддиннәрнең бу өлкәдәге олы нәтиҗәле хезмәтләре, күләме-колачы белән дә, дөрләүле-ялкынлы кайнарлык-яктылыклары, казанышлары белән дә Г.Исхакыйлар - Г.Тукайлар эшчәнлеге төреннән. Шул ук затлылык, ихласлылык-йөкләмәлелек, эчтәлеклелек. Ә бит ул чорның публицистика классикасы бу исемнәр белән генә чикләнми. Сәйдәшевләр гәзитен («Бәянелхак»ны) кемнең өйрәнгәне бар? Җ.Вәлиди, Б.Шәрәф, Г.Баттал, Һ.Атласи, М.Бигиев, Һади һәм Садри Максудилар, тиңдәше аз Й.Акчура... тагын бик күп шундый талантлы гәзитчеләрнең, кайсын гына алсаң да, үзләренең дә, милләтебезнең һәм мәдәниятебезнең дә йөз аклыгы булырлык хезмәтлә-

реннән нәрсәне беләбез? Белемсезлегебезне-хәбәрсезлегебезне сакларга гына өйрәтелгән, күндерелгән халык инде без. Чын белем тузанын арттыруга да аяк терәп каршы торабыз кебек. Һәрхәлдә шул нәрсә бездә өстенлек итә. Аның каравы компетентлы булмаган - әһеле түгел кешеләргә «төтен җибәреп» («шулерлык» белән) яшәүгә зур мөмкинлекләр ачыла. (Ә менә үзләре өчен шул мөмкинлекләрне саклауда алар кимчелек күрсәтмиләр!). Менә тулы сигез дистә ел милли йөзебезне, милли менталитетыбызны гына түгел, гомумән, кешелек, әхлакый-иҗтимагый сыйфатларыбызны юкка чыгара, генофондыбызны җимерә торган гүя шул үләт базына ташланган хәлдә яшибез. Шуңа күрә мондый бозыклыклар исеме хәтта янәшә куелырга ярамаган кеше турында сөйләгәндә, «авыз тәмен бозмыйк», дип торып булмый, әлеге хәвефле хәлебезне телгә алып, шул әрнүләребез хакында да чаң сугарга туры килә. Кайтыйк асыл максатыбызга.

Миңа Риза хәзрәт публицистикасы белән кызыксынып, аны күпмедер өйрәнергә туры килмәде. Аны белмәвем башкалар белән бер дәрәҗәдә диярлек икәнен генә икърар итә алам. Очраклы рәвештә күземә чалынган ике-өч мәкаләсе мәдәниятебез тарихында башка табылмаган-кабатланмаган эшләнешләре, тирәнлекләре-үткенлекләре белән чын мәгънәсендә мине тетрәндерде. XX йөз башында Диния Нәзарәтенең яшь казыйлары иҗтимагый хәрәкәттә актив катнаша. Мәдрәсә тәмамлап Нәзарәткә имтиханга килгән тирән белемле актив шәкертләрне алар Көнчыгыш Себер, Ерак Көнчыгыш төбәкләрендәге татар ислам җәмәгатьләренә имам (мулла) булып китәргә үгетли. Шуннан соң да Риза хәзрәт андый имамнар белән хат язышып, хәбәрләшеп тора. Иң кызыклы шундый хатлардан 1905 елга ул бер җыентык әзерли. 1905 елның 2 сентябрендә Петербургта Идел буе татарлары телендә «Нур» исемле беренче гәзитә чыга башлагач, бу басманы чыгарышуга ярдәм итү йөзеннән, ул әлеге җыентыгын «Нур» редакторы Гатаулла хәзрәт Баязитовка тапшыра. «Нур»ның баштагы саннарын-

да ул хатларның кайберләре басылып та чыга. Инде Оренбургта «Вакыт» гәзите чыга башлагач, аның беренче һәм алтынчы апрель (1906) саннарында Риза хәзрәт шундый ике хаттан татар диаспораларының аяныч хәлләрен чагылдырган өзекләр китерә. Шулар эчендә илдәге хәлләргә үзенең мөнәсәбәтен белдергән, әһәмиятен һәм кайнарлыгын бүген дә әле аз гына да җуймаган хөкемнәрен урнаштыра. Хатлардагы фактлардан әрнеп, галим царизмның милли сәясәттәге тупаслыкларын һәм мәгънәсезлекләрен фаш итә. Мондагы кайнарлык, тапкырлык, сәяси фикер үткенлеге бу вакытта әле (һәм, гомумән, соңыннан да, бу планда) башка бер татар авторында да күренми.

«Вакыт»тагы мәкаләсендә Риза казый, аерым алганда, болай дип яза: «Руслар арасында галим һәм мөхәррир исеме алган күп адәмнәр үз ватандашлары саналган, бу ил өчен ничә йөз ел малларын, җаннарын аямаган мөселманнарның дине, лисаны (теле), гореф-гадәтенә тыкшыналар. «Өстән караганда, ялтыравыклы күренгән, хакыйкатьтә, бер типкәндә авып китәрлек дәрәҗәдә нигезе черегән бюрократия идарәсе каршында» шулар ватанга файдалы кешеләр саналалар. Рус телендәге яңа фәннәр һәм миссионерлар һәм руслаштыручанлык коесы төбендә булганлыктан, мөселманнар аны алырга теләсәләр, шул коега гаркъ булачакларыннан (батудан) хәвеф итәләр. Фән вә мәдәният дөньясында (Көнбатышта) Пастер, Декарт, Кант кебек галимнәрнең исемнәре никадәр мәшһүр исә, безнең мөселман дөньясына анлар урынына - Ильминский, Остроумов, Чериванский,... Русия мөселманнары фән китаплары йиренә Машановларның, Смирновларның исламиятне сүккән китапларыны, «Новое время», «Московские ведомости»нең татарларга һөҗүм иткән гәзитләренә карап, каршы язарга рөхсәт ителмәгәнлеге сәбәпле, өй эчләрендә, гомерен шуның кеби инсаният (кешелеклелек) вә мәдәният дошманнарына ләгънәт укып үткәрәләр».

Яшьлек көннәрендәге, «Китабел-игътибар»дагы кайнарлык, тапкырлык. Проблемалылык, масштаблык. Бай тәҗри-

бәле каләм әһеленең фикер төгәллеге, үткер сүзлелеге. Мәсьәләнең асылын күрә белү, берничә җөмлә белән, халкының тарихи фаҗигасен тулылыгында һәм факт конкретлыгында укучылары күз алдына калкыту. Шуларны басмада үткәрә белү осталыгы. Публицистикада бу дәрәҗәдә күпъяклылыкка Риза хәзрәт кенә сәләтле дисәк тә, әллә ни яңлышкан булмабыз. Һәм бу - аның бер мәкаләсендә генә чагылган очраклы күренеш түгел.

«Вакыт»ның 1906 елгы 1 сентябрь санында кечкенә бер хәбәр күләмендә генә диярлек, имзасыз басылган «Тарихтан бер вәрәкъ (бит)» дигән мәкалә бар. Тел-сөйләм стиль үзенчәлекләре, халык тарихының ул гына белүе ихтимал булган катламнарына кагылуы язма авторының Риза хәзрәт булуында шик калдырмый. Телгә кермәгән, тарихи язмаларда чагылмаган, инде һичкем хәтерендә калмаган, XIX йөз башы татар иҗтимагый хәрәкәтендә һәм тормышында күренекле урын тоткан «абызагайлар хәрәкәте» турында язма хәзинәбездә бердәнбер хәбәр. Диния Нәзарәте архивында күп еллар казынган Риза хәзрәт кенә, инде онытылган ул хәлләр турындагы хәбәрне шулай кабат җанландырып тарихыбызга кайтара ала. Биредә дә теге апрель мәкаләсендә, «Китабел-игътибар»ындагы кебек көрәш дәрте, көрәш пафосы. Шул үзенчәлекләре аның бу язмасын да публицистикабызның шиңмәс классик үрнәге югарылыгына күтәрә.

«Шура» журналының 1909 елгы 10 нчы санында Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Гаилә мәсьәләсе» дигән, исеменә караганда, көнкүреш-гаилә хәлләренә багышланган зур булмаган мәкаләсе басыла һәм аерым бер факт нигезендә царизм милли сәясәтенең нинди мәгънәсезлекләргә барып җитүе фаш ите918*.

Октябрь революциясе һәм Совет дәүләте, ниһаять, әдипнең публицист каләмен кулыннан сугып төшерүгә ирешә кебек. Ул актив катнашкан «иске» («буржуаз») гәзит-журналлар ябыла. Әдип кабат Диния Нәзарәтенә

* Бу хакта авторның икенче мәкаләсендә тәфсилле язылган

эшкә кайтырга мәҗбүр була. 1922 елдан анда мөфти хезмәтен башкара башлый. «Бездә дин дәүләттән аерылган» дигән сылтау нигезендә, руханилар башлыгы буларак, аның язмаларын гәзит-журналларга алмыйлар. Менә шушы шартларда да Риза хәзрәтнең публицистик каләме мәдәниятебез тарихында мәңге сүнмәслек яшен уйнату мөмкинлеген тапкан. Биредә без аның «Уфа шәһәрендә Губернский исполнительный комитетка сайланган котлуг татар егетләренә һәм гомумән бүген эш башында торучы иптәшләргә ачык мәктүб» дигән язмасын күз алдында тотабыз.

Татар тарихын юкка чыгаруны максат иткән караңгылык көчләре, революция, социализм төзү тирәсендә ясалма көчәйтелгән шау-шуларга ышыкланып, соңгы 150 еллар дәвамында татар тарихының бай материаллары тупланган Диния Нәзарәте архивын туздырмакчы булалар. 1924 елда шәһәр идарәсеннән алар шул архив бинасын Нәзарәт кулыннан алу турында карар чыгарталар. Риза Фәхреддинов бу узынуларның асыл йөкләмәсен, чын мәгънәсен бик яхшы аңлый һәм архив бинасын саклап калу өчен ярсу көрәшкә ташлана. Кайларга гына сугылмый ул. Беркайдан яклау таба алмагач, 1925 елның 11 гыйнваренда әлеге «Мәктүб»не (хатны) язып ул «депутатлыкка» «сайланган татар яшьләрен», «җитәкче иптәшләр»не телгә алып, киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итә. Бу адым үзен тулысынча аклый, Риза казый ахыр чиктә архив бинасын-архивны саклап калуга ирешә.

Әлеге «Мәктүб» - әдип публицистикасының яңа югары казанышы. Үткен каләмлелек, үткер фикерлектә һаман да шул ук тапкырлык, кайнарлык, һөҗүмчәнлек. Максат олылыгы һәм конкретлыгы. Автор мәкаләсен Казан алынганда халыкның тарихы, мәдәнияте, һөнәре-кәсебе, икътисади тотрыклыгы тар-мар ителүне сурәтләүдән башлап китә. Һәр мәкаләсендәге кебек, нигезгә тотрыклы тирән тарихи караш куела. Әдип күңелендә халыклык нигезетарихына карата мәкерле дошманлык күрсәткән көчләргә каршы гадел ачу, изге нәфрәт хисе кайный. Шул хисләр

язманың пафосын тәшкил итә, һәр фикерен, һәр сүзен үтәдән-үтәгә сугара. Күңелнең фикер һәм хиснең мондый логик тотрыклылыгы, мондый табигый, органик бердәмлеге башка авторларда юк һәм була да алмыйдыр кебек ышану биләп ала. Галим тар-мар ителгән илнең шуннан соңгы фаҗигале яшәешен сурәтли: «Үз араларында бер-берсенә баглану һәм катнашу дигән нәрсә калмады». «Мең еллык әкиятләр балаларга сөйләнү юлы белән... бу көнгә кадәр килеп җиткән хәлдә, Казан дәүләте... батырларның сугышлары... хакында мөселманнар арасында хәтта әкиятләр генә дә калмады». Әдип халкының тарихын юксына, тарихын даулый. Тарихыңны оныту зур фаҗига: «Алты миллион мөселман - алты миллион кабер ташы кабиленнән катып калды. Киң далада адашып йөрүче сарык көненә төште». Әдип менә шул тораташ хөкемендә калдырылган кешеләргә җан өрү дәрте белән яна.

Ябырылып килә торган (Европа фәнендә, цивилизация котылгысыз итә торган дип күрсәтелгән) рухсыз ялгызлык йомыклыгы (отчуждение) дип йөртелә торган афәт, тоталитарлык кыргыйлыгы әдипнең бу чыгышында көнүзәк конкретлыгын, үтә актуальлек кайнарлыгын көчәйтә, аңа аеруча кискен көрәш чалымнары йөгертә. Р.Фәхреддин - 1905 ел хөррият идеаллары һәм талпынышлары мәйданга чакырган, мәйданга чыгарган журналист. Шул идеалларының зур максатлы көрәшнең, чын мәгърифәтнең - кеше аңының җиңүенә ул абсолют ышану белән ышана. Илдә, шәхес культы котырыну, мәчетләрне тар-мар итү, имамнарны ГУЛАГ зинданнарында черетү, үтерү көннәре якынлашкан көннәрдә мөфти Риза хәзрәт бу язмасында: «Авырлыкларны күрми генә ир егет булып булмый. Бу көннәрне дөньяны тулгак тота. Ул ыңгыраша һәм сукрана. Әлбәттә, бер нәрсә туарга тора... Хәерле бер нәрсә туар... Бу көндә җансыз һәм хәлсез... мөселманнарның киләчәк бер көндә хәлләнү ихтималлары юк түгел. Милләт, никадәр сәфаләткә (түбәнлеккә) төшсә дә, ул һәмишә - Милләт», - дип, олы ышаныч белдерә...

Ризаэддин Фәхреддиннең менә шушы мәкаләләре - публицистик классикабызның күренекле үрнәкләре. Алар оригинальлекләре, тирән фикерлелекләре, накаллы кайнарлыкта гәүдәләндерелүләре, тәэсирчәнлекләре белән аерылып тора. Нәкъ шуның өчен дә алар бу юнәлештәге эшчәнлеккә яшьләрне күнектерү, өйрәтү материалы булып күзаллана. Бу язмалар мәктәп программаларына кертелеп, әдип иҗаты кысаларында өйрәнелергә, хрестоматияләргә кертелеп, популярлаштырырга, халыкның бүгенге яшәешендә дә йөкләмәле эшчәнлеккә җәлеп ителергә тиешләр һәм шуңа лаеклар. Каләме шундый энҗеләр сибә алган авторның башка язмаларында да, һич югы шул мөмкинлек төсмерләре, орлыклары мул булырга тиеш. Аларны барлау, шәрехләү, гыйбрәтле тарихыбызны, милли мирасыбызны өйрәнгәндә актив рәвештә файдалану, укучылар игътибарына тапшыру - галимнәребезнең мөһим һәм саваплы бурычларыннан берсе.

Әнвәр Хәйри

РИЗАЭДДИН БИНЕ ФӘХРЕДДИН ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТӘРБИЯ-ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Татар халкының күренекле фикер иясе, мәгърифәтче, язучы һәм журналист, тарихчы һәм педагог Ризаэддин бине Фәхреддин мәдрәсәнең өлкән сыйныф шәкерте булганда ук үзенең хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә: башлангыч сыйныф балаларын укыта. Дөньяви фәннәр укытуы, укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануы белән ул бик тиз танылып өлгерә. Гомумән, бу һөнәренә гомере буена тугрылыклы булып кала.

Мәдрәсәдә укуын төгәлләгәч, Р.Фәхреддин укыту эше белән шөгыльләнә. Укыту эшчәнлеге белән беррәттән, ул фәнни эш белән мавыга, бик күп китаплар һәм мәкаләләр яза. 1887-1888 елларда аның «Әт-төхфәтел-әнисия», «Китабет-тәсрыйф», «Китабе мөкаддимә. Әт-тәхрирел-мосфа...» һәм «Китабел-игътибар» исемле китаплары басылып чыга. Бу китапларның беренчесе татарча хезмәт булса, икенчесе - гарәп теле грамматикасы (морфологиясе) буенча дәреслек, өченчесе - мирас бүлү мәсьәләләрен шәригать кануннарына нигезләнеп аңлатып бирү, ягъни хокук фәне буенча кулланма, ә дүртенчесе - тәрбия, әхлак мәсьәләләре турындагы хезмәт.

Укучыларның тәртибенә багышланган дәресләрендә Ризаэддин бине Фәхреддин: яшь буынны тәрбияләү эше - ул бик мөһим социаль мәсьәлә, һәм ул үзенә укытучыларның һәм ата-аналарның даими игътибарын таләп итә, дигән фикер уздыра. Моңа дәлил итеп, аның тарафыннан тәрбия, әхлак мәсьәләләренә багышланган унбер исемдәге җитмештән артык китап язылуын күрсәтергә мөмкин. Бу - «Гаилә» (Оренбург, 1902-1916), «Нәсыйхәт I» (Малайлар өчен. Казан-Уфа-Оренбург, 1903-1919), «Нәсыйхәт II» (Кызлар өчен. Казан-Оренбург, 1903-1913), «Нәсыйхәт III» (Зурлар өчен. Казан-Оренбург, 1898-1909), «Тәрбияле хатын» (Казан-Оренбург, 1899-1910), «Тәрбияле ата» (Казан, 1898),

«Тәрбияле бала» (Казан-Оренбург, 1898-1914), «Тәрбияле ана» (Казан, 1898-1909), «Әдәбе тәгълим» (Оренбург-Казан. 1902-1908), «Әһле гыял» («Кыз балалар вә хатыннар өчен», Оренбург, 1908-1910). Октябрь инкыйлабына кадәрге барлык татар мәдрәсәләрендә тәртип, әдәп, әхлак, эстетика дәресләре укытылган һәм Ризаэддин бине Фәхреддиннең әлеге китаплары шул дәресләрдә кулланылган.

Р.Фәхреддин Ш.Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар...» китабы үрнәгендә үзенең «Юаныч» исемле 1200 битлек китабын яза. Аның чын мәгънәсендә күпкрылы галим булуына инанып өчен биредә ул күтәргән мәсьәләләрне атап чыгу да җитә: әхлак, тәрбия, тормыш-көнкүреш, гаилә, никах, дуслык, дошманлык, сугыш, тынычлык, хөкүмәт һәм аның җитәкчеләре, дәүләт эшлеклеләре, борынгы һәм бүгенге вакытларда ислам хөкүмәтләренең тәхет вә мәркәз шәһәрләре исемлеге (алфавит тәртибендә), суд эшләре (казый турындагы мәзәкләр белән), коллык, хөррият, шагыйрьләребезнең җыр һәм шигырьләре (халык җырлары), зыяфәт-туй, кунак булу, кунак итү, ашау-эчү әдәпләре, тәмәке һәм аракының зыяны, яхшы холыклар, бозык һәм яман холыклар, милләт, миллият, фәлсәфә һәм аның тарихы һ.б., һ.б.ш.

Р.Фәхреддин үзенең «Әдәбе тәгълим» исемле (Казан, 1908, 8 б.) китабында җәмгыятьтә шәхес тәрбияләүнең никадәр авыр, катлаулы һәм дәвамлы эш икәнлеген ассызыклап күрсәтеп болай яза: «... Тәрбия - акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер... Сабанчы вә бакчачылар - орлык чәчмәстән вә җимеш икмәстән элек җирләрен ни кадәр игътибар белән йомшартулары, чүп вә бозык үләннәрнең хәтта тамырларына кадәр чыгарып ташлаулары мәгълүмдер. Бу исә җир тәрбиясе булып, җир эшкәртү ысулынча мөһим бер шарттыр. Бу төркемнән бөек вә гүзәл кеше итәчәк кемсәләрне сабый вакытларында тәрбия итү тиеш килер. Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә - гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия - иң кирәкле бер эш булачактыр...»

Тәрбия эшенең нечкәлекләренә һәм үзенчәлекләренә тукталып, галим аны чорларга бүлеп карый һәм шәхес тәрбияләүдә гаилә, мәктәп һәм җәмгыятьнең рольләре гаять зур икәнлегенә басым ясый. Югарыда телгә алынган китапның 9 битендә: «... Баланың иң кечкенә вакытында имезү, йоклату, ашату, киендерү, юындыру, кыскасы, ана вә яки ана хезмәтендә булган кеше кочагында булган тәрбиясе, тәрбия галимнәре каршында «беренче тәрбия» вә мәктәптә булган тәрбия - «икенче тәрбия» вә аннан соң булган тәрбия - «өченче тәрбия» исеме белән билгеледер. Бу тәрбияләрдән беренчесе - аналардан вә аналык хезмәтендә булганнардан; икенчесе - мөгаллимнәрдән, өченчесе - шулай ук мөгаллимнәрдән вә укылачак китаплар һәм газеталар, дус мөгамәләдә булачак затлардан өйрәнелер», - дип яза.

Бала тәрбияләүдә гаиләдән тыш мәктәпкә дә зур җаваплылык йөкләтелгәнен күрсәтеп, Р.Фәхреддин бу эштә мәктәпнең вазифасы нинди булырга тиешлегенә игътибарны юнәлтә: «... Балаларны мәктәпкә җибәрүдән максат нидә, беләсезме?... Әлбәттә, дөрес вә гүзәл тәрбияләтүдер... ... Моннан аңлашылганча, мәктәпнең вазифасы да - фәкать гыйлем өйрәтү белән генә чикләнмичә, бәлки эченә җыелган балаларның күңелләренә Алланы сөю, гүзәл гадәтләр, тырышу, эшлеклелек, туганлык, гайрәт, инсафлылык, гүзәл холык, гаделлек, батырлык, җанлылык кебек яхшылык орлыкларын тәмам игътибар белән чәчү вә тәрбияләп үстерү булачактыр...»

Шул ук хезмәтнең II битендә Р.Фәхреддин, мәктәптә балаларны тәртипкә, әхлакка өйрәтүче укытучының коры сүз белән генә түгел, ә үзенең шәхси үрнәгендә тәрбияләү осталыгы да булырга тиешлеген таләп итә. Аның фикеренчә: «... Хозурына саф-саф булып тезелгән шәкертләргә мактаулы холыклардан дәрес бирүдән элек, мөгаллим булган кеше үз холкын яхшыртырга вә үз холкы вә фигыле белән шәкертләргә күчергеч булырга тиештер. Болай булмаганда шәкертләргә бирелгән нәсыйхәтләр файдасыз,

укытылган дәресләр дә нәтиҗәсез калыр... Чөнки күп вакытта балалар мөгаллимнең сүзенә түгел, бәлки арт көпчәк ал көпчәккә ияргән кебек, фигыленә иярерләр. Соңыннан, ияргән нәрсәләре - аларда бер гадәт булып китәр. Шуның өчен, гүзәл холык өйрәтү турында балалар мөгаллимнең: «Шулай булыгыз! Болай булыгыз!» дип биргән фәрманнарына түгел, бәлки холкы гүзәл булуына мохтаҗ булырлар. Бер мөгаллим - ни кадәр галим вә ни кадәр зирәк булса да булсын, гүзәл холык иясе булмаса һәм дә гүзәл холкын вәгазьләренә яраклаштырып һәм фигыле белән күрсәтмәсә - аның укытуыннан файда күрелмәс. Файдасы торып торсын, бәлки зарар күрелер!..»

Яшь буынга үрнәк тәрбия, гүзәл холык, тирән белем бирергә алынган укытучы-мөгаллимнәрнең дә һөнәри осталыклары, камиллекләре ни дәрәҗәдә югары булырга тиешлеген, аларның гаять зур мәгълүматлы, җитди әзерлекле һәм ихлас, чиста күңелле кешеләр булырга тиеш икәнлегенә басым ясап, Р.Фәхреддин болай ди: «... Мөгаллимнең гүзәл холык иясе булуы ни кадәр тиеш булса, мөгаллимнәргә тиеш булачак мәгълүматны белүе, мөгаллимлек итүгә кодрәте-куәте булуы тагын да артыграк тиештер... ... Мөгаллимнең алдында җыелып, тезелеп утырган балалар һәр ни кадәр кечкенә булсалар да булсыннар, аларны тәрбия итәчәк гыйлем - кар бөртегенә караганда мең тапкыр җиңел түгелдер. Бәлки тәрбия гыйлеме кебек бөек һәм изге бер фәннең кагыйдәләреннән хәбәрдар буларак, аңлылык белән хәрәкәт итүе зарур булыр. Тәрбия гыйлеме - сәламәтлек саклау, әхлак гыйлеме, рух гыйлеме кебек төрле фәннәрдән кушылган кагыйдә астына алынган бер гыйлем булганлыктан, атап киткәнебез гыйлемнәрнең һәр ни кадәр тәфсиллеге белән беленүе тиеш булмаса да, нигез вә терәкләре, игътибар ителгән ысулларыннан хәбәрсез булу да дөрес түгел»...» («Әдәбе тәгълим», 16 б).

Әлеге хезмәтендә, галим, яшь баланы укытучы-мөгаллимнең шәхес, гакыл, рух һәм гүзәл холык тәрбияләүче кеше буларак, һәрвакыт гадел булырга кирәклеген, гүзәл

холык тәрбияләүнең нигезе дә гаделлек икәнлеген аңлатып бирә. Аның фикеренчә, һәр кеше - гадел булганда гына максатына һәм теләгенә ирешә алачак.

«... Гаделлек. Гүзәл холыкларның иң гүзәле - гаделлектер. Дөньяви вә ахирәткә бәйле эшләрдә гаделлек белән булу - һәркем өчен тиеш булса да, тәрбия белән мәшгуль булганлыктан, гакылларны вә рухларны тәрбияләүдә олы бер катнашы булганлыктан, мөгаллимнәр өчен тагын да артыграк тиеш булса кирәк! Гаделлек ияләре һәр максатның юлынча барырлар вә һичкемгә таш атмаган хәлдә теләкләренә дә иркен вә тугры барып ирешерләр...» («Әдәбе тәгълим», 91 б.).

Мәшһүр мәгърифәтчебез бала тәрбияләүне бишектән башларга кирәк дип саный һәм шуңа күрә ана булган хатын-кызны тәрбияләү мәсьәләләренә бик күп игътибар бирә. Ул «бала тәрбияләү - ананың гаиләдәге генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы булып тора», дип саный. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балаларны тәрбияләү буенча биргән киңәшләрендә ул балаларга фәкать дөресен сөйләргә, аларны һәртөрле җеннәр, пәриләр, өрәкләр һәм башка шундый нәрсәләр турындагы уйдырмалар белән куркытмаска кирәк дип әйтә. Аныңча, ана кеше үзенең балалары белән тыныч, тигез тавыш белән сөйләшергә, аларны кызыксындырган сорауларга сабыр гына җавап бирергә тиеш. Тән җәзалары һәм башка төрле җәзалар кулланылырга тиеш түгелләр. Ана кеше үзенең балаларын кечкенә чактан ук үзләренең кылган гамәлләре өчен җавап бирергә өйрәтергә тиеш.

Үзенең «Тәрбияле бала» исемле (Оренбург, 1912) китабының иң башында Р.Фәхреддин тәрбияле баланың нинди булырга тиешлегенә, андый баланың гаилә һәм җәмгыять өчен нинди зур байлык икәнлеген күрсәтеп, болай дип яза: «Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә - тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә

йөзгә аклык китерер. Тәрбияле бала - дөнья байлыгына да бирелмәс һәм бер дәүләт патшалыгы белән дә алмаштырылмас; аны һәркем яратыр һәм мактап телгә алып сөйләр, ни сораса да бирерләр. Тәрбиясез баланы бер кеше дә яратмас, йомыш кушмаслар, бәлки хурларлар вә кимсетерләр генә».

«Шәкертлек әдәбе» исемле китабында Ризаэддин бине Фәхреддин әхлакый, рухи, этик һәм эстетик тәрбия турында төшенчә һәм яшь егетләргә киләчәк һөнәр сайлауда киңәшләр бирә, дуслар сайлаганда ялгышмаска һәм ялкау иптәшләр белән аралашмаска киңәш итә. Биредә ул бөек кешеләрнең тормышыннан гыйбрәтле мисаллар күп китерә һәм китапта күтәрелгән мәсьәләләр буенча галимнәрнең сүзләрен урнаштыра. Аның тәрбия буенча язган китаплары халыкта шул кадәр киң таныла ки, аларның кайберләре унар-уникешәр тапкыр басыла. Үзенең 1904 елда Казанда нәшер ителгән «Шәкертлек әдәбе» исемле китабында (35 б.), галим, күркәм холыкны бар нәрсәдән дә өстен саный һәм көчле, үткен коралга тиңли. Аның фикеренчә: «... Таш йөрәкләр, кара күңелләр - күркәм холык хозурында йомшарырлар, итагать кылырлар. Дошман һәм дусны ризалату өчен күркәм холыктан үткен корал дөньяда юктыр...». Ул, гүзәл холыкның бар нәрсәгә дә ачкыч булуын күрсәтеп, фикерен дәвам итеп, болай ди: «... Киләчәк гомерләрегездә, кирәк - олы галим, кирәк - мәшһүр бер мөхәррир (язучы), кирәк - маһир сөйләүче (хатыйб), кирәк - сәүдәгәр, кирәк - башка әлхасыйль*, теләсәгез кем булсагыз да булыгыз, ләкин гүзәл холыктан бер карыш читкә чыкмагыз!.. Гүзәл холык белән аз гыйлем дә - күп, кыска гомер дә - озын булыр».

Халкыбызның аң-белем, мәгърифәт, мәктәп-мәдрәсә тарихы бик еракларга барып тоташа. Күркәм бер гадәт буларак, бабаларыбыз һәр мәчет янында мәдрәсәсен дә салып куя торган булганнар. Ә мәчетсез яшәү мөэмин-мөселман өчен мөмкин булмаган бер эш саналган. Ерак бабаларыбыз тормышта нинди белемнәр кирәк булса, шуларны бик

җентекләп аңлатып биргәннәр. Һәм инде, әлбәттә, дөньяви тормыш белән берлектә рухи хәят турында да онытмаганнар. Дин сабагы да бергә укытылган. Безнең мәктәп-мәдрәсәләребез тарихы да, әнә шулай итеп, бабаларыбызның ислам динен кабул итүләре белән бәйләнгән.

Ибне Фазлан раслаганча, Болгар илендә алар килгәнче үк инде ислам дине таралган, мәчет-мәдрәсәләр, имам-хатыйблар һәм мөәзиннәр күп булган. Гыйлемгә сусаган һәм гыйлем белән генә дөньяда кеше булып яшәп булачагын аңлаган бабаларыбыз әнә кайчаннан бирле үзләренә киләчәк яшь буынны укыту, тәрбияләү хәстәрен күргәннәр. Алар үз балаларын гына укытып калмаганнар, ә бик күп тирә-як мәмләкәтләр өчен дә белгечләр әзерләгәннәр. Моның шулай булуына XI гасыр башында борынгы Болгар дәүләтенең ислам дине белгечләре әзерләүче зур бер үзәккә әйләнүе ачык мисал булып тора. Әлбәттә, ул уку йортларында дин сабакларыннан тыш дөньяви фәннәр дә укытылган, шул чор өчен кирәкле белем бирелгән.

Казан ханлыгы чорында да Казанның үзендә һәм башка зур шәһәрләрдә мәчетләр эшләп килә, алар карамагында руханилар җитәкчелегендәге башлангыч һәм югары сыйныфлы мәктәп-мәдрәсәләр укучыларга үз чоры өчен кирәкле гыйлемнәрне бирә.

Мәктәп-мәдрәсәләр язмышы, мәгърифәт тормышы Р.Фәхреддинне дә борчый. Үзенең алдарак телгән алынган «Юаныч» исемле хезмәтендә ул «Без - Шималь (Болгар) төрекләрендә гыйлем тәхсил итү рәвешләре» дигән бер бүлек урнаштыра. Мондый рухтагы язмаларын аның башка хезмәтләрендә дә очратырга мөмкин. Р.Фәхреддин коры мәгълүматларны гына теркәп бармыйча, укыту, тәрбия эшенең торышына фәнни, тәнкыйди бәя бирә. Бу эштәге җитешсезлекләр аны бик борчый. Борынгыларның укыту ысулларын үрнәк, өлге итеп файдаланып булмавына көенә.

Р.Фәхреддин биредә әле үзенә кадәр беркем тарафыннан да эшләнмәгән бер бик кирәкле һәм кызыклы эш эшли. Ул үзе бала һәм үсмер вакытындагы мәдрәсәдә

укытылган фәннәр турында мәгълүмат бирә. Шуннан чыгып, без инде XIX гасыр урталарында гади авыл мәдрәсәсендә нинди фәннәр укытылганы турында да төгәл мәгълүмат ала алабыз. Гомумән, Р.Фәхреддин бу язмасы белән дә уку-укыту, тәрбия, мәктәп-мәдрәсәләр тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле эш эшләп калдыра.

Р.Фәхреддин һәр мөэмин-мөселман өчен канун рәвешендә үтәлергә тиешле ислам диненә, башкалардан аермалы буларак, галим сыйфатында, фән күзлегеннән чыгып карый. Аның өчен ислам дине - гади, бер төрле карашлар тупланмасы гына түгел, ә бик җитди, ныклап өйрәнелергә тиешле һәм олуг игътибарга лаеклы зур бер фән өлкәсе дә булып тора. Шуңа күрә ислам диненә кагылышлы бер генә мәгълүмат тә аның игътибарыннан читтә калмый. Биредә без аның ислам динен бөтен нечкәлекләре белән белүен, аның тарихында булган вакыйгалар турында коры мәгълүмат кына бирмичә, җентекле, тирән һәм мәгънәле нәтиҗәләр чыгаруын, һәрьяклап тикшерену уздыруын күрәбез.

Р.Фәхреддин дингә - кешелек җөмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнап алып, Әдәп, Әхлак, Шәфкать, Галиҗәнаплык, Изгелек, Итагатьлелек, Кешелеклелек, Намус, Сафлык, Пакьлек, Гаделлек, Яхшылык һәм башка бик күп күркәм төшенчәләрне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы һәм тәртип, тәрбия һәм әхлакның нигезе, гаиләдә тәртип сакчысы, тормышның төзек, гомерләрнең бәрәкәтле вә файдалы узуына сәбәпче итеп карый. Бу - аның, дин әһеле булудан тыш, чын галим икәнлеген күрсәтеп тора.

Үзенең 1908 елда Оренбургта басылган «Әһле гыял» («Өй җәмәгате»), (Кыз балалар вә хатыннар өчен) исемле китабында әле әйтелгән фикерне куәтләп, Р.Фәхреддин болай дип яза: «Балаларның иң төп вазифалары - кечкенә вакыттан ук Аллаһыны сөю вә Аңа коллык итәргә өйрәнү. Аллаһы кушканнарны җиренә җиткереп үтәү, тыйганнарыннан тыелу - коллык итү буладыр.

Аллаһыны сөйгән гаиләдә тәртип сакланыр, тормыш төзек торыр, гомерләр бәрәкәтле вә файдалы узар. Коллык итү - бәндәнең бурычы. Һәм ул - өстендәге шушы бурычны үтәргә тиеш. Үти икән - файдасын күрер».

Р.Фәхреддин яшьтән үк укыту-тәрбия эшенә бирелә һәм гомере буена аңа турылыклы булып кала. Тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышлап бик күп китаплар бастыра. Әле кулъязма хәлендә сакланып, матбугатта басылмыйча, үз чиратын көтеп ятучы язмалары да мәшһүр галимебезнең әхлакый мәсьәләләргә нинди зур игътибар бирүен күрсәтә. Югарыда телгә алынган «Юаныч» исемле китабыннан «Зыяфәт** һәм туй», «Ашау-эчү» дип аталган бүлекләрдә - бүген инде күбесе онытылып бара торган йолалар, гореф-гадәтләр, кунак кабул итү һәм аны сыйлау әдәпләре, тәмәкенең кеше сәламәтлеге өчен зарарлы булуы, исерткеч эчүдән котылу чаралары, исерткеч эчү аркасында килеп чыккан кайбер гыйбрәтле хәлләр турында һәм бүгенге көн өчен зарур булган башка бик күп кыйммәтле мәгълүматлар бирә. Җәмгыятебез әхлакый яктан шактый бозылу нәтиҗәсендә «Әхлак» дигән югары төшенчә - Р.Фәхреддин аңлаган дәрәҗәдән бик күпкә түбән төшкән чорыбызда бу язмаларның әһәмияте бик зур.

Әдәп, әхлак, тыйнаклык, эшчәнлек, тырышлык кебек сыйфатларның тере гәүдәләнеше буларак, Р.Фәхреддин үзенең балаларын да шул рухта тәрбияли. Кешелек сыйфатын бетерүче һәртөрле бозыклыкларга каршы гомере буе көрәшә. Ул бигрәк тә бөтен әшәкелекләрнең башы, бозыклыкларның анасы булган эчкечелеккә каршы гомере буе көрәш алып бара, кешеләрнең бу юлга төшүләре аны тирән кайгы һәм олуг оят утына сала. Үзенең «Юаныч» исемле зур күләмле хезмәтендә, яшь буында эчүчелеккә карата нәфрәт хисләре тәрбияләүнең үтемле чараларын күрсәтеп, Р.Фәхреддин болай дип яза: «Җиде белән егерме яшь арасындагы яшьләрнең күз уңнарына исерекләрнең рәсемнәрен, үпкәләренең сыйфатларын куеп тору кирәк. Бу рәсемнәрне күреп курыксын-

нар, исереклеккә дошман булып үссеннәр. Аларны исереклек хәлләрен күрсәтә торган кинотеатрларга йөртергә кирәк. Шуларны күрсеннәр вә җирәнсеннәр. Аналарга балалары алдында исерек гаиләләрнең башларына төшкән фаҗигаларны вә харап булуларын һәрвакыт хикәят итү вә кызганып сөйләү кирәк. Шул фаҗигалар яшьләрнең вә балаларның күңелләрендә тамырланып калсын! Аналарның бу рәвешле сөйләгән сүзләре балаларга тәэсир бирә вә йөрәкләрендә урнашып кала».

Р.Фәхреддиннең хатын-кыз табиблар (табибәләр), язучылар, укытучылар, дәүләт эшлеклеләрен тасвирлаган «Мәшһүр хатыннар» китабы татар хатын-кызларының үзаңына уңай йогынты ясый. Хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклылыгын кайнар яклап һәм хатын-кызның, бигрәк тә аналарның җәмгыятьтә токкан урынын билгеләп, һәм бигрәк тә, җәмгыять алдында гаять тә җаваплы булуларын искәртеп, ул «Тәрбияле ана» китабында болай дип яза: «... Халыкның яхшы вә усал улмакларында күп вакытта аналарның һәм катышы уладыр... Тәрбияле аналар үз балаларына гына улмай, бәлки мөселманнарның барчасына хөрмәтле ана улмаклардыр... Аналарның хезмәтләре иң авыр вә иң мәшәкатьле хезмәттер, аны язып бетерерлек, тел илә сөйләп бәян кыйлырлык түгелдер...»

Р.Фәхреддин үзенең «Тәрбияле хатын» исемле 1910 елда Оренбургта басылган китабының 6 нчы битендә хатын-кызның күркәм холыклы булуының гаять зур байлык икәнлеген күрсәтеп болай дип яза: «... Йөзләрчә адәмнәрнең көче җитмәгән бер хезмәтне күркәм холык камил кылыр. Маллар белән сатылып алынмаган хәтерләр - гүзәл холык белән алыныр...» Ә китапның ахырында исә күркәм холыклы һәм тәрбияле хатын-кызлар турында канатлы гыйбарәләр китерүне урынлы саный (24 б.). «... Яхшы тереклек - гүзәл холык иясе хатыннан башка булмас». «Гүзәллеге белән мактанучы хатын - гүзәл түгелдер, бәлки тәрбияле хатын гүзәлдер». «... Дөньяның бәхетсезләре - тәрбияле хатын белән тәрбияле баладан мәхрүм булган затлардыр...»

Ризаэддин бине Фәхреддиннең үзе мөхәррирлек иткән «Шура» журналында (Оренбург, 1908-1917) ватанында һәм чит илләрдә булган мәгариф тарихы һәм аның шул чордагы торышы киң яктыртыла, фикерләр көрәше чагылыш таба, тәҗрибә уртаклашу һәм заманасы таләп иткәнчә Рәсәйнең мәктәпләренә укыту-тәрбия эшенең куелышы мәсьәләләре тикшерелә. Шул юнәлештәге мәкаләләр арасында «ысулы җәдид» («яңача ысул») турында, мәктәпләр, китаплар, дәреслекләр, уку әсбаплары, китапханәләр, укытучылар әзерләү, табигый һәм дөньяви фәннәрне укытуны яхшырту турында һәм башка язмалар очратырга мөмкин. Биредә шулай ук биология, педагогика, дидактика, психология буенча тулы дәреслекләр һәм шулай ук төрле мәдрәсәләрнең программалары һәм укыту планнары, башка төрле педагогик язмалар - барысы 500 дән артып киткән исемдәге мәкаләләр басыла.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең тирән кызыксынган һәм җитди шөгыльләнгән мәсьәләләрнең күплегенә гаҗәпләнәсең дә, сокланасың да. Ул тарих, фәлсәфә, педагогика, әдәбият, тел белеме, сәнгать, география, этнография, археология, археография, генеалогия, эпитафия, медицина, нумизматика, юриспруденция, астрономия, халык авыз иҗаты, дин тарихы һәм башка төрле фәннәр белән бик нык кызыксынган һәм алар буенча күпсанлы һәм кыйммәтле хезмәтләр язып калдырган.

Бу чыгышыбызда мәшһүр галимебез Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Нәсыйхәт» исемле өч китабына аерым тукталу сорала. Китапның беренчсе - ир балаларны әхлакый һәм рухи тәрбияләүгә, әдәпкә, тәртипкә өйрәтүгә багышланган. Икенчесе - кыз балаларны тәрбияләү, ничек итеп эчке һәм тышкы матурлыкка ирешү, үз-үзләрен тоту кагыйдәләренә өйрәтә. Өченчесе исә - зурларны әхлакый һәм рухи тәрбияләүгә багышланган.

Татар халкының күп гасырлар буенча яшәп килгән һәм көндәлек гамәлдә булган әхлакый һәм рухи тәрбия кануннарын эченә туплаган бу гыйльми хезмәт халыкта

шулкадәр тиз танылып һәм таралып өлгерә ки, ул күп еллар дәвамында зур-зур тиражлар белән Рәсәйнең төрле шәһәрләрендә басыла. Чын мәгънәсендә халык педагогикасына нигезләнеп язылган бу дәреслекне автор үзе «Гыйльме әхлак», ягъни «Әхлак гыйлеме» дип атый һәм китапның беренчесен - «Гыйльме әхлактан җиденче кисәк», икенчесен - «Гыйльме әхлактан сигезенче кисәк», өченчесен - «Гыйльме әхлактан тугызынчы кисәк» дип атый. Моннан - бу мәсьәләгә багышланган аның башка исемдәге хезмәтләре дә булганлыгы аңлашыла. Беренче китапның башында «Балалар өчен» (ир балалар күздә тотыла) дип күрсәтелгән, икенчесендә - «Ялгыз (фәкать - Ә.Х.) кыз балалар өчен» дип язылган, ә өченчесе - «Олуглар вә бөекләр өчен» дип аталган. Беренче китап - унике мәртәбә Оренбургта 1903, 1906, 1908, 1912, 1913, 1916 елларда; Казанда 1904, 1909, 1911 елларда; Уфада 1907, 1908 елларда зур-зур тиражлар белән басылып таралып бетә. Икенче китап - җиде тапкыр, Оренбургта 1903, 1912, 1913 елларда; Казанда 1905, 1908, 1910, 1911 елларда басылып чыга. Өченче китап - сигез тапкыр, Оренбургта 1903, 1911, 1912, 1915 елларда; Казанда 1907, 1909, 1911 елларда басылган, ә берсендә - басылуның урыны һәм елы күрсәтелмәгән.

Татар халкының күп гасырлар буенча тупланып, үсеп, камилләшеп килгән әхлакый һәм рухи тәрбия кануннарын, гомумиләштереп, «халык педагогикасы» дигән төшенчәгә кертергә мөмкин. Аның тарихы бик еракларга барып тоташа. Кешелек җәмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнан алып, кешеләрдә үз-үзләрен тотуга, олыларга буйсынуга, балаларны саклауга, илаһи затлар булып күзалланган төрле җан ияләренә, табигать күренешләренә һәм башка нәрсәләргә табынуга юнәлдерелгән билгеле бер дәрәҗәдәге инстинкт яки курку белән бәйле примитив тәрбия чаралары гамәлгә керә. Кешенең аң дәрәҗәсе үскән һәм тәҗрибәсе арткан саен тәрбия чаралары да үскән, арткан, камилләшкән һәм билгеле бер кануннар

җыелмасы рәвешенә кергән. Ислам дине кабул ителгәнче, әлеге кануннар - иң яхшы әхлакый һәм рухи тәрбия чараларын эченә алган һәм татар халкы үзе булдырган, үзе иҗат иткән бөек бер ядкяр булган булсалар, Ислам дине тарала башлагач һәм кабул ителгәч - аңа дини төсмерләр дә бирелеп, ул гөнаһ, әдәп һәм башка төшенчәләр белән тулыландырылган, тагын да баетылган. Элек яшәп килгән тәрбия чаралары белән Ислам дине алып килгән әхлакый һәм рухи тәрбия ысуллары һич кенә дә бер-берсе белән каршылыкка килмәгән, ә, киресенчә, бер-берсен камилләштергән. Күп кенә очракларда, хәтта тулаем дип әйтергә мөмкин, алар бер-берсенә тәңгәл килеп, бер үк төшенчәдә, бер үк мәгънәдә йөреп, бер үк вазифаны башкарганнар. Нәкъ менә шушы халыкчан һәм дини тәңгәллекләргә нигезләнеп, Ризаэддин бине Фәхреддин үзенең «Болгар вә Казан төрекләре», исемле китабында Ислам диненең Борынгы Болгар дәүләтенә бернинди каршылыкларсыз таралып, үсеп, чәчәк атуын һәм рәсми дәүләт дине итеп кабул ителүене сәбәбен аңлатып бирә. Әлеге китабының (1993 елда Казанда басылган) 46 битендә ул: «Ислам барлыкка килгәннән соң, кайсы еллардадыр, Болгар мәмләкәтенә һәм Болгар кавеме арасыда Ислам дине керде һәм яхшы гына таралды. Чөнки боларның рухи халәтләренә Ислам дине яраклы һәм туры килә торган иде», дип яза. Димәк, безнең борынгы бабаларыбыз үз ватаннарына Ислам дине килгәнче үк инде, нигездә ул таләп иткән әхлакый һәм рухи тәрбия кысаларында яшәгән булганнар.

Әлеге хезмәттә күтәрелгән һәм энәсенән-җебенә кадәр җентекләп тикшерелгән мәсьәләләрнең күплегенә, тирәнлегенә һәм җитдилегенә хәйран калырлык. Биредә ата-бабаларыбызның гаҗәеп бай акыл хәзинәсенә нигезләнгән һәм - мең еллар буенча тупланып һәм камилләшеп килгән милли гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз, гаилә кануннары, әдәп, әхлак, тәртип, тәрбия кануннары, этика, эстетика, психология, физиология, сәламәтлек саклау кануннары, ги-

гиена, ислам дине һәм... боларның барысын да берләштерүче - халык педагогикасының XX гасыр башы өчен генә түгел, ә бүгенге көн өчен дә үзенең әһәмиятен югалтмаган һәм киләчәктә дә югалтмаячак зур чыганак булуын күрәбез. Биредә күтәрелгән һәр мөһим мәсьәләне тикшереп, зур фәнни хезмәтләр язарга мөмкин. Әмма - максат ул түгел. Бу китап - дәреслек, кулланма буларак басылып таралган. Аның никадәр мөһим һәм зарур китап булганлыгын зур-зур тиражлар белән унике тапкыр басылып таралып бетүе дә күрсәтә. Бүгенге җәмгыятебез әхлакый һәлакәт чигенә килеп җиткән, җинаятьчелекнең коточкыч чиккә җитеп үскән, эчкечелекнең һәм наркоманиянең чәчәк аткан, җенси тотнаксызлык илкүләм дәрәҗәдә пропагандаланган һәм ата-улны, ана-кызны белмәс чиккә килеп җиткән фаҗигале бер вакытта бу китапның яңадан актив гамәли кулланылышка кертелүе, үз чорындагы кебек зур-зур тиражлар белән кабат-кабат басылып таратылуы сорала. Һәм ул - милли балалар бакчалары, тәрбиячеләр, мәктәпләр, гимназияләр, лицейлар, колледжлар, институтлар, университетлар һәм академияләр өчен һәр яшьтәге, һәр дәрәҗәдәге, һәр баскычтагы укучылар, шәкертләр, студентлар, аспирантлар, укытучылар, профессорлар, академиклар, һәм иң мөһиме һәр милли гаилә, һәр ата-ана, һәр бала һәм яшүсмерләрең, кыскасы, җәмгыятебездә шәхес тәрбияләү, бу очракта милли генофондыбызны саклап калу һәм яңадан торгызу мәсьәләсе белән шөгыльләнгән һәркем өчен өстәл китабы булырга тиеш. Нәкъ менә шушы китап нигезендә милли балалар бакчаларында һәм һәртөрле уку йортларында «Тәрбия дәресләре», «Педагогик мирасыбыз», «Халык педагогикасы» һәм башка төрле исемдәге дәресләр, лекцияләр, семинарлар, курслар үткәрелергә тиеш һәм «халык әхлагкы», «халык педагогикасы» дигән белгечлекләр буенча махсус әзерлекле белгечләр әзерләү дә - максатка ярашлы булыр иде. Ә бу гамәлләр - үз чиратында үзебезнең рухи, әхлакый мирасыбызга хөрмәт күрсәтү генә түгел, ә милләтебезнең, җәмгыятебезнең

әхлагын сафландыру, рухын пакьләндерү юнәлешендә бик мөһим һәм бик кирәкле җитди бер адым булыр иде.

Ризаэддин бине Фәхреддин «Нәсыйхәт»нең икенче китабын 27 бүлекчәгә бүлә. 1903 елда Оренбургта «Гыйльме әхлактан сигезенче кисәк» булган «Ялгыз (фәкать - Ә.Х.) кыз балалар өчен» генә дә барысы җиде тапкыр зур-зур тиражлар белән басыла. Әлеге хезмәтнең керешендә, автор, кыз балаларга мөрәҗәгать итеп: «холкы гүзәл булган кыз бала - бөтен гаиләсе өчен олуг байлык вә бәхеттер, ... укыган вә холкын тәрбияләгән кыз - алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр, ... мондый кызлар карендәш - кабилә өчен генә түгел, бәлки бөтен милләт вә бөтен дөнья халкы өчен дә мактаныч булыр», - дип башлап китә. Шунда ук әдәпле вә әдәпсез кешеләрнең кемлеге турында, ничек итеп әдәпле кеше булырга кирәклеге хакында да язылган.

Бу китабында бөек галимебез Ризаэддин бине Фәхреддин малайлардан аермалы буларак, кыз балаларның акылфигылен, психологиясен, физиологик үзенчәлекләрен һәм башка сыйфатларын тирән белгән педагог-тәрбияче һәм табиб буларак тагын да киңрәк ачыла. Биредә - көндәлек тормышта, җәмәгать урыннарында һәм чит кешеләр арасында, олылар һәм ярдәмгә мохтаҗ кешеләр янында, күршеләр һәм авырулар, туганнар һәм укытучылар янында, кыскасы, һәр очракта үзеңне ничек итеп әдәпле, тыйнак итеп тотарга кирәклеген өйрәткән тәрбия, әхлак кануннары бөтен тирәнлеге белән ачып бирелә.

Ризаэддин бине Фәхреддин «Нәсыйхәт»нең өченче китабын 1904 елда Оренбургта «Гыйльме әхлактан тугызынчы кисәк» итеп «Олуглар вә бөекләр өчен» дигән исем белән бастыра. 26 бүлекчәдән торган әлеге хезмәтнең баштагы 15 бүлекчәсе төрле әдәпләргә багышланса, соңгы 11 бүлекчәсе үгетләрдән тора. Бу китап та, алдагылары кебек үк, зур-зур тиражлар белән Оренбургта һәм Казанда сигез мәртәбә басылып таралып беткән.

Китапның керешендә нәсыйхәт бирүнең бик үтемле тәрбия чарасы икәнлеге һәм олыларның, бигрәк тә ата кешенең, үзе нинди булуына карамастан, үз балаларын яхшы тәрбияләү максатында нәсыйхәт бирү бурычы зур икәнлеге ассызыклап әйтелә. Һәр ата үзенең баласының нинди булып үсүенә бик зур бурычлы икәнлеген дәлилләп, «Бохари шәриф» («Изге Бохари») исемле хәдисләр китабының 6 томыннан, 152 биттән бер җөмлә китерелә. «Күллүкүм рагун вә күллүкүм мәсьәүлүн гань рагыййәтүһү», ягъни «һәрберегез - көтүчесез, вә һәрберегез - көтүләрегез хакында җавап бирәчәксез» - дигән изге һәм гыйбрәтле сүзләр - бигрәк тә мөһим һәм олы мәгънәгә ия. Ризаэддин бине Фәхреддин үзенең «Нәсыйхәт» китапларын язуын да әлеге изге сүзләргә таянып, балаларына һәм киләчәк буыннарына нәсыйхәт итү һәм үзенә йөкләтелгән изге бурычны үтәү йөзеннән башкаруын әйтеп үтә.

Ризаэддин бине Фәхреддин: адәм баласы үзен-үзе тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен-үзе тәрбияли ала, дип саный һәм аның күп кенә китаплары үз-үзеңне тәрбияләүдә ярдәм итү максатында язылган. Әлеге фикеренә ул үзе гомере буенча тугрылыклы булып кала һәм кешенең үзен-үзе тәрбияләүнең һәм камилләштерүнең гүзәл бер үрнәге булып тора. Нинди генә вазифа башкарса да һәм нинди генә фән тармаклары белән шөгыльләнсә дә, мәшһүр мәгърифәтче галимнең игътибарыннан уку-укыту һәм тәрбия-әхлак мәсьәләләре беркайчан да читтә калмый. Бу эше белән ул гомере буе шөгыльләнә һәм педагогика мәсьәләләренә багышлап 77 китап бастырып калдыра. Шуңа күрә дә инде бөек галимебезнең милли педагогика өлкәсендәге хезмәтләре - хәтеребездән һичкайчан җуелмас эз калдырган. Аның бу эшчәнлеге тирән фәнни тикшеренүгә мохтаҗ һәм үзенең өйрәнүчеләрен көтеп ята.

Бөек галимебезнең милли педагогика өлкәсендәге биниһая зур хезмәтләренә тиешле бәя бирү һәм аның исемен мәңгеләштерү максатында Ризаэддин бине Фәхред-

дин исеме Казан дәүләт педагогия университетына бирелсә, аның исемендәге стипендия булдырылса һәм Казанның «Париж Коммунасы урамы» «Ризаэддин бине Фәхреддин урамы» дип үзгәртелсә - олы галимебезнең рухы шат, ә аның рухы алдында безнең дә йөзебез ак булыр иде.

ИСКӘРМӘЛӘР

* Озын сүзнең кыскасы.

** Кунакчыллык.

Ф.Ф.Исламов

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИНОВ - МӘШҺҮР МӘГЪРИФӘТЧЕ, ПЕДАГОГ

Р.Фәхреддинов дөньяга карашы һәм гомуми эшчәнлеге буенча киң карашлы мәгърифәтче һәм педагог була. Аның әсәрләре Татарстанда һәм Башкортстанга бәйле төбәкләрдә генә түгел, бөтен Русиядә киң таралган һәм замандаш төрки халыкларның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үсешендә зур роль уйнаган. Сыйнфый юнәлеше һәм иҗтимагый-сәяси эчтәлеге каршылыклы булуга карамастан, алар хәзерге вакытта да үз әһәмиятен югалтмаган фәнни чыганак булып кала киләләр.

Р.Фәхреддинов педагогик эшчәнлек белән турыдан-туры озак вакытлар шөгыльләнә алмаса да, тарихка гомере буе ата-аналарга, яшь буынга белем һәм тәрбия бирергә, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту проблемаларын хәл итәргә, тәрбияви эчтәлекле хезмәтләр, мәктәп-мәдрәсә шәкертләре өчен дәреслекләр, методик кулланмалар иҗат итәргә омтылучы һәм бар теләкләрен диярлек гамәлгә ашыручы данлы шәхес буларак керде.

Мәгълүм булганча, 1887 нче елда имамлыкка имтихан биреп, ике ел тулы хокуклы хәлфә булып мәдрәсәдә эшләгәч, 1889 елда Р.Фәхреддиновны хәзерге Азнакай районындагы Илбәк авылына икенче мәхәллә имамы итеп чакыралар. Тагын бер елдан укытучылыгы һәм китаплары (бигрәк тә «Китабел – игътибар» белән үзен тирән белемле, имамәтлек хезмәтендә исә ихлас, гадел кеше сыйфатында танытып өлгергән өметле мөгаллимгә Диния Нәзарәтендә казыйлык вазифасын тәкъдим итәләр. 1908-1909 елларда ул Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсенең директоры, педагогик һәм назыйрьләр советының җитәкчесе вазифаларын башкара, үз гомерендә педагогик темаларны яктырткан 77 китап, күп санлы дәреслекләр, мәкаләләр яза.

Бер үк вакытта әдәбият, тарих һәм халык мәгарифе өлкәсендә актив эшчәнлек күрсәткән яшь укытучы 1888

елда язган «Китабел-игътибар» дигән хезмәтендә туган халкының, бигрәк тә яшь буынның милли аңын һәм культура дәрәҗәсен үстерү өчен мәгариф системасын яңарту проекты белән чыга, гамәлдәгесен, аның уку планын һәм программаларын кискен тәнкыйтьли, урыс гимназияләренә охшаш «һөнәргә өйрәтә торган» уку йортларын оештыруны тәкъдим итә. Җәмәгатьчелек көче белән ачылачак һәм эшләячәк яңа тип мәктәпләрнең төп уку-укыту принципларын ачыклый. Шул күзлектән чыгып, түбәндәгеләрне бәян итә: дөньяви фәннәрне балаларның туган телендә өйрәтү, аларны сәгатьләп укыту, сәгатьләп ял иттерү, уку елы ахырында аерым фәннәрдән имтиханнар кабул итү, билгеле вакытта үзләштерелгән белемнәрен бәяләү һәм таныклык язуы (диплом, аттестат) бирү һ.б. «Балаларны тәрбия итәр өчен, - дип язды Р.Фәхреддинов, - ике төрле эшкә зур хаҗәтебез бардыр. Беренчесе - балаларны үзләренә хас ирләр, кызларына башка-башка мәктәпләр кирәк. Алар шул мәктәпләргә барып, сәгатьләп дәрес укысыннар. Сәгатьләп язу язсыннар... Һәр утыз бала өчен бер укытучы булсын... Инде сорарсыз - бу эшләрне гамәлгә ашырырга акча кайдан алырга кирәк, дип... Гайрәт-һиммәт (тырышлык) булса, акча табарга булыр. Мәсәлән, иң элек җәмгыять тәртип итеп, сүздән ризалык алырбыз. Соң һәрберемез кырмыскаларның йорт ясаулары мисалында чынлап эшкә керешермез. Кулдан килгәннәремез акча яки өч-дүрт көн хезмәт илән ярдәм итәрмез. Бер авылда бу рәвештә мәктәп бина итүдән урынымыз кимемәс... Хәзерге мәктәпләрдә... балаларга язу танып яза белергә дүрт ел гомер кирәк буладыр... Бу яңа мәктәпләрдә бер елда бик яхшы язу танып укырлар һәм язарлар... Безнең белән мәгыйшәт (тормыш) итә торган чит мәктәпләрнең бик фәкыйрьләрендә дә балалар укытуда гакылдан тыш гайрәт бар»[1].

Шулай итеп, XIX гасырның сиксәненче еллары азагында ук җәмәгатьчелек көче белән яңа типтагы мәктәпләр ачарга кирәк дигән фикерне башлап кузгатучыларның

берсе, бу мәктәп төзелешенең шактый тотрыклы эшкәртелгән идеяләрен фикерләп, яңа мәктәпнең төп уку-укыту принципларын тәкъдим итүче Р.Фәхреддинов хакында бәян итүе белән татар мәгърифәте, мәгарифе тарихын, мәшһүр фикер иясенең тормыш юлын һәм иҗатын җентекләп өйрәнүче галим Равил Үтәбай-Кәрими нык хаклы булды. Риза казый яшь укытучы балаларга уку, аларның сәламәтлеген саклау, рухларын күтәрү өчен уңайлы шартлар тудыру юнәлешендә дә каләм тибрәтә. «Сәгатьләп дәрес укысыннар, сәгатьләп уйнасыннар, иркә очып шатлансыннар, куансыннар, - ди педагог. - Дәрес укыган урыннарында тузан, юеш, бу, ис кебек табигатькә хилаф, сәламәтлекккә зарарлы нәрсәләр булмасын. Сабый һәм сабияләр шушы урыннарда рәхәт-рәхәт укысыннар»[2].

Төрек, фарсы, гарәп телләрен мәдрәсәдә укыганда ук тырышып үзләштергән егет шәкертләр өчен 1887 елда ук Казанда гарәп теле грамматикасы (морфология) буенча «Китабет-тәсрыйф. Гыйльме сарыф» исемле дәреслеген язып бастыра.

Р.Фәхреддинов башлангыч мәктәпне тәмамлаган балалар өчен ике бүлектән торган «Мәгариф мәдрәсәсе» проектын эшли. Аның беренче бүлегендә балаларга шәригать белемнәре, икенчесендә дөньяви фәннәр укыту күздә тотыла. Мондый мәдрәсәләрдә укучы шәкертләр аз гына вакыт эчендә «гакаид (иман), хисаб, һәндәсә (геометрия), гыйльме җәграфия, гыйльме җәбер (алгебра), хикмәт (фәлсәфә), кимия (химия), һәйьәт (астрономия), тыйб (медицина), гыйльме хайванат (зоология), гыйльме нәбатәт (ботаника) тарих ...вә гайреләрне белерләр», - ди галим. Мәшһүр фикер иясенең гомере буе аеруча яратып эшләгән өлкәсе - педагогика, кече, урта, өлкән яшьтәге балаларны, шәкертләрне, аларның ата-аналарын тәрбияләү проблемасы булды. Ул бу өлкәгә кагылышлы бихисап хезмәтләр, дәреслекләр, методик кулланмалар иҗат итте. Хезмәт юлын авыл мәктәбендә хәлфә булып башлаган Р.Фәхреддинов укыту һәм тәрбия өлкәсендә яңа ысуллар кертү, дөньяви

фәннәр укытны юлга салу нәтиҗәсендә җәмәгатьчелек, халык арасында зур хөрмәт казана. Педагог-галим үзенең хезмәте чорында арифметика, татар һәм гарәп телләре грамматикалары, тәрбия проблемаларын колачлаган дистәләгән дәреслекләр авторы булды. Ул яшь буынны тәрбияләүнең социаль проблема булуын аңлата, бу өлкәдә мөгаллимнәр һәм ата-аналарның даими рәвештә үзара килешеп, аңлашып эш итәргә тиешлекләрен искәртә.

Шунысы мәгълүм: революциягә кадәрге татар һәм башкорт мәктәп-мәдрәсәләрендә әхлак дәресләре дә укытыла. Р.Фәхреддинов балага бишек чорыннан ук тәрбия бирү фикерен алга сөрә, шунлыктан хатын-кыз, ананың үзен тәрбияләү мәсьәләренә җитди игътибар бирә. Аның «Тәрбияле хатын» һәм «Тәрбияле ана» дигән хезмәтләре шул максатны күз алдында тотып язылганнар да инде. Бу дәреслекләрнең ун ел дәвамында тугыз мәртәбә басылып чыгуы аларның халык арасында нинди уңыш казануын яхшы аңлатса кирәк.

Бу китапларда ананың гаиләдәге роле, бала тәрбияләүдә җәмгыять алдындагы җаваплылыгы бәян ителә, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп яшендәге балаларны тәрбияләү буенча кыйммәтле киңәшләр бирелә, төрле холыклы балалар белән эш итүнең алымнары күрсәтелә. Сабыйларны, укучыларны тәрбияләүгә бәйле киңәшләрендә ул аларга бары тик дөрес мәгълүматларны җиткерергә, балаларны һәртөрле албасты, җен, сихерчеләргә бәйле уйдырмалар белән куркытмаска киңәш итә. Балалар белән һәрвакыт гадел булырга, аларның алдашу гадәтләрен кисәтергә өнди. Автор ананың үз балаларында кечкенәдән үк эш-гамәлләре, кыланашлары өчен җаваплылык хисе тәрбияләргә тиешлеген искәртә, балалар белән һәрвакыт тыныч тонда гына сөйләшүен, аларга карата тән җәзасы кулланмавын хуп күрә.

Бу хезмәтләрдә чисталыкның, туклану режимының роле, салкын тию авырулары, кием-салым, аяк киеме, хатын-кыз гигиенасы хакында киң мәгълүмат, эшлекле киңәшләр

тәкъдим ителә. Кече яшьтәге балалар өчен язылган «Тәрбияле бала» дигән дәреслегенең унбер тапкыр дөнья күрүе дә аның кыйммәтле ярдәмлек булуын раслый.

Өлкәнрәк шәкертләр өчен язылган «Шәкертлек әдәбе» дигән дәреслегендә галим әхлак, эстетик тәрбия төшенчәләрен киң һәм тирән яктырта. Яшьләргә булачак профессияләрен, дуслар сайлау мәсьәләләрендә дә файдалы киңәшләр бирә, ялкау кордашларыннан читләшергә өнди. Китапта шулай ук күренекле шәхесләр тормышыннан гыйбрәтле мисаллар, аларның тәрбия мәсьәләләренә карата әйткән мәгънәле, кызыклы фикерләре китерелә. Галим карашынча, кеше гомере буе үзен тәрбияләү, камилләштерү белән шөгыльләнергә, иптәшләрен тәрбияләргә омтылырга тиеш.

Үз-үзеңне тоту һәм тәрбияләү буенча ярдәмлекләрдән тыш, Р.Фәхреддинов ир һәм кыз балалар, шулай ук өлкән яшьтәгеләр өчен махсус уку китаплары - өч кисәктән торган «Нәсыйхәт» дигән хезмәт язган. Бу китаплар үз заманында бик популяр булган. Аларның уналты ел эчендә егерме җиде тапкыр басылып чыгуы бу хакта шулай ук ачык сөйли.

Китапларны күчереп язып, Р.Фәхреддинов бай китапханә туплаган, мәдрәсәдә алган белемнәрен даими тулыландырган, үз заманының танылган энциклопедист галиме булып әверелгән, мөстәкыйль рәвештә урыс телен үзләштергән.

XX гасыр башында татар иҗтимагый тормышында иң тирән эз калдырган вакытлы матбугат органнарының берсе - «Шура» журналы була. 1908-1918 елларда Оренбургта Р.Фәхреддинов мөхәррирлегендә айга ике тапкыр чыгып килгән бу журналның 240 саны дөнья күрә. Журналда даими эшләп килгән 21 рубрика арасында «Тәрбия вә тәгълим» бүлеге дә урын алган. Академик М.Госманов раславынча, журналда ун ел дәвамында дүрт меңләп публикация, шул исәптән педагогика, дидактика, тәрбия, методика мәсьәләренә караган 400 дән артык материал басыла[3]. Аларның тулы исемлеге М.Госманов тарафыннан «Шура» журналы буенча төзелгән кулъязма

био-библиографик күрсәткечендә «Мәктәп-мәгърифәт» исемле тематик бүлеккә туплап бирелгән. Бу бүлек үз чиратында «Татар һәм башка төрки халыкларда мәктәп-мәгариф, мәгърифәт», «Русларда мәктәп-мәгариф», «Чит илләрдә мәктәп-мәгариф», «Укыту һәм мәктәп программасы», «Тәрбия» (мәктәп һәм гаиләдә) кебек төркемнәрдән тора. Бу мәкаләләрдә яктыртылган проблемаларның күбесе бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген югалтмый.

«Шура»да күтәрелгән милли мәктәп, аның эшчәнлеге, юнәлешләре, педагогик алымнар, баланың яшь үзенчәлекләрен, белем дәрәҗәләрен исәпкә алып эш итү кебек темалар нәзари һәм гамәли кыйммәтләрен әле дә булса саклауларын дәвам итә. Журналда шулай ук Русиядә һәм чит илләрдәге мәгариф тарихы һәм аның шул вакыттагы торышы киң чагылышын таба, мәгариф мәсьәләләренә карата фикерләр көрәше яктыртыла, татар һәм башкорт мәктәп-мәдрәсәләрендәге укыту-тәрбия эшенең куелышына бәйле тәҗрибә уртаклашу оештырыла. Педагогик эчтәлекле мәкаләләр арасында «Ысулы җәдид»нең («Яңа метод») асылын ачыклаган язмалар, китаплар, дәреслекләр, уку кулланмалары, укытучылар әзерләү, табигать һәм дөньяви фәннәрне укытуны яхшырту турындагы мәкаләләр һ.б. белән очрашабыз. «Шура» битләрендә биология, педагогика, дидактика, психология фәннәренең тулы дәреслекләре, аерым предметларның укыту методикалары, төрле мәдрәсәләрнең уку планнары һәм программалары һ.б. педагогик эчтәлекле мәкаләләр урын алган. Журналда төрле елларда басылган «Дин вә милли мәктәпләребез хакында» (1913, №24; 1914, №2) «Ислам вә ана теле» (1917, №3, 16), «Төрки лөгатемезнең әдәбияты белән шөгыльләнүчеләргә» (1911, №12), «Үрнәк алырга лаеклы бер гаилә» (1913, №17), «Татар вә башкорт көйләре» (1912, №9), «Тел ярышы» (1910, №1-4) кебек һ.б. мәкаләләр бүгенге көндә дә актуаль яңгырый. «Мәктәб вә зәкят, хәзинә вә земство ярдәме» дигән китабы да (Оренбург, 1910) авторның психологик карашларын ачык чагылдыра.

Р.Фәхреддинов гомере буена төрле халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгыту, үстерүгә зур игътибар итте. Халыкларның үзара якынаюы, аңлашулары булсын өчен ул «Шура» журналында башкорт, болгар, караим, чуаш, төрек, бурят, мордва, удмурт, мари, гарәп, француз, инглиз һ.б. көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, тел-әдәбиятлары, халык иҗаты, килеп чыгышлары, мәгърифәткә, мәгарифкә бәйле карашлары буенча даими рәвештә бай эчтәлекле мәкаләләр бастырды.

Зур сәләткә ия булган, күп укыган, үзенә дә бик таләпчән булган галим мәктәп-мәдрәсәләрдә кулланыла торган белем һәм тәрбия бирү чаралары, ысуллары белән канәгатьләнеп кала алмый, даими эзләнә. Аның педагогика, тәрбия мәсьәләләренә булган җитди карашы «Тәрҗемәи хәлем» дип аталган хезмәтендә аеруча ачык чагыла: «Күп еллардан соң белдем ки, «гыйльми тәрбия» (педагогика) иң бөек фән икән. Ул исә сабак укыту юлларын вә, гомумән, шәкертләр тәрбия итү кагыйдәләрен белдерә икән»[4].

Мәгариф мәсьәләләре белән беррәттән, галим яшь талантларны үстерүгә дә игътибар иткән. Моны без аның югарыда искә алынган «Шәкертлек әдәбе» дигән дәреслегендә башлап язучыларга киңәшләр бирүеннән дә ачык күрәбез.

Тәрбия өлкәсендә аеруча уңышлы нәтиҗәләргә гаилә, мәктәп, җәмәгатьчелек тәрбиясен үзара килешеп бер юнәлештә алып барганда гына ирешергә мөмкин булуын Р.Фәхреддинов, күп еллар элек үк, бик дөрес билгели алган. Аның түбәндәге фикерләре шул хакта сөйли: «Өммәтләрне (милләтләрне) дә, фәрдләрне (аерым шәхесләрне) дә бәхет мәйданына алып бара торган юлларның иң тугрысы - гүзәл холык вә яхшы тәрбиядер ... Гүзәл тәрбия хасил кылыр өчен мәктәпләр, гаиләләр, җәмгыятьләр исемендә өч төрле дәресханәләрдә үтәргә мәҗбүрләр. Әгәр дә шушы дәресханәләрдән яхшыларын сайлый алсалар, шул нисбәттә тәрбияләре яхшы, әгәр дә бәгъзе берләре яки бөтенләй бозык булса, шул нисбәттә тәрбияләре дә бозык булыр. Тәрбиясе бозык кеше, табигый, бәхет вә сәгадәткә ирешә алмас...»[5]

Р.Фәхреддиновның педагогик карашлары XIX гасыр ахырында, XX гасыр башында иҗат ителгән «Сәлимә, яки гыйффәт» (1899), «Әсма, яки гамәл вә җәза» (1903) романнарында киң чагылышын тапкан. Аларда әледән-әле тәрбия-тәгълим турында публицистик уйланулар, фәкыйрь-фокараның надан булуына ачыну, педагогик борчылулар («гыйлемнән артык байлык, наданлыктан артык фәкыйрьлек юктыр»), фәнни-техник казанышларга ирешергә насыйп булган кеше акылына соклану бар. Әсәрдәге аерым геройларның зур гыйлем иясе булып китүендә төп факторлар итеп автор түбәндәгеләрне билгеләп үтә: гаиләдә хатын-кыз, ана тәрбиясе, «адәм углы өчен иң куәтле тәрбиячеләрнең» берсе булган әдәби-фәнни китапларны тирән үзләштерү һ.б. Автор «Сәлимә, яки гыйффәт» романында иҗтимагый фикерләрне, гаилә һәм тормыш турында мәгърифәтчелек карашларын укучыга җиткерүне максат итеп куя. Әсәрдәге төп каһарманнардан татар шәкерте һәм Иран баеның кызы Сәлимә образлары идеаллаштырып бирелгән, иске һәм соңга таба җәдидләшкән мәдрәсәләрдәге уку-укыту, тәрбия эше киң тасвирланган. Әдип, мәгърифәтчелек карашларына туры китереп, укыган кыз Сәлимәнең татар шәкерте белән чагыштырганда гыйлем, мәгърифәтчелек, һөнәр, сәнгать, телләр белү ягыннан өстенлекләрен күрсәтә. «Хатыннар да ирләрдән ким түгел, тиешле тәрбия алсалар һәм тәртипле мәктәпләрдә укысалар, ирләрне гаҗәпләндерерлек белемле була алалар» дигән карашны расларга омтылыш романның бөтен эчтәлеге уенча дәвам итә. Әсәрдә тормыш өчен дин белеме генә җитми, дөньяви белемнәрне үзләштерү аеруча зарур дигән фикер әйтелә. Чын кеше булу өчен, гыйлем белән бергә, күркәм холык һәм кешелекле булу, яшьләрне халыкка хезмәт итәрлек затлар итеп тәрбияләү өчен мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия ысулларын үзгәртеп кору, алга киткән башка халыклардан өйрәнү, урыс телен дә яхшы үзләштерү зарур, дигән карашны алга сөрә автор. Аның түбәндәге фикерләре бу хакта ачык сөйли: «Дөнья тормышы өчен

дин илә дөнья гыйлемене һәм белмәк лязимдер... Инсан улмак (кеше булу) өчен гыйлем илә күркәм холык кирәктер... Русча яхшы белмәкәндә бунларны мәйданга куймак мөмкин дәгел идеке шөбһәсез». («Сәлимә, яки гыйффәт». Казан, 1899, 19 бит.)

Р.Фәхреддинов «Әсма, яки гамәл вә җәза» романында һәр эшнең һәм җимеше һәм җәзасы булмый калмый дигән идеяне яктырта. XIX йөз мәгърифәтче язучыларның традициясен дәвам иттереп, яхшылык бүләге - бәхет, начар эшләрнең җәзасы - түбәнлек, хурлык дигән идеяне тәэсирле картиналарда сурәтли. Сюжет үстерелешендә баш героиня Әсманың мажаралы язмышы төп урынны алып тора.

Р.Фәхреддинов 1891 елдан алып (1906-1917 елларны кертмәгәндә) 1921 елга кадәр Русия һәм СССРдагы мөселманнарның Диния Нәзарәтендә казыйлык, ә 1922-1936 елларда мөфтилек вазифаларын намус белән башкарды, монументаль тарихи-библиографик мәгълүматлар һәйкәле - «Асар»ны тудырды. Болардан тыш, татар-башкорт халыкларының мәгариф, мәктәп-мәдрәсәләр, милли архитектура (Оренбургтагы Кәрвансарай) тарихы хакындагы бай мәгълүматны халыкка җиткерде. Гомумән, барлык өлкәләрдә дә Риза казый галим-мәгърифәтче һәм халык мәгарифе эшлеклесе буларак танылды һәм эш итте.

Әдип әдәбиятка педагогик күзлектән карап, аңа укучының әхлагын төзәтү коралы, дөньяга карашын баету, фикерен үстерү, тәрбия чарасы итеп карады, мондый әсәрләргә изге бурычлар йөкләде. Туган әдәбиятны мәктәп-мәдрәсәләрдә иҗади рәвештә, балаларны мавыктыргыч итеп укытуны пропагандалады: «Балалалар өчен төлке, әтәч, арыслан, бүре, куян һәм башка, һәм башка кызык кыйссалар вә тасвирлар-романнар тәрҗемә ителсен. Дәрес укып аргач, күңелләрен юатсыннар, аз-аз гына булса да дөньяның рәвешләре, халыкларның тормышлары, дәүләт һәм мәмләкәтләрнең мәшһүрләре вә урыннары өйрәтелсен»[6]. Шул ук вакытта башка бер хезмәтендә гарәп-фарсы әдәбиятларының аерым тискәре сыйфатларын, күренешләрен тәнкыйтьләп үтүне дә кирәк

таба. «Әдәбият ... бер милләтнең холкы сафлыгын күрсәтүче үлчәү булырга тиешле иде, - ди әдип. - Һәр халыкның әдәби әсәрләре бозыклыклардан тыю, аеклыкка гадәтләндерү, начарлыклардан нәфрәт итүгә хезмәткәр булу вазифасын үтәү тиеш иде. Ләкин гарәп әдәбиятыннан боларны көтеп булмый. Дөрес, ике йөз еллардан бирле гарәпләр әдәбиятларына намус һәм тәрбия ысулын куя башлады. Оят сүзләр һәм оят хикәяләрдән башка да яхшы нәрсәләр күп икәнлеген расладылар. Ләкин мең елдан бирле салынып килгән бинаны сүтеп, яңа бина төзү өчен күп тырышлык кирәк»[7]. Галим гарәп-фарсы әдәбиятын шушы рәвештә тәнкыйть итә. Әмма моңа карап Р.Фәхреддинов бу халыкларның әдәбиятларына һәм телләренә кимсетүле караштa торган дигән фикер тумаска тиеш. Киресенчә, мәгърифәтче әдип бу телләрне бик яхшы белгән, бөтен нечкәлекләренә кадәр оста үзләштергән. Бу очракта фикер иясенең күңелен әдәби әсәрләрнең тәрбияви ягы, ул әсәрләрдә халык теле гәүһәрләренең урынлы файдалану мәсьәләсе борчый.

Р.Фәхреддиновның педагогик хезмәтләрендә дини тәрбиягә кагылышлы, Коръән аятләренә таянып эш иткән моментлар да шактый. Авторның мондый карашлары «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» (Оренбург, 1914), «Мәталигы идарәи исламия» («Ислам буенча җитәкчелек итүнең башлангычы») (Оренбург, 1903), «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» (чаралары) (Оренбург, 1907), «Рәхмәте илаһия мәсьәләсе» (Оренбург, 1910) «Коръән вә табәкат» (дәрәҗә) (Казан, 1900), «Ислам дине нинди дин?» («Мирас» журналының 1991 нче елгы 1, 1992 елгы 1-12, 1993 елгы 2-6 саннарында басылган) һ.б. шактый хезмәтләрендә киң чагылыш тапкан.

Әдип яшь буынга аң-белем бирүгә, аның дөньяга карашын киңәйтүгә, гыйлемнең әһәмиятен пропагандалауга аеруча зур игътибар итте. «Нәсыйхәт» китабында урын алган түбәндәге фикерләре моның җанлы мисалы. «Гыйлем күңел күзен ачар, наданлык караңгылыгын бетерер, олуг дәрәҗәләргә ирештерер, дошманнарга каршы корал булыр,

тереклекне саклар, дөнья көтү юлларын белдерер, йорт эчендәге кешеләр белән ни рәвештә булырга кирәк икәнен өйрәтер. Гыйлем галимнәрнең зиннәте вә кешеләрнең хөрмәте булып, угрылардан курыкмый торган байлык вә һич бетми торган байлыктыр... Гыйлеме күп булган кешеләргә карап аз гыйлемле булудан оялмагыз, бәлки белергә кулыгыздан килерлек нәрсәләрне белми калудан оялыгыз. Чөнки гаептер... һәрвакыт белергә мәхәббәт итегез»[8].

Сүз уңаенда шул хакта да әйтеп үтәсем килә: әдипнең «Нәсыйхәт» һ.б. хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итүдә һәм эшкәртүдә тарих фәннәре докторы Равил әфәнде Әмирхановның өлеше гаять зур. Бу хезмәтләр 1994-1999 еллар дәвамында «Мәгариф» журналы битләрендә лаеклы урыннарын ала килә. Шушы изге гамәле өчен без - күп меңләгән укытучылар, галимнәр, ата-аналар мәшһүр галимебез Равил Усман углына тирән рәхмәтлебез.

Р.Фәхреддинов яшьләргә тормыш өчен зарур булган гомуми белемне ана телендә бирүне хуплады: «Без хәзер ана телендә укырга һәм аны белмәүдә гаҗизләрбез. Әүвәл, башлангыч мәктәпләрдә, ана телен белдерүдә камил иҗтиһадыбыз (тырышуыбыз) зарурдыр. Аны белгәннән соң башкаларны белергә ансат булыр. Бер-берсенә юл ачар»[9].

Мәшһүр затның бу тәгъбирләре белем нигезләренең ныклыгы башлангыч мәктәпләрдә уку-укыту эшенең тырышы белән тыгыз бәйләнгән булуын раслый. Автор бик хаклы рәвештә ана теленә зур тәрбия чарасы итеп карый. Үз әсәрләрен иҗат иткәндә дә туган теленең бөтен нечкәлекләреннән оста файдалана, аны гарәп, фарсы, төрек телләре йогынтысыннан мөмкин кадәр азат итәргә тырыша.

Мәктәп-мәдрәсәләрдә бердәм уку планы һәм программалар булмаган, аларда госманлы төрек, яки гарәп-фарсы телләрен укытуга өстенлек бирелгән чорда педагог ана, урыс һәм чит телләрдәге атамалардан киң файдаланып, иҗади рәвештә фәнни терминология нигезләрен эшкәртә башлый, дәреслекләрдә, матбугат битләрендә гади халыкка аңлаешлы сүз-

тезмәләрнең рәсми рәвештә кулланылуына ирешергә омтыла. Ана телен тулы хокуклы тел итәргә тырышу белән бергә, балаларны урыс телен һәм башка чит телләрне тырышып үзләштерергә өнди, халыклар арасындагы үзара дуслык бәйләнешләрен үстерүне хуп күрә, төрле өлкәдә урыс һ.б. халыклардан уңай үрнәкләр алырга чакыра.

Р.Фәхреддинов балаларга нәзари һәм гамәли белем бирү белән бергә, аларда гуманлылык, туган җирен, туган илен, туган халкын ярату, башка халыкларга карата ихтирамлы булу сыйфатларын тәрбияләргә тырышты. «Күге астында яшәдегез, һаваларын иснәп, суларын эчтегез вә икмәкләрен ашадыгыз, - дип язды галим. - Ватан тугрысында малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне жәлләмәгез. Ватан хакына бу илә фидакяр түгел кеше анда яшәмәгә лаек түгелдер. Ата вә анагыз, якын кардәшләрегезне ничек сөяр итсәгез, милләтегезне шу илә сөегез, милләтегез өчен хезмәт итмәке җаныгызны ганимәт (чын күңелдән тоеп) белеңез»[10]. Әдип әдәби әсәрләрендә туган төбәгенең матур табигатен, хезмәт сөюче халкын йөрәк җылысы белән сурәтләде. Аның әдәби әсәрләреннән алынган кайбер өзекләр Г.Тукайның 1911 елда Казанда басылып чыккан «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән хрестоматиясендә лаеклы урынын алды. Г.Ибраһимовның 1917 елда нәшер ителгән «Татар нәхүе» (синтаксисы) исемле хезмәтендә дә күп кенә татар язучылары белән беррәттән Р.Фәхреддиновның гыйльми хезмәтләреннән һәм әдәби текстларыннан өзекләр бирелгән.

Галим яшь буынга хезмәт тәрбиясе бирү мәсьәләсен дә читләтеп үтми. Ул хезмәтне кешене акыл ягыннан һәм әхлакый тәрбияләүдә беренче төп чыганак итеп исәпләде. «Адәм баласы никадәр зирәк вә зур гаиләгә караган һәм дә бай булсын - кулы белән эш эшләү, тир агызып байлык табу - һич тә гаеп булмас вә аны үз дәрәҗәсендә аз гына төшермәс... Алтын - арыслан авызында, аны алыр өчен күп тырышу кирәк», - ди педагог. Ул балаларга яшьтән үк хезмәт тәрбиясе бирергә өнди. Ялкаулыкка,

тормышта бары тик рәхәтлек һәм уен-көлке генә эзләп йөрүчеләргә Риза казый тискәре караштa була: «Эш эшләми тик яту - хәят (тормыш) сугышында булган дошманнарга ярдәм бирү вә анларның галиблекләренә (җиңүләренә) юллар хәзерләү һәм дә анлар тарафыннан тапталу һәм изелүдән гыйбарәт булачактыр... Хәлбуки һәрбер кеше үз кулыннан килгән кадәр эш эшләргә, байлык вә һөнәр һәм дә санагать (индустрия) тугрыларында милләтнең күтәрелүенә ярдәм кылырга тиешле... Җәннәт ачкычлары халыкларның аяк астларында уралып йөриләр, шуларга абына вә сөртенәләр, ләкин шуны күрмиләр, бик ерак җирләргә барып шәм яндырып эзлиләр, ләкин таба алмыйлар»[11]. Шулай итеп, Р.Фәхреддинов хезмәтчән халыкның матур киләчәген тәэмин итү өчен көрәшче шәхесләр формалаштырырга омтыла.

Яшь буынга эстетик тәрбия бирү өлкәсендә дә Р.Фәхреддиновның хезмәте гаять зур. Аның музыкага, рәсем, театр сәнгатенә булган җылы мөнәсәбәте, сәнгатьнең бу төрләрен балаларны тәрбияләүдә файдалануга бәйле эшлекле киңәшләре, тәкъдимнәре шул хакта сөйли. «Көйләр инсаннарны (кешеләрне) үзләренә җәлеп итәләр, халыкларны ерак җирләрдән сөйрәп китерәләр. Ислам дөньясы бу эшне әхлак төзәтү вә гыйффәт (сафлык) тарату хакында вәсилә китерергә тиешле иде. Яшьләрнең көй тыңлау өчен бозык урыннарга йөрү һәм бозык юлдашларга иярү юлларын бикләргә кирәк иде. Бу исә өй эчендә вә гаилә уртасында, карендәш вә кабилә, туган вә тумачалар арасында көйләү вә көйләүне тыңлау гаеп саналмау белән булачактыр. Безнең бу турыдагы хосусый фикеремез ошбудыр»[12], - дип галим халыкның җыр сәнгатен яклап чыкты.

Шигъри әсәрләрне, халык көйләрен, театр сәнгатен тирән аңлаучы мәшһүр зат музыкага булган шәхси мөнәсәбәтен түбәндәге фикерләре ярдәмендә укучыга җиткерде: «Мин үзем музыка тавышын бик яратам, бәгъзе (кайбер) көйләрне озаграк тыңлаганым соңында, хәтта җылыйм, күңелем шул кадәр нечкәрәдер вә, дөньяга килүем

мәсьәләренә кереп, бөтенләй югалам. Үземнең барлыгымнан һич нәрсәм калмый»[13].

Балаларга дөрес тәрбия бирү - ата-ананың изге булычы булуын төшендерү белән бергә бу гамәлнең җәмәгатьчелек эше дә булуын автор түбәндәге сүзләр белән бәян итте «Балаларны изге итү юлы ничек? Изге балалар күктән килмиләр, бәлки гаиләләр эчләрендә җитешәләр. Аның юлы исә...яшь вакытлардан башлап яхшы тәрбия бирүдер. Бу эш ата һәм ана өстендә иң мөһим бурыч... Балаларны яшь вакытларыннан башлап, моһмәл (бәйсез) тоту, бозык кешеләр кулларына бирү, урам балалары берлә йөртү - тиешсез эш. Балалар - һәртөрле язу язылуы кабил булган ак кәгазь вә яки һәртөрле нәрсәнең сурәте күрелергә мөмкин булган көзгеләрдер. Шуның өчен мөмкин кадәр яхшы язу язылу вә мәргуб (әйбәт сыйфатлы) рәсемнәр төшерелү лязим (тиеш). Монларның тәрбияләренә тәмам бирелү, яхшы кеше булып җитешүләре өчен бөтен иҗтиһадны (тырышлыкны) сарыф итү тиешле»[14].

Кыз балаларга һәм хатын-кызларга багышлап язылган «Әһле гыял» («Гаилә») дигән китабында галим яшьләрнең гаилә төзү мәсьәләренә дә җитди игътибар итә: «Гаилә төзү - мәмләкәт тәшкил итү кадәр кирәкле исәпләнгәннән, бу турыда бер төрле тәртип булырга тиештер»[15] Р.Фәхреддинов гаиләдә тормыш-көнкүреш һәм тәрбия мәсьәләрен уңышлы хәл итүдә хатын-кызның зур роль уйнавына, ана тәрбиясенең иң мөһим чыганак булуына әледән-әле тукталa. Шуңа күрә бала анасы булачак затларга аң-белем бирү, аларның әхлакый сыйфатлларын даими рәвештә үстерү, баету, дөньяви белемнәрен камилләштерүне алгы планга куя. Яшь буынның, җәмгыять, милләт язмышының хатын-кызлар кулында икәнлеген ул аеруча 1888 елда Казанда басылган «Китабел-игътибар» дигән хезмәтендә шәрехли. Алга таба әдип 1903 елда Оренбургта «Мәшһүр хатыннар» дигән китабын нәшер итә. Бу хезмәткә 1939 елда академик В.В.Бартольд «Тарихчы-марксист» журналының 5-6 саннарында басылган «Тәүге ислам һәм хатын-кызлар» дигән

мәкаләсендә югары бәя бирде. «Гыйбадәте нисван» (Оренбург, 1912) дигән китабы да әдипнең хатын-кызларга карата нинди җылы мөнәсәбәттә булуын күрсәтә.

1905-1907 елгы революция барча халыкның иҗтимагый фикер үсешенә зур йогынты ясады. Төрки телләрдә беренче газета-журналлар чыга башлау, уку-укыту өлкәсендә җитди үзгәрешләр, педагоглар үсеп чыгу - әдиптә халык мәгарифенең төп мәсьәләренә тагын да җитдирәк караш тәрбияләде. 1905 елның декабрендә мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укыту тәртибен үзгәртү хакында вакытлы матбугат битләрендә бәхәс күтәрелә. Бәхәс дәвамында түбәндәге актуаль проблемалар буенча фикер алышулар үткәрелә: мәктәп-мәдрәсәләрдә мөдирлек вазифасын башкару, ир һәм кыз балаларны укыту, балаларны укырга кабул итү вакыты, имтиханнар, укытучылар җитештерү һәм аларны аерым фәннәр буенча әзерләү, башлангыч классларда ана теле һәм чит телләрне укыту, дәреслекләр, методик кулланмалар тудыру һ.б. ун сорауга җавап бирүдән башланып киткән бәхәс, фикер алышу төрле төбәкләрдән килгән 86 мәкалә сыйфатында 1906 елда татар матбугатында басыла. Р.Фәхреддинов, бу мәкаләләрне бергә туплап, аларга «Шура»да басылган «Тел ярышы» исемендәге язмаларны да (1910) өстәп, 195 битле аерым китап нәшер итә. Китапка 11 биттән торган сүз башын, киң мәгълүматлы белгеч буларак, галим үзе яза. Бу хезмәттә автор бәхәскә карата үз уй-фикерләре белән бүлешә. Алар түбәндәгеләр: мәктәп-мәдрәсәләргә реформа ясауның максаты - фәкыйрь вә ятим балаларны да укыту һәм тәрбияләү; белемле укытучылар әзерләү; мәгариф эшенә җаны-тәне белән бирелгән, күңел куеп эшләүче җитәкчеләр булдыру; мәктәп-мәдрәсә мөгаллимнәренең һәм тәрбиячеләренең халык алдында җаваплылык тойгысы белән эш итүләренә ирешү.

Р.Фәхреддинов күп кенә авылларда бөтенләй мәктәпләр булмауга борчыла, милли мәктәпләргә карата патша хөкүмәтенең реакцион сәясәтен аңлап эш итә. «Милли мәктәпләр өчен дәүләт хәзинәсе белән ярдәм бирелүне өмет итәргә

урын юк», - ди ул һәм шул уңайдан мәктәп-мәдрәсәләрнең укыту-тәрбия эшенең торышы буенча урыс мәктәпләре, гимназияләреннән шактый артта калу сәбәпләрен ачыкларга омтыла. Галим тирән белемле, югары әхлакый сыйфатларга ия булган мөгаллимнәр әзерләүгә, тәрбияләүгә үз хезмәтләрендә аеруча зур урын бирә, алар алдына җитди таләпләр дә куя. «Мөгаллим вә мөдәррис булуның иң зур шарты шул хезмәткә икътидар (көч җитү) булу булса, андан соң шарты да милли халыкның горефләрен, гадәтләрен, гакыйдә (ышану) вә мәсләкләрен (дөньяга карашларын) ихтирам итүдер. Шушы хәл һичвакытта да хәтердән чыкмасын», - ди фикер иясе[16].

Олпат тарихчы аерым хезмәтләрендә мәктәп-мәдрәсәләребезнең гасырлар төпкелендә яшеренгән тарихын да яктырта. Ул чиктән тыш кыен шартларда бөтен күңеле белән балаларның, өлкән яшьтәге кешеләрнең туган телне яхшы үзләштерүләренә ирешергә тырыша. «Телне башлап өйрәтүче беренче дәрәҗәдә әниләр булса, икенче дәрәҗәдәге өйрәтүчеләр ибтидаи (башлангыч) мәктәпләр вә уку китапларыдыр»[17],- дип язды галим. Галимнең түбәндәге фикерләре исә яшь буынны табигый байлыклардан киң һәм дөрес файдаланырга өнди: «Ата-бабаларыбыздан калган бик бәрәкәтле туфракларыбыз, урманнарыбыз булса да, болардан файдалана белмибез. Бу җирләребез вә урманнарыбыз башкаларга китеп торалар»[18]. Әдипне йөз елга якын элек борчыган яшь буынга экологик тәрбия бирү проблемасы бүгенге көндә үзенә аеруча игътибар сорый.

Р.Фәхреддинов укытучыларга, ата-аналарга, балаларга мөһим фәнни-психологик, методик киңәшләр бирү, дәреслекләр, кулланмалар язу белән генә чикләнмәде, бәлки халыкта, милләттәшләрендә олуг кешелек сыйфатлары тәрбияләргә дә омтылды. «Холыклары гүзәл булган милләт мотлака (шөбһәсез) дөньяда өстен вә могтәбәр (хөрмәтле) булачактыр... Гүзәл холыкларның патшасы - тугрылык; хатаны икърар кылу, ягъни тану; вазифаны белү; әдәбе җәсарәтле (батыр) булу, ягъни сүзне ачык сөйләү вә күңелдәге

фикерне катлаусыз бәян итү; хакыйкатьне күзәтү; вакытында эшләү; һәртөрле киртәләргә каршы тору вә үзең хак дип белгән фикереңнән кире кайтмау; үзеңдә ышану көче, хисе булдыру; сафлык, намуслылык; һәр эштә салкын кан белән фикер йөртеп, акыл белән эш итү... Образованный, зыялы булу - урысча киенү вә алтын күзлек асып, таяк тоту яки пычак вә чәнечке белән ашаудан түгел, бәлки ошбу урында зикер ителгән (искә алынган) холыклар белән холыкланудан гыйбарәттер. Образованный (зыялы) дип шундый холыкларга малик (ия) булган кешеләргә генә әйтелергә тиешле, дип беләмез»[19].

Әйтергә кирәк, Р.Фәхреддиновның педагогик карашларында, мәгариф, мәгърифәт, гыйлемгә бәйле, шәхес турында уйлануларында берникадәр каршылыклы, дөрес үк булмаган фикерләр дә чагыла. Әйтик, язучы әсәрләрендә иҗтимагый тормыш берникадәр чагылыш тапса да, тәрбияви тирәлек төшенчәсен ул гаилә һәм мәктәп-мәдрәсә кысалары белән генә чикли. Кешене шәхес буларак формалаштыручы үзәк, аныңча, гаилә һәм мәктәп кенә. Шуның белән бергә, кешенең шәхес буларак җитлегеүендә иң мөһим чорны бары тик балалык вакытына гына кайтарып калдыра. «Сигез-ун яшендә уңган бер бала сигез ел соңыннан бер зур кеше булыр. Бала чагында алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас»[20], - дип яза галим «Тәрбияле бала» дигән китабында. Бу фикерләре белән әдип, безгә калса, тәрбия өлкәсендә берьяклылык күрсәтә һәм иҗтимагый тирәлекне шактый тарайтып күз алдына китерә.

Педагогика фәне алдына куелган бүгенге таләпләр Р.Фәхреддиновның хезмәтләрендә йөз еллар элек үк киң чагылыш тапкан булган. Аның бу өлкәдәге фикерләре педагогика фәнен алга таба үстерергә, камилләштерергә, төрле уку йортларында укытуның сыйфатын яхшыртырга, яшь буынны гуманистик рухта тәрбияләргә, өлкән яшьтәге кешеләрнең, әти-әниләрнең педагогик осталыкларын арттырырга бүген дә зур булышлык итә.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Русия Үзәк тарих архивы. Ф.777, Тасв.4, 116 б.
2. Шунда ук, Тасв.4, №8, 163 б.
3. Казан утлары. - 1984. - №1
4. Ризаэддин Фәхреддин. Фәнни-биографик җыентык: Казан, 1999. - 27 б.
5. Җәвамигуль кәлим шәрхе: Казан, «Рухият» нәшр. - 1999. - 416 б.
6. Татар әдәбияты тарихы. II том: Казан, Таткитнәшр. - 1985. - 321 б.
7. Агыйдел. - 1986. - №3. - 110 б.
8. Мәгариф. - 1999. - №4. - 74 б.
9. Нәсыйхәт. III кисәк. - 1909. - 24 б.
10. Шунда ук. - 23-24 б.
11. Җәвамигуль кәлим шәрхе: Казан, 1996. - 73-74 б.
12. Җәвамигуль кәлим шәрхе: Казан, 1916. - 144 б.
13. Шунда ук.
14. Шунда ук. - 146 б.
15. Әһле гыял: Оренбург, 1902. - 2 б.
16. Җәвамигуль кәлим шәрхе: Казан, 1996. - 297-298 б.
17. Шура. - 1914. - №23. - 706 б.
18. Шунда ук.
19. Җәвамигуль кәлим шәрхе: Казан, 1996. - 135-140 б.
20. Тәрбияле бала: Казан, 1889. - 17 б.

И.Б.Бәширова

ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ҺӘМ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИНОВ ИҖАТЫ

Р.Фәхреддиновның тууына 130 ел тулуга багышланган фәнни конференция 1989 нче елның 13 февралендә үткәрелгән иде. Шул конференциядә «Р.Фәхреддинов прозасының теле» дигән чыгышка хәзерләнгәндә, китапханәбезнең иске китаплар саклана торган «чорма»сында озак вакытлар кичергән идем. Шул вакыт Р.Фәхреддиновның әхлак-тәрбия мәсьәләләренә караган хезмәтләрен, «Шура»-да басылган мәкаләләрен һәм «Асар»ның томнарын укып, аңларга тырышкан идем. Дөрес, ул вакытта инде әдипнең сәнгатьле чәчмә әсәрләре кириллицада дөнья күргән[1], 125 еллыгы белән бәйле рәвештә, аның тормыш юлы, иҗаты, шәҗәрәсе, кулъязмалары хакында күләмле фәнни мәкаләләр басылган иде[2]. Инде ун-унбиш ел вакыт үтеп тә киткән, кызганыч ки, конференция материаллары аерым җыентык булып дөнья күрә алмады, әмма Р.Фәхреддиновның тарихка, әхлак һәм дини мәсьәләләргә караган хезмәтләре журнал битләрендә дә, аерым китаплар булып та басылып, укучыларны куандырды, галимнең бу өлкәдәге эшчәнлеге фәнни-объектив бәяләнде[3]. Шулай булуга да карамастан, бу чыгышны хәзерләгәндә дә «чорма»да утырырга мәҗбүр идем, чөнки атаклы галимнең иҗат мирасы тулаем һаман да киң укучыга җиткерелә алганы юк. Яңадан басылган хезмәтләре дә, нигездә, хәзерге татар әдәби теленә күчерелгән, тәрҗемә ителгән иде.

Мәгълүм ки, XIX гасыр ахыры - XX йөз башында язылган текстларның күбесе хәзерге укучыга авыррак аңлашыла, шуңа күрә аларны яңадан басмага хәзерләгәндә, сирәк кенә искәрмәләр булса да, гадәт буларак, хәзерге татар әдәби теле нормасына салалар[4]. Шулай итеп, гарәп графикасын укый алмаган укучыга текстның эчтәлеге белән танышырга мөмкинлек тудырыла. Бу юнәлештә эш алып бара торган текстологлар, тарихчы, әдәбиятчы, телче

галимнәр бик зарур булган, мактауга лаек хезмәт башкаралар, күп көч-егәр сарыф итеп, язма мирасыбызны хәзерге укучыга кайтаралар. Ләкин гарәп имлясында язылган текстларны хәзерге әдәби нормада укучыга тәкъдим иткәндә, түбәндәге хасиятләр тормышка ашырылмый кала: беренчедән, иҗатчы-авторның телдән файдаланганындагы тулаем эшчәнлеге күренә алмый һәм шуңа күрә, икенчедән, әсәр иҗат ителгән вакыттагы әдәби телнең табигате һәм вазифасы объектив рәвештә аңлатыла, күз алдына китерелә алмый. Аерым әдипләрнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны, аларның колачлы хезмәтенең тарихы, әдәби, сәяси әһәмияте объектив бәяләнеп язылган, шуңа күрә һәр яктан әһәмияткә ия булган мәкалә-хезмәтләрдә аерым авторның теле турында хакыйкатькә бик үк туры килеп бетми торган фикерләр әйтелә тора. Мәсәлән, академик М.Госманов Ризаэддин бине Фәхреддиннең тарихчы, археограф, журналист, педагог, әдип, ориенталист, теолог, дини философ буларак күп кырлы эшчәнлеген, бай мирасын яктырткан хезмәтендә тел үзенчәлеге хакында болай дип яза: «...Р.Фәхреддинов исә, киң масса укучылар ихтыярын игътибарга алып, башта үзе идеал иткән корамачалыктан да, бер ара мавыккан төрекчелектән дә баш тартты...»[5].

Р.Фәхреддиновның «Болгар вә Казан төрекләре» хезмәтен хәзерге графикага күчерүдә катлаулы эш башкарган Ә.Хәйруллин әлеге әсәрнең теле хакында болай белдерә: «Р.Фәхреддинов язмаларының теле ничек кенә шома булса да, аларда әле бүгенге укучы өчен шактый кыен урыннар бар. Чөнки ул чордагы әдәби тел чаралары бүгенге әдәби тел чараларыннан шактый аерылып тора. Бу гаҗәп тә түгел, ул чордагы уку йортларында гарәп, фарсы, төрек телләре бик төпле укытылганлыктан, шул телләрдән кергән сөйләм телендәге чуарлык язма телгә дә тәэсир ясаган. Ул үзенең әсәрләрен ана телендә, үзе әйткәнчә, төрки телдә яза...»[6].

Яисә менә Ф.Кәриминең «Морза кызы Фатыйма» исеме белән басылып чыккан сайланма әсәрләренә язылган

кереш мәкаләгә игътибар итик. М.Гайнетдинов үзенең әлеге мәкаләсендә татар филологиясендә беренче мәртәбә Ф.Кәриминең шәхесе, аның татар халкы, әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында тоткан урыны хакында объектив мәгълүмат бирә, әдип турында ничек язылырга тиешлекнең үрнәген күрсәтә алган. Әмма шул ук вакытта ул болай дип белдерә: «Ф.Кәриминең дөньяга карашында махсус тукталып һәм аңлатып үтүне сорый торган «үтә каршылыклы» ике момент бар... Икенче момент - Ф.Кәрими әсәрләренең теле. Ул да бу чор әдәбиятында үзенчәлекле һәм каршылыклы бер күренеш: халык сөйләм теленә якынайтылган яңа әдәби телебез дә, гарәп, фарсы алынмалары белән бизәкләнгән борынгы әдәби «төрки» дә түгел. Икенчесеннән беренчесенә күчүнең кайсыдыр бер этабы дип тә булмый аны...»[7].

Төрле хезмәтләрдән китерелгән әлеге фикерләрдә бер уртаклык бар: ике әдипнең дә әсәрләре теленә гомумән алып бәя бирелә, аерым жанр-стильләргә бүленеп каралмый, үлчәмле фикер әйтелә алмый. Яки менә Адилә Айданың «Садрый Максуди Арсал» исемле хезмәтендә, «Хисамеддин менла» әсәрен «Казан төрекчәсе илә язылмыш бер әсәр улмадындан, Казан төрекләренең әдәбияты тарихында йир алаҗак нителекле дәгелдер. Акъегетзадә хикәясене Истанбул төрекчәсе илә язмага йелтенмеш фәкать йөзене гүзене булаштырмыштыр. Әсәрдәге дил нә Истанбул төрекчәседер, нә дә Казан төрекчәседер», - дип белдерә әдибә һәм шуның белән «Садрый Максуди «Мәгыйшәте»не Казан төрекчәсе илә язмыштыр», шуңа күрә әлеге әсәр генә Казан татарларының беренче язма истәлеге булып саналырга хаклы дип әйтәсе килә[8].

Әлеге фикерләр юнәлешендә тагын классик иске татар әдәби теленең берникадәр дәрәҗәдә башкорт, казакъ һ.б. халыкның җанлы сәйләмә формалары белән аралашкан вариантлары белән язылган текстларны фәкать «үзебезнеке» генә дип саналу күренешләрен дә әйтеп үтәргә мөмкин булыр иде[9].

Менә шул рәвешле, йөз еллар элек язылган текстларның тел үзенчәлеге хәзерге әдәби тел күзлегеннән чыгып, ягъни әдәби телнең җанлы сөйләмә нормада гына булырга тиешлегеннән карап бәяләнә һәм чынбарлыктагы хәл ачылмыйча, шул вакытта иҗат иткән аерым шәхесләрнең милли әдәби мирасыбызда тоткан урыннары тарихи дөреслегенә тәңгәл китерелмичә кала. Хикмәт нәрсәдә соң? Хикмәт шунда ки, хәзерге татар әдәби теленнән аермалы буларак, XIX гасыр ахыры - XX йөз башы татар әдәби теле, язма-төрки һәм сөйләмә-татар нормаларының бәйләнеш-мөнәсәбәтенә нигезләнгән, берничә вариантта хәрәкәттә яши.

«Нур» вә башка газета һәм шулай ук «Шура» журналы битләрендә кузгалган тел бәхәсе, тел ярышы вакытында әлеге вариантлар түбәндәгечә билгеләнә: 1) иске татар әдәби теленең дәвамы булып, әдәби тел дип аталганы, 2) «Тәрҗеман» газетасының теленә якын булган, җәдиди госманлы һәм 3) татар халкының гомумсөйләмә сүз һәм сүзформалары белән аралашкан һәм алар өстенлек иткәнгә, гамәли-гавамлашкан төрләре «Нур», 1905, №4-13).

Бу вакытта иҗат иткән әдип һәм шагыйрьләрнең, галим һәм публицистларның әсәрләрен укып бару уңаенда, аларның кайсы укучыга (гомумтөркиме әллә татармы) багышлап, нинди максатны күздә тотып язуларына карап, әлеге вариантларның һәр өчесе белән дә иркен файдаланулары күзәтелә. Шулай итеп, иске татар әдәби теленең дәвамчылыгы булып торган параллель формаларның кулланылу үзенчәлеге күрсәтелгән чорда яңа этапка керә. Әлеге вариантларның үзләре генә үти торган вазифалары ачыклана: гомумтөрки укучыга адресланган әдәбият традицион язма нормаларга нигезләнә, татар укучысына дип язылган текстларда халыкның җанлы сөйләмә формалары мул файдаланыла. Әлеге сайланыш Г.Чокрый, М.Акмулла, З.Бигиев, Р.Фәхреддинов, Ф.Кәрими иҗатларында бигрәк тә ачык чагылыш таба[10].

Менә - «...әдәбият тарихын өйрәнүдә бәяләп бетергесез кыйммәтле чыганак булган», 1898-1899 нчы елларда язылган

күп томлы «Асар». Р.Фәхреддинов әлеге хезмәте белән мәшһүр галим Ш.Мәрҗани башлаган био-библиографик пландагы *гарәп телендә язылып* (ассызымы безнеке - И.Б.) бара торган эшне дәвам иттерә. Ул әлеге хезмәтен Диния Нәзарәтенә казый итеп сайлангач яза башлый: архивтагы күп санлы кульъязмаларны тәртипкә китерә, архивта булмаганнарын үзе туплый[11]. Бу язмаларның күбесе имам вә мөдәррисләрнең эшләренә һәм тормышларына караган материаллар, ягъни эшчәнлекләре турыдан-туры гарәп-фарсы-төрек теле белән бик нык бәйле шәхесләр хакында була. Автор хезмәтенең атамасын болай дип тәфсилләп-аңлатып куйган: «...мәмләкәтемездә улан ислам галимләренең вә мәшһүр кемсәләрнең тәрҗемә вә табаигълары, тарихы валәдат вә вафатлары вә башка әхвәлләре хакында язылыш китабдыр. Сахибе Ризаэддин бине Фәхреддин»[12].

Мәгълүм булганча, био-библиография традицион ныклы схема-калып нигезендә языла: галимнең тулы исеме, туган вә вафат еллары, кабер ташындагы язуы; остазлары, шәкертләре, хатыннары, балалары, тугмалары; әлеге шәхеснең эшләгән эшләре, язган китаплары, аның хакында могтәбәр кешеләр тарафыннан әйтелгән мактау сүзләре; сәяхәте, нигездә хаҗ сәфәре вакытында язган мәктүб-хатлары. Күргәнебезчә, Р.Фәхреддинов «Асар»ын язганда, күп кенә әзер текстны, әзер «тел»не үзгәртмичә теркәргә тиеш була. Димәк, әлеге хезмәтнең жанры, аның үзенчәлекле материалы татар халкының җанлы сөйләмә телендә бирелә алмый, бәлки традицион китаби классик искетатар әдәби телендә, аның да гарәп-фарсы алынмалары шул кулланыла торган вариантында гына язылырга тиешлеген күрсәтеп тора. Шушы җәһәттән «Р.Фәхреддиновның гомумән татар тарихчысы буларак түгел, бәлки культура һәм мәгариф тарихчысы сыйфатында каләмгә тотынуы да...» аңлашыла. Шулай булса да, әлеге хезмәтнең соңрак елларда басылган өлешләрендә тел берникадәр гадиләшә кебек: алынмалар кими төшә яисә җәя эчендә аңлатыла, җөмләләр җыйнаклана, галимнең исем

шәрифе кыскарак бирелә, вафаты да һиҗри белән генә түгел, миляди белән дә күрсәтелә башлый. Мәсәлән, «Харис бине Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрле. Уфа төбәгендәге Эстәрле баш карьясында имам вә мөдәррис улыб, ике йөз сиксән йиденче (1287-1870) йыл 2 нче шәгъбан (ноябрь) вафат итде...»[13].

«Асар» белән бер үк вакытларда язылган «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала», «Тәрбияле хатын», «Нәсыйхәт» һәм күп санлы дидактик-педагогик хезмәтләрнең барысы да диярлек ачык ана телемездә язылмыштыр: «...Алтындан бәһале, оҗмах нигъмәтләрендән кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата вә ана өчен тәрбияле бала дәрәҗәсендә олуг байлык һич булмаз. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык вә ахирәттә йөзгә аклык китерер». «...Атам вә анам шадлансын, кешеләр дә бәңа рәхмәт әйтеб, бәне күчергеч идеб сүзләсеннәр дигән баланың барчасын тәрбияле бала илә белерләр...». «...Барча кешеләрне дөньяга китерүчеләр аналардыр, буны үзеңез һәм ачык беләсез. Ләкин бу кешеләрнең каюсы усал, каюсы яхшы, каюсы әдәбле, каюсы әдәбсез, каюсы белүче, каюсы белемсез улмакдалардыр. Халык (кешеләр вә адәм балалары)ның яхшы вә усал улмакларында күп вакытда аналарның һәм катышы уладыр. Тәрбияле аналарның балалары күп вакытта яхшы вә тәрбияле уладыр, бозык вә тәрбиясез аналарның балалары күп вакытта усал вә тәрбиясез уладыр...»

Әлеге хезмәтләрендә автор укучыга аңларга авыр була дип уйлаган күп кенә сүзләргә өстәмә аңлатма бирә: я текст эчендә, яисә астөшермә итеп, аерым сүзләрнең синоним парларын китерә: халык - кешеләр вә адәм балалары, сәгадәт - изгелек вә рәхәтлек вә бәхетлелек, мәдех - мактамак вә үкмәкдер, әҗер - йал, хак, сачләре - чәчләре, табиблар - докторлар, хәстә - рәнҗү, дару - дәүә, хальләрене - мәзах, табигатьне, көйсезләнүче - бимаза итдерүче, күстәрмәзләр - күргезмәзләр, күрсәтмәсләр, гүзәл - чибәр, матур һ.б.[14]

Шулай итеп, бөек мәгърифәтче Р.Фәхреддинов ана һәм бала тәрбиясенә багышланган хезмәтләр ачык, саф ана телендә язылырга тиеш дип ышанган һәм аның үз хезмәтләре әлеге изге эшнең матур үрнәге булып тора. Галимнең дини-теологик хезмәтләренең теле дә, нигездә, шушы тәртиптә бара. Мәсәлән, «Җәвамигуль кәлим шәрхе»дә: «...Аллаһе Тәгалә хәзрәтенә иң күб шөкер итүче кеше - адәмләргә шөкер итүче кешедер. Шөкер - Аллаһега шөкер диб, коры сүзләр тәкрарлаб йөрүдән гыйбарәт түгел. Галимләр сүзләренә күрә шөкер: 1) нигъмәтне бирүче кем булса, шул нигъмәтне бирүчедән хасил булганлыкны белү, 2) һәм дә аны бирүе ичүн күңелдән шадлану, 3) вә шул нигъмәтне тиешле булган урынында истигъмаль кылу өч нәрсәдән гыйбарәтдер: Аллаһе Тәгаләгә шөкер итү һәм дә хакыйкий шөкер ошбудыр, әмма бәндәләргә каршы булган шөкер анларның изгелүк кыйлуларыны белү вә шуңа каршы сәна кыйлу вә хөрмәт күрсәтүдән гыйбарәт. Нигъмәт бәрабәренә шөкер итү, яхшы эшләргә каршы мөкафәт кыйлу әхлакый эшләрдән булган кадәр иҗтимагый вә гомраный эшләрдән булып, монларны тиешле урынларында кыйлмый калдыру зур фәсадләргә сәбәб буладыр...»[15].

Тарихи һәм педагогик эшчәнлеге белән беррәттән Р.Фәхреддинов татар әдәби теленең имля һәм мәгариф мәсьәләләренә караган фәнни-гамәли чараларда да актив катнаша. Мәсәлән, төрки-татар телен төзәтүгә багышланган беренче Гыйльми мәҗлес Уфада, 1899 нчы елда үткәрелә. Анда яңа чор мәктәпләре өчен программалар төзелә һәм имля берләштерү турында карар кабул ителә. Карар унөч пункттан гыйбарәт булып, төп таләп болай куела: «Русия төркиләре өчен Казан шивәсе лисанын гомуми ителеп кабул итәргә, фәнни вә истыйляхи мәгънәләр өчен истыйляхәте гарәбине кабул итәргә...» Атна буена дәвам иткән бу мәҗлескә кырык-иллегә якын мөгаллим һәм галим-голәмә җыела. Монда, Г.Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә: «...Шул вакытның татар язучылары (Һади Максуди, Фатих Кәрими, Рәшид

казый, Риза казый, Бубилар һ.б.) белән җәмәгать хадимләре халык арасына аң-белем тарату эшләрен карадылар»[16].

Әлеге аң-белем тарату эше татар телендә беренче газета-журналлар басылырга мөмкинлек ачылгач тагын да кискенләшә, «...милли аң, үз-үзеңне танып белү, шунан чыгып милли әдәби тел мәсьәләләрен хәл кылу» көч-куәт ала. «Нур», «Йолдыз», «Әхбар» һ.б. газета битләрендә берничә ел буена шаулап бара торган әлеге катлаулы мәсьәләне бер сукмакка төшерергә өндәп, «Шура» журналында рәсми игълан басыла (1909, №15). Игъланны Р.Фәхреддинов яза: «...Ана телемезнең рәваҗ вә тәрәккыйсына укучы вә язучыларның гайрәт вә хиссалары артуына сәбәб улсын өчен, «Шура» идәрәсе кәлям мөсабәкасы ачарга карар вирде. Ошбу мөсабәка, идарәгә махсус буларак, 20 юлдан аз вә 40 юлдан күб улмас шарты илә, нә тугрыда улса да улсын, һич бер чит сүз катыштырмый халис вә саф төркичә бер мәкалә язмакдан гыйбарәтдер. Килмеш мәкаләләр идарәдә тәдкыйк иделенер».

Ана телебезнең таралуына вә үсешенә укучы һәм язучыларның көч вә өлеш-мөмкинлекләрен арттыру максатын күздә тотып башланган сүз, асылда, шул юнәлештә дәвам иттерелә. Кәлям мөсабәкасына (сүз, сөйләм, тел ярышына) бик күп җавап-мәкаләләр языла, «Шура» журналына басыла алмыйча калганнарын Р.Фәхреддинов аерым китап итеп чыгара (1910)[17].

Игъланның текстыннан күренгәнчә, Р.Фәхреддинов баш мәкаләне, әлеге журналда басылып килә торган күп санлы башка мәкаләләр кебек үк, иске татар әдәби теленең җәдиди госманлы дип атала торган, берникадәр төрекләшкән вариантында язган, чөнки шулай итеп язу гына «Шура» журналы каршында торган асыл максатка, ягъни барлык төрки халык та укысын, бертигез дәрәҗәдә аңласын, үзенең мөнәсәбәтен белдереп, мәкалә язсын, дигән максатка туры килгән.

Р.Фәхреддиновның бу өлкәдәге эшчәнлеге традицион әдәби телебезнең кочагында яңарышның-халыклашуның ничек

итеп борынлавын һәм, иң мөһиме, әлеге процессны теоретик яктан нигезләнүнең беренче адымнары ничек булганлыгын күрергә мөмкинлек бирә. Мәкаләләрнең күбесендә төп бер фикер кабатлана: китапларыбызда гарәп-фарсы алымнары күп булганга, халык аңламый, нәтиҗә ясала: барлык төрдәге әдәбиятны халык сөйләшә торган тел белән генә язарга кирәк. Халыкка аңлаешсыз итеп язуда хәзрәтләр дә гаепләнә.

Менә шушы шартларда авторлар бер-берсенең мәкаләләреннән гарәп-фарсы сүзләрен санап күрсәтә башлыйлар. Әлеге ярышны «тиле ярыш» дип әйткән вакытта Г.Тукай менә шушы моментны күздә тоткан булса кирәк. Мәгълүм ярыштагы бу «тилелек», күпмедер дәрәҗәдә, татар теле гыйлемендә инде күтәрелгән һәм эшкәртелгән кайбер теоретик фикерләрне искә алмаудан да килгән дип әйтергә мөмкин. Билгеле булганча, XX гасырның беренче ун еллыгында, ә элегрәк М.Иванов, С.Кукляшев, Н.Ф.Катанов хезмәтләрендә, эзлекле бер фәнни системага салынса да, телдән файдалануда традицион-язма жанрларның, халык авыз иҗаты әсәрләренең һәм шулай ук көндәлек-гамәли җанлы сөйләмнең үзенчәлекләрен күрсәтә торган, хәзерге көндә функциональ стильләр дип аталып йөртелә торган бүленеш инде шактый сизелерлек булып тикшерелгән, өч стиль теориясе дә яшәеш алган була.

Күп төрле фәннәр буенча китаплар язган галим К.Насыйри да, һәрбер фәннең үз теле, үз терминнары булырга тиешлегенә инанган һәм шуңа басым ясап, «...һәрбер фәннең үзенә махсус истыйляхы бардыр вә үзенә махсус теле бардыр...», «... мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөддәтдә үгрәнгән теледер, икенчесе дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер» дигән, ягъни әлегәчә фәннилеген югалтмаган тезисларын биргән була. Менә шушы фонда: «...нә тугрыда улса да улсын, һич бер чит сүз катыштырмай халис вә саф төркичә бер мәкалә язмак» дигән максатны төгәл үтәүгә булган омты-

лыш, әлбәттә инде, изге ният белән башланган эшне берникадәр көлкегә әверелдерә. Бу хәлгә Г.Ибраһимов та игътибар итә: «...Садә язу, татарча язу дип, бөтенләй таралышып беткән чит сүзләрне алыштырырга омтылу да урынсыздыр...». Әлеге тел ярышында беренче урынны алган М.Гафури да шушы ук фикерне куәтли: «...бу сүзләр үз сүземез кеби булган, әдәби телемездә урын алган...».

Шулай итеп, әлеге тел ярышында, киң демократик планда, тел һәм сөйләмнең бик катлаулы үз кануннары булуы икърар ителә, күп кенә сүзләрне, алынма дип әйтеп, чыгарып ташларга, яисә үзеңнеке булганы өчен генә кулланышка кертеп җибәрергә мөмкин булмавы ачык күренә. Бу вакытта әдәбиятның төрле жанр-стильләргә бүленүе, ягъни әдәби тел белән языла торган текстларның, нинди максатны күздә тотып һәм кайсы укучыга атап язылуларына, нинди вазифа үтәүләренә карап, телдән файдалану да төрлечәрәк булырга мөмкин дигән мәсьәләгә теоретик яктан өйрәнү объекты буларак куелмый, барлык энергия халыкның җанлы сөйләмен, аның үз сөйләмә байлыгын хәрәкәткә китерүгә, ягъни язма китап теле итеп тә күтәрүгә, шуңа инандыру-ышандыруга юнәлдерелә, чөнки әлеге фикергә каршы торучы көчләр дә, мәгълүм булганча, бик куәтле була.

Нәкъ менә әлеге тел бәхәсләре тәэсирендә булса кирәк, күп кенә классикларыбызның 1912-1914 нче елларда язылган әсәрләре аларның башлангыч (1907-1909) чорларындагы иҗатлары белән чагыштырганда, тел һәм шигърият ягыннан сизлерелек рәвештә халыклаша, халыкның җанлы сөйләме рухы белән баетыла, халыкча сүз теземе, җөмлә төзелеше-интонациясе белән яңара. Әйтик, Ш.Камалның 1909 нчы елда «Шура»да басылган «Уяну» хикәясе «Хикәяләр төркеме» (1914) җыентыгындагы вариантыннан күләме ягыннан да ике мәртәбә диярлек артык, җөмлә төзелеше һәм сүз сайланышы ягыннан да иске татар әдәби теленең көчле йогынтысында.

Р.Фәхреддиновның үзенең дә дидактик хезмәтләренең теле тагын да сизелерлек халыклаша: төрек теле алынма-

ларының күпчелеге татар теленең үз сүзләре белән алмаштырыла: улган-булган, вирелгән-бирелгән, бәңа-миңа, еш кабатлана торган ушандак сүзе кулланылмый, төшереп калдырыла. Ләкин Р.Фәхреддинов, каләмдәше Ф.Кәримидән аермалы буларак, үзенең сәнгатьле чәчмә әсәрләренең телсөйләм рәвешен тулаем җанлы-гавами вариантына күчереп бетерми, үзенең тәнкыйтьчеләренә[18] болай дип җавап бирә: «... «Сәлимә»не мин үз кавемемез арасында хикәятләр вә романлар йулыны ачу касды илә тәртиб итмәдем. ...үз кашымда бик әһәмиятле вә бик гали бер-ике төрле мәгънәви вә рухани максудым бар иде, шул максудларымны йиренә йитешдерергә сәбәб улмазмы дип, мин шул «Сәлимә»не һәм аның тиңдәше булган «Әсма»ны йаздым. ...Болар минем йәш вакытымның йадкярлары һәм дә эчемдәге зар-моңларымны, хәсрәт-кайгыларымны уртаклашкан сердәшләремдер, шул әсәрләрдә (әсәр исемләрене бирү ярамаса, шул нәрсәләрдә) булган кимчелекләрне күрсәтүчеләргә каршы сүз сөйләүне артык нәрсә хисаб итәм...»[19].

Шулай да Р.Фәхреддинов әлеге әсәрләренең сәнгатьчә яңгырашына игътибар итмәгән дип әйтеп булмый. Әдипнең бу төр прозасы, сурәтләү чараларыннан башка, үзенчәлекле поэтик синтаксисы белән дә аерылып тора. Уңай итеп, ягъни авторның әйтергә теләгән фикерен укучыга илтеп җиткерүдә төп көч итеп сайланган персонажларны сурәтләгәндә, анафорик һәм эпифорик кабатлаулар билгеле бер ритм-көй, чәчмә сөйләмнең сәнгатьле яңгырашын, әдипнең мәрхәмәтле мөнәсәбәтен тасвир итү чарасына әвереләләр. Кабатлаудагы эзлеклелек фикернең әйтү рәвешен матурайта-бизи, сөйләмнең тәэсир көче, тойгылылык көче арта. Эмоциональ кичерешләрне сурәтләп бирүдә хәзерге көндә дә яратып кулланыла торган поэтик сиктаксисның төп алымы булган сүз, тәгъбир, җөмләләрне кабатлап сурәт ясау үзенчәлегенең башлангыч үрнәкләре белән без Р.Фәхреддиновның сәнгатьле чәчмә әсәрләрендә очрашабыз. Ә инде әлеге әсәрләрдәге мәдәни-педагогик, тарихи-информатив белем бирә торган урыннары Р.Фәхреддиновның фәнни мәкалә-

хезмәтләренең теленнән бер нәрсәсе белән дә аерылмый: гарәп-фарсы алынмалары шактый күп, шулай ук гомумтөрки язу нормаларының китаби традицияләре дә дәвам иттерелә: угыз-төрки формалары шактый актив. Әмма персонажларның хис-кичерешләрен яисә аларның төс-кыяфәтләрен тасвирлауга күчү белән, татар әдәби теле, үзенең барлык традицион мөмкинлекләрен сакланган хәлдә, «...язу тарызын садә вә гүзәл итеп»[20] ясый торган шигъриятле чаралар белән бергә үрелә.

Шулай итеп, танылган мәгърифәтче-педагог һәм әдип, тарихчы-галим һәм журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Р.Фәхреддинов үз чоры әдәби теленең өч варинаты белән дә иҗат иткән: «Асар»ында гарәп-фарсы теленең һәм борынгы төрки телдән үк килә торган язма китаби традициясе нык саклана. «Шура» журналында эзлекле рәвештә басылып килә торган күп санлы мәкаләләрнең барысында да төрекчелек тәэсире сизелә. Ә инде аналарга нисбәт итеп язылган дидактик хезмәтләре әнә шул аналар сөйләшә торган көндәлек җанлы сөйләмә тел белән иҗат ителә. Сәнгатьле әсәрләрнең теле дә әлеге сөйләм рухы белән баетыла[21].

ИСКӘРМӘЛӘР.

1. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860-1905) - Казан: Таткитнәшр., 1979.

2. Госманов М. Катлаулы чорның каршылыклы вәкиле//Казан утлары, 1984, - №1. - 142-157 б.; Хәйруллин Ә. Галимнең кульязма мирасы//Казан утлары, 1984, - №1 - 157-162 б.; Әхмәтҗанов М. Риза Фәхреддинов шәҗәрәсе //Казан утлары, 1984, - №1. - 164-168 б.; Рахимкулова М. Просветитель. К 130-летию Ризы Фахрутдинова//Южный Урал (Оренбург). - 1989, 4 янв.

3. Фәхреддинов Р. Ислам дине - нинди дин?//Мирас, 1991. - №1; 1992. - №№1-12; 1993. - №2-6; Нәсыйхәт. Ялгыз кыз балалар өчен//Мәгариф. - 1992. - №6-12; 1993. - №2-4; Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр//Мирас, 1993. - №8-11; 1995. - №1-6; Болгар вә Казан төрекләре. - Казан: Таткитнәшр., 1993. - 187 б.; Казан ханлыгы тарихыннан//Мирас, 1995. - №1; 1996. - №11-12; Бөек Болгар дәүләте тарихы//Мирас, 1995. - №9-10; 1997. - №10; Әмирхан Р. Риза Фәхреддинов - тарихчы//Мирас, 1992. - №12. - 64-73 б.; Әмирхан Р. Бөек галимнең мәшһүр адәмнәре//Мирас, 1997. - №10. - 79-94 б.; Баишев Ф.Н. Общественно-политические и нравственно-этические взгляды Ризы Фахреддинова. - Уфа: Китап, 1996. -

176 с. (Бу хакта Раиф Мәрданов төзегән библиография // Ризаэтдин Фәхретдин. Фәнни-библиографик җыентык. - Казан: «Рухият» нәшр., - 1999. - 204-209 б.).

4. Бигиев З. Зур гөнаһлар. Романнар, сәяхәтнамә. Төзүчесе, төп текстның транскрипциясен һәм хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсен эшләүче, искәрмәләр һәм сүз авторы Р.Даутов, - Казан: Таткитнәшр., 1991. - 382 б.; Атласов Һ. Сөен бикә, Казан: Типо-литография «Умидъ», 1914. - 62 б. Репринт басма. М.Госманов, редакция һәм соңгы сүз, Казан, 1992. - 74 б.

5. Госманов М. Күрсәтелгән хезмәт, 151 б.

6. Хәйруллин Ә. Кереш сүз//Ризаэддин Фәхреддинов. Болгар вә Казан төрекләре. - Казан: Таткитнәшр., 1993. - 17-18 б.

7. Гайнетдинов М. Кереш сүз//Фатих Кәрими. Морза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр. - Казан: Таткитнәшр., 1996. - 26-28 б.

8. Айда Адилә. Садрый Максуди Арсал. - Анкара: Культур Баканлыгы, 1991. - 23-25 б.

9. Фасеев Ф.С. Старотатарская деловая письменность, - Казань, 1981. - С.36-39; Закиев М.З. Введение: койне, традиционные нормы, старотатарский и современный татарский литературные языки. Истоки татарского литературного языка. - Казань, 1988. - С.8-9.

10. Бәширова И. XX гасыр башы татар әдәби теле һәм аны өйрәнү ысулларына карата//Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихлары: традицияләр һәм заман. 1 том. - Казан, 1992. - 141-144 б.

11. Ахметгалиева Я. Архив Р.Фахрутдинова в Ленинградском отделении Института востоковедения АН СССР//Исследования по лексике и грамматике татарского языка. - Казань, 1986. - С.132-146.

12. Фәхреддинов Р. Асар, икенче җилд, тукызынчы җөзьэ. - Оренбург: Тип-фия М. - Ф.Г.Каримова, 1904.

13. Фәхреддинов Р. Асар, 2 җилд, 15 җөзьэ. - Оренбург: Тов-во «Каримов, Хусаинов и К°», 1909. - 505 б.

14. Фәхреддинов Р. Тәрбияле бала. Ачык ана дилемездә йазылмышдыр. - Казань: Типо-лит-фия насл-ов М.Чирковой, 1898; Тәрбияле ана. Ачык ана телемездә йазылмышдыр. - Казань: Типо-лит-фия ун-та, 1898.

15. Фәхреддин Р. Җәвамигуль-кәлим шәрхе. - Казан: Таткитнәшр., 1989. 1916 елгы Оренбург басмасыннан фотога алу юлы белән басылды. - 552 б.

16. Ибраһимов Г. Мәсьәлә чишелде//Г.Ибраһимов, Әсәрләр, Сигез томда, 8 том. - Казан: Таткитнәшр., 1987. - 197 б.

17. «Шура»ның тел ярышы. Мөрәттибе: Ризаэддин бине Фәхреддин. - Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1910.

18. Кубкинский (Оренбург). «Сәлимә, яки гыйффәт» // Шура, 1917. - №23-24.

19. Шунда ук.

20. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда, 5 том, Истәлекләр, юлъязмалар, хатлар (1902-1913). - Казан: Таткитнәшр., 1986. - 116 б.

21. Бәширова И.Б. Ризаэтдин Фәхретдинев һәм татар әдәби теле// ТДГИ. Гыйльми язмалар - Ученые записки, №4. -Казан, 1998. - 79-92 б.

М.В.Гайнетдинов

РИЗА ФӘХРЕДДИНОВНЫҢ ИҖАТ ПАФОСЫ

Риза Фәхреддинов, яңа татар әдәбиятының чәчәк ату чоры башланган көннәргә, 1905 елларга, 45 яшьлек ир уртасындагы танылган хәзрәт, атаклы казый буларак килеп керә. Шул көннәрдә үк, бу могътәбәр эшлеклебезгә бүген дә көчен саклаган мөнәсәбәтнең тотрыклы калыбы формалаша. Яшь көчләр аны хөрмәт итәләр, әмма көрәштәшләре - үз сафташлары итеп саный алмыйлар: аңардан үз көрәшләре идеалларын яклауны көтмиләр, эзләмиләр. Үзләренең аны хөрмәт итүләрен исә - тырышлыгын, галимлеген, эшчән булуын, намуслылыгын гына тәкъдир итү дип аңларга тырышалар. Шул рәвешчә, укучылар һәм язучылар күз алдына - китап һәм язмалар өемендә казынудан башка нәрсә белән рәтләп кызыксынмаган, каләм тибрәтүдән генә тәм һәм ямь тапкан, дини юнәлештәрәк эшләүне гадәт иткән урта гасыр «голяма»ларына тартымрак, үз заманыннан соңгарак калып туган һәм, шуңа, яңалык серләренә теше әллә ни үтмәгән бер культура эшлеклесе булып килеп баса (Г.Тукай, Г.Ибраһимовларның аңа мөнәсәбәтен искә төшерик). Аның яшәеш рәвеше һәм биографиясе фактлары да шул калыпка кергән образын тагын да ышандырырлыграк итүгә генә каратылганнар кебек. Казыйлыктан үзе теләп китеп, ун елдан артыграк татар журналистларының терәге буларак яшәгәннән соң да, язмыш аны кабат шул ук Диния Нәзарәте бинасына кайтарып кертә. Кайбер китапларында (мәсәлән, гарәп галимнәре биографияләрен тасвирлаганнарында) һәм язмаларында («Асар» һ.б.) ул ачыктан-ачык «китап корты» булып, дөньясын онытып, замандашлары инде кирәксезгә чыгарган, тузан баскан иске язмаларда - ерак бабаларыбыз әсәрләрендә казынырга яратуын, шуннан олы ләззәт һәм рухи канәгатьлек табуын, әледән-әле искәртеп тора. Якыннан белгән замандашлары да аны шундыйрак шәхес итеп бәялиләр. Диния Нәзарәтендә аның белән бергә казый булып эшләгән педагог,

тарихчы галим, язучы Хәсән-Гата Габәши: «Риза казый хатиб (оратор) түгел. Тавышы зәгый флеген бәһанә[1] итеп һәр вакыттагы кебек... каты көрәшләрдән саклана», - дип яза үзенең бер истәлегендә. Кыскасы, кайсы яктан карасаң да, югарыдагы стереотип образ әдипнең чын сурәтен күз алдыбызга бастыра кебек. Галимнең билгеле әсәрләрен, аларда гәүдәләндерелгән идеалын, шул идеалга омтылышын, кыскасы, аның күркәм иҗат пафосын күз алдына китерсәк, әлеге стереотиплашкан образ авторның асыл йөзен яшереп торган пәрдә генә икәнен танырга мәҗбүр булабыз. «Дини юнәлештәрәк» кенә эш иткән бу галимебез - үзенең идеаллары буенча, мисал өчен, И.С.Тургеневның Базаровын хәтерләткән инкярчы ул. Аерма тик шунда: Базаров, без җимерәбез дип, һәр нәрсәне инкяр итәрәк, табигать законнарын өйрәнүгә чумган булса, Риза хәзрәт, шундый ук кискенлек белән: «Без инкяр итәбез» позициясендә торган хәлдә, кешене тәрбияләү, активлыкка өйрәтү юлы белән җәмәгыятьне кимчелекләрдән (феодализм калдыкларыннан) арындыру эшенә баш-аягы белән чумган. Ул үзенең нәкъ менә шушы эшчәнлеге әлеге олы нәтиҗәгә китерәсенә чын ышану белән ышана; шуңа күрә, үзен аямыйча, шул юнәлештә эш алып бара, шул эшне үзенең кешелек бурычы итеп саный. Ул да җәмгыятьне төптән яңартуның идеологик нигезләрен эзләү белән мәшгуль. Тукайлар, Әмирханнар, Г.Ибраһимовлар кебек яңа буын язучыларының эшчәнлеге дә шул ук максатка хезмәт итә түгелме соң? Ә шулай да алар Р.Фәхреддиновны үз сафташлары дип белмиләр. Моны ничек аңларга соң?

1888 елда, әле шәкерт Р.Фәхреддиновның Казанда 80-90 битле «Китабел-игътибар» дигән хезмәте басылып чыга. Табут якасында торган бөек Ш.Мәрҗани китапка игътибар иткән, чыккан көннәрендә үк күздән кичергән һәм авторы турында: «Бу егет өметле», - дигән имеш.

Китап чыккан көннәрдәге әдәби мохитны хәтерлик. 1883 елда «Тәрҗеман» газетасы чыга башлый һәм татар дөньясына килеп керә. 1884 елда традицияләр йөген күтәрергә

теләгәндәй, К.Насыйриның «Фәвакыйһел-җөләсә»се, 1885 елда Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбары»ның беренче томы, 1886 елда М.Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла»сы, 1887 елда З.Бигиевның «Гүзәл кыз Хәдичә» романы, Г.Ильясиның «Бичара кыз» драмасы, 1888 елда Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз»ы дөнья күрә. Газета, яңа фән (тарих), яңа әдәбиятның өр-яңа жанрлары - романнар, драмалар, публицистика. Менә шушы исемлектә Р.Фәхреддиновның да беренче китабының мәгънәсе һәм әдәби барыштагы урыны ачыклана. Х.Габәшинең «Бәсыйрәт»е (1889), Ф.Фәезхановның «Мөхәрикыль-әфкяр»е (1893) белән бергә, ул бездә газетадан аерым яши торган яңа әдәби публицистика жанрын башлап җибәрә. Үз чорында ук югары бяләүдә Ш.Мәрҗани ялгыз булмый. РГИАда әсәрнең цензура тоткарлаган кулъязма варианты бар. Цензор В.Д.Смирнов аның авторын гимназия, яки университет белеме алган кешеләрдән саный, әсәрне - мәгърифәт җырчысы кебегрәк бәяли. Авторның үзе дә, соңыннан, оялып кына аны үзенең яшьлек максимализмы гәүдәләнеше диебрәк бәяли. Китапта автор татар мәдрәсәләрен рус урта уку йорты тибындагы, фән нигезләрен һәм һөнәрләр өйрәтү учакларына әйләндерү «проекты» белән чыга; иске укыту тәртипләрен каты тәнкыйтьли. Традицион әдәбиятка да ул каты гына бәрелеп уза. Хәтта «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек халык китабы булып киткән дастаннарның әһәмиятен, нәкъ безнең 30-50 еллардагы кебек үк, тулысынча инкяр итә; аларны «вакыт караклары» дип атый, алар урынын белемгә, һөнәргә өйрәтә торган әсәрләр алырга тиеш[2] ди.

«Китабел-игътибар»ның, нәкъ шул елларда татар тормышында көчәеп киткән, мәктәпләрне, уку-укыту системасын яңарту (җәдид) хәрәкәтен мәйданга чакырган әсәрләрдән булуын шәйләү кыен түгел. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар» (1885) китабы Яңару хәрәкәтендә Ш.Мәрҗани этабын йомгаклаучы әсәр булды. Бу этапта яңару башлыча идеологик планда бара һәм Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Чокрый һ.б.лар кебек ялгызак энтузиастлар эшчәнлегендә чагыла. Югарыда исемнәре саналган башка әсәрләр Яңару

хәрәкәтенең 80 елларда яңа баскычка күтәрелүен гәүдәләндерделәр... «Тәрҗеман» газетасы рәвешендә бу хәрәкәт идеологик планнан практик эшчәнлек баскычына күчә: киң катлау җәмәгатьчелек аңына яңа фикерләр алып килә, аларның тормыш-көнкүрешкә үтеп керүе өчен көндәлек көрәш башлап җибәрә. Әдәбиятның яңа жанрлары (роман, драматургия, публицистика) ул көрәшнең мәйданын киңәйтә, коралларын ишәйтә. Сугышчан яңа әдәби публицистиканың беренче карлыгачлары булган «Китабел-игътибар», «Бәсыйрәт»ләр урыны да шул сафта: алар яңаруның җиңүе өчен кирәкле шартларга җәмәгатьчелек игътибарын юнәлтәләр, тиешле иҗтимагый-идеологик җирлек әзерләшәләр. Күренә ки, беренче китаплары белән үк Р.Фәхреддинов чорының идеологик хәрәкәтенең алгы сызыгына баса, аның актив һәм күренекле вәкилләреннән берсенә әверелә. Шул уңышлары һәм абруе нәтиҗәсе буларак, мәдрәсәдән чыгуының өченче-дүртенче елында ук аны Диния Нәзарәтенә казый итеп сайлыйлар.

Яңаруның 80 елларда башланган бу этабы - тарихта бик сирәк очрый торган социаль-иҗтимагый күренеш. Ул киң катлау массаларны яңа мәдәният югарылыгына күтәрүгә хезмәт итә. Ихтимал, мәсьәләнең шул гадәттән тыш катлаулылыгы һәртөрле сәяси хокуктан мәхрүм ителгән, икътисади мөмкинлекләре дә бик чикле булган колониаль халыктан бар көчне яңару бурычларының иң зарурилары-на туплауны сорагандыр. 90 елларда, мәсәлән, яңа мәктәп челтәре, яңа укыту методикасы («җәдидчелек хәрәкәте») формалаша. Ихтимал, яңаруның шул иң масса күләм өлкәсенә төп игътибар юнәлтелгәндер дә, башка юнәлешләрдә процесс берникадәр күләгәдәрәк торгандыр. 1888-1898 елларда яңа жанрлар инде мәйдан яулаган әдәбият гүя авазсыз кала. 80 еллар урталарындагы үрнәкләрне хәтерләтердәй әсәрләр мәйданда күренми.

Нәкъ шул елларда Р.Фәхреддинов эшчәнлегендә дә сөртенү, чәчелү, таркалу кебек күренеш күзәтелә: ул «тәрбия», «әдәп» китаплары кебек, урта гасырчылыкның «әдәбә»

(«зерцало») жанрын хәтерләткән дидактик нәрсәләр «штамповать итәргә» алына, гарәп грамматикасы, тагын әллә никадәр китапчыклар чыгара. Ун-унбиш ел да үтми, яңа буын зыялылары (Х.Әбелхан һ.б.) «яңа заман Фәзаилешшөһүр»ләре дип, бу китаплардан көләләр. Хәлбуки, үз вакытында аның бу әсәрләре җәдиди мәктәпләр тарафыннан дәреслекләр рәвешендә кабул ителгәннәр. Ягъни бу әсәрләрендә дә галим инициатива, активлык күрсәтә, гомум мәдәни характердагы әсәрләр иҗат итүен читкә куеп торып, чорның социаль заказын үтәргә алына. Мондый хезмәтләрнең әһәмиятен билгеләгәндә аларны галимнең бөтен эшчәнлеге фонында карарга кирәк. Югарыда әйткәнебезчә, иҗатының буеннан-буена Р.Фәхреддинов, нигездә, халкының «көндәлек» социаль заказы белән бәйле рәвештә, «яшь көчләр» үз итә алмаслык «традиция чикләреннән чыкмау» позициясендә кала, әмма, шул позициясендә торган хәлдә, ул милли яңару өчен көрәшнең алгы сафында бара. Әйтик, аның бу елларда төп эшчәнлеге нидән гыйбарәт булганын мәшһүр «Асар»ыннан чыгып билгеләргә мөмкин.

«Асар»... Бу олы әсәрнең илле табактан артыграк күләмдәге баштагы ике томын автор, зур кыенлыклар белән, 1900-1908 елларда унбиш кисәк («җөзьэ») итеп бастырып чыгаруга ирешә. Китапның шул вакытта әзерләнгән өченче томы исә дөнья күрә алмый кала. Автор гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу әсәре өстендә эшләвен дәвам итә, аның дүртенче томын да әзерли. 1900 елда аерым брошюра булып басылып чыккан беренче кисәк теоретик характердагы кереш мәкалә белән ачыла. Ул авторның иҗат пафосын һәм социаль-идеологик идеалларын ачыкларга бай материал бирә. Галимнең «Китабел - игътибар»ындагы кебек үк, яшьлек дәрте белән, искене инкяр итү позициясендә торганын күрәбез. Менә ул үзенең әле басылып чыкмаган бу язмаларын шул чор татар мәдәни дөньясында кулланышта булган китаплар белән чагыштырып карый һәм «Мөстәфадел-әхбар», «Вафийятел-әслаф»ның бәгъзе кисәкләрен истисна иделенер[3] исә,

күзем уңында китап исеменә лаек улган һич шәй улынмас иде», - ди (6б.). Заманының бөтен укымышлылыларын да ул, шулай, бер кизәнүдә юкка чыгарып ташлый: «... Үзләренең кайсы заманда идекләрене белмәй, дөньяның һәм каю өлешендә тордыкларына игътибар итмәй... файдасыз бәхәсләр илә, көн-төн мөҗәдалә итеп гомер уздырган кемсәләрне (кадимче муллаларны) галимнән санамак - тауларны урыныннан күчермәк кадәр мөшкел бер эштер»... (9 б.). Үзе чамадан тыш хөрмәт иткән остаз да аны хакыйкатькә хилаф сүз әйтергә мәҗбүр итә алмый: «... үз кашымда ышанычлы булган дәлилләргә мәҗбүр улып, күп вакытта «Мөстәфад», ягъни шәех Мәрҗанинең ихтыяр иткән сүзләренә һәм хилаф иттем», - дип белдерә ул (7 б.).

Әйе, иҗатының - XIX йөзгә караган чорында аның Мәрҗани белән бәхәскә керүе шәйләнә. 1897 елда «Мөстәфад»ның икенче томы басылып чыгып өлгерми, Р.Фәхреддинов, «шәех Мәрҗани ихтыяр иткән» сүзләргә хилафлык күрсәткәндәй, үзенең «Асар»ын яза башлый. Һәм аның максатын болай билгели: «Язмактан максат... гасырлар арасында үлчәү, кыяслар йөртеп, зиһеннәрне кузгатмак вә фәһемнәрне уйгатмак» (8 б.). Халкын мәдәни яктан үстерү бурычын алга куеп, ул мондый бурычны үти алырлык укымышлылар юклыкка борчыла: «Әдип вә галимнәре улмаган кавем - бәхетсез, мәшһүр кемсәләрне оныткан кавем хамиятсез, әдәбияты улмаган милләт - рухсыз», - ди (5 б.). Мондый уйлануларның асылы яңа культурага яңа функцияләр йөкләүгә кайтып кала. Мәрҗанидән соңгы этапның мәгънәсе, Р.Фәхреддиновның Ш.Мәрҗани белән «ярышуының җеп очлары» нәкъ шул моментка килеп төенләнә. Әйткәнебезчә, Ш.Мәрҗани халкына яңа идеология эзләү юнәлешендә эшли. Р.Фәхреддинов - «хисапсыз җаннар»ны «наданлык хәстәлегеннән» йолу өчен көрәш алып бара. Аның миссиясе, аның иҗатының пафосы - культурабыз үсешенең Мәрҗани этабын үтеп, аны тагын да үстерү. Бу зарури миссияне ул Мәрҗани югарылыгында, Мәрҗанинең соң яңа этап булырлык итеп

башкарып чыга. Шуңа күрә дә аның «Асар»ы Ш.Мәрҗани «Мөстәфад»ы белән тиң дәрәҗәдә, бер-берсен һич тә юкка чыгара алмас рәвештә, бүген дә безнең беренчел чыганагыбыз булып яши ала. «Асар»да заманына хас рәвештә конкретлашуга табан йөз тоткан. Ул белемне матди тормышны тәэмин итү чыганагы буларак бәяли. Халкында социаль катлаулану процессы барганлыгын күрә. Мәгърифәтче буларак, Европа халыкларындагыдай фәнни (дөньяви) белемнәр тарату аша, халкын хәерчелектән йолып алу проекты белән чыга. Туган халкының киләчәктә дә милләт буларак яши алуы өчен көрәшкә чыгуы Р.Фәхреддиновны - язучы, галим генә түгел, чорының алдынгы көрәшчесе - социаль реформаторы итеп таныта. Мондый сыйфатлар башка әдипләребездә ул кадәр үк кискенлек белән чагылмыйлар иде. Риза Фәхреддиновның чордашлары арасындагы какшамас абруеның нигезе дә әнә шунда.

Риза Фәхреддиновның культурабыз үсешенә керткән өлеше менә шул әйтелгәннәр белән генә чикләнгән булса да, тарих аның исемен Ш.Мәрҗаниләр янына куеп киләчәккә алып барыр иде. Әмма ул башка юнәлешләрдә дә онытылмас казанышларга ирешә алган әдип. «Мәшһүр хатыннар» (1904), «Мәшһүр ирләр» сериясе (1904-1917), «Иҗтимагый һәм дини мәсьәләләр» (1914) галимнең тарихыбызга кагылышлы хезмәтләре һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, культурабыз тарихында тиңе булмаган журналистлык хезмәте һәм җәмәгать эшчәнлеге мәдәни мирасыбызның монументальләре булып калалар. Болардан тыш, Р.Фәхреддинов матур әдәбиятыбыз үсешендә дә мөһим роль уйнаган. Моны ачыклау өчен ул чор әдәбиятыбыздагы хәлләргә күз салыйк.

Мәгълүм ки, XIX йөз ахырыннан бездә әдәби хәрәкәт бермә-бер җанланып китә. Аның баштагы елларында әсәрләрнең күплеге, төрлелеге, иң мөһиме, җитлеккәнлеге, актуальлеге, сугышчанлыгы белән Фатих Кәрими алгы сафка чыга. Шуннан соңгы чирек гасырда зур активлык күрсәтәчәк байтак темалар (кадим - җәдид көрәше, иске,

яңа мәктәп; прогресс һәм иҗтимагый активлык һ.б.), мотивлар, карашлар, идеаллар башлап нәкъ менә Ф.Кәрими иҗатында әдәби норма рәвешенә китереләләр. Яңача яшәеш һәм прогрессның динамикасы, аларның кыйбла-ориентирлары безнең халыкның тарихи яшәешендә шул рәвешчә формалаша. Бу актуаль «программалаштырулар» мөмкинлекләрне һәм идеалларны кабат яңартып күзаллаулар - Риза Фәхреддинов белән янәшәдә, аның күз алдында һәм, әйтергә кирәк, аның шифалы тәэсирендә формалашалар һәм мәйдан торалар. Мәсьәлә шунда: Риза хәзрәт - Ф.Кәримигә гаять якын кеше. Ф.Кәрими - аның апасының улы. Бу ике мәшһүр әдибебез арасында бер-берсенә карата зур хөрмәт, тирән мәхәббәткә нигезләнгән олы дуслык мөнәсәбәтләре яши. Шул рәвешчә, Ф.Кәриминең иҗади казанышларында Р.Фәхреддиновның да остазлык өлеше бар.

Ф.Кәрими белән бер үк вакытта диярлек әдәбиятта башланган яңарыш дистәләгән талантлы авторлар (С.Максуди, Г.Исхакый, Ш.Мөхәммәдев, Г.Камал, З.Һади, М.Гафури һ.б.) иҗатында да киң урын ала. Бу хәрәкәтнең беренче сафындагылар исемлегендә Р.Фәхреддинов исеме дә бар. 1899 елда аның «Сәлимә, яки гыйффәт» повесте, 1903 елда, «Әсма, яки гамәл вә җәза» романы басылып чыга. Бу әсәрләр ул чор әдәби хәрәкәтендә үзенә бер юнәлеш тәшкил итәләр кебек. Алар «Хисаметдин менла», «Гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар», «Мәгыйшәт», «Кәләпүшче кыз», «Җәһаләт», «Мирза кызы Фатыйма» һ.б.ларның берсенә дә охшамаган. Чорының тормышны яңарта алырлык актив мәгърифәт идеалын гәүдәләндергән «Сәлимә», «тормыш төбе»ндә рухи пакьлекләрен саклап яшәүче гүзәл кешеләрне сурәтләгән «Әсма» автор иҗат пафосының тирән демократизмын шактый калку чагылдыралар. Хәлбуки, мондый әсәрләрне, гомумән, мәгърифәтчелек әдәбиятына хас норматив әсәрләр дип карау, алардагы дидактик башлангычны абсолютлаштыру шактый таралган. Чынлыкта исә аларда бу традицион элементлар түгел, бәлки чорның конкрет сорауларына җавап эзләү, шул

мәсьәләләр хакында чордашлары, укучылары белән әңгәмә, чор «публицистикасы» өстенлек итә. Шуңа күрә дә бүген алар «сәнгать» булуга караганда «публицистик башлангыч» бик активлаштырылган, дидактик әдәби әсәрләрне хәтерләткәндәй күренәләр. Ягъни аларда бүген инде «онытылган» чорның конкрет практик проблемаларына киң мәйдан бирелә. Газетасы булмаган, иҗтимагый-фәлсәфи, сәяси фикер яралгы хәлендә яшәгән халыкта ул вакытта моның башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Автор биредә дә «наданлык хәстәсе һәм фәкыйрьлек бәласе илә мөбтәля» туган халкының язмышы, аның киләчәге турында уйлана. Ягъни, художник буларак та ул халык бәхете өчен көрәш һәм социаль реформаторлык позициясендә кала. Характерының бу төп үзечәлеге 1905 ел революциясенең аның шәхси язмышында чагылышында да үзенчәлекле гәүдәләнеш тапкан.

Әлеге революция йогынтысында Р.Фәхреддинов үзенең шәхси тормышында кискен борылыш ясый: 1906 елда ул казыйлык хезмәтеннән үз теләге белән баш тарта, Уфадан Оренбургка күчеп килә, «Вакыт» газетасында хәбәрче булып эшли, ә 1908 ел башыннан ул - Оренбургта чыга башлаган «Шура» журналының төп оештыручысы һәм баш редакторы-.Ун елга сузылган редакторлык хезмәтендә дә Р.Фәхреддинов журналистикабыз тарихында тиңдәше булмаган уникаль эш башкара. Аның бу хезмәте махсус тикшеренүне көтә.

Аена ике мәртәбә чыгып килгән «Шура»ны берүзе редакцияләү белән бергә, бу елларда әдип иҗат активлыгын да арттыра. «Мәшһүр ирләр» сериясендә дистәләп китап нәкъ шул елларда иҗат ителә һәм басылып чыга; «Иҗтимагый вә дини мәсьәләләр» кебек җитди хезмәтен әзерли; йөзләгән биографияләр, күп йөзләгән, төрле күләмдәге тарихи, иҗтимагый-сәяси, әдәби тәнкыйть мәкаләләре язып журналда бастыра. Алар арасында нинди җәүһәрләр барлыгын, мәсәлән, аның «Сорауларга җавап» рубрикасында басылган «медиатор» сүзенә биргән кыска аңлатма - репликасында күреп була.[4] Бу репликаны шул чор татар

сәяси фикеренең үткенлек дәрәҗәсен күрсәтүче әсәр дип билгеләргә мөмкин. Колониаль коллыктагы халыкта административ хокук турында хәтта иллюзия туу ихтималыннан куркып, Әби патша (Екатерина II), Диния Нәзарәтен оештырганда, бу оешмада «хаким» (третейский судья), «казый» (дини мәсьәләләр буенча хөкем йөртүче) дигән атамаларны кулланудан курка, шул хезмәтне башкаручыларны халыкка аңлашылмый торган француз теленнән алынган «медиатор» сүзен кулланышка кертә. Һәм XIX йөзнең 30 елларына кадәр шул аталма гына кулланылышта була. Галим инкяр итү мөмкин булмаган факт нигезендә царизмның милли сәясәтенең асылын ачып күрсәтә, аның халыкларга ни дәрәҗәдә дошман булганын фаш итә. Фәнни тотрыклы, тирән сәяси фикерле, сугышчан публицистик рухлы мондый «миниатюра»ларны ул аз язмаган.

Журналда ул укучыларына Маркс һәм аның тәгълиматы турында да информация бирә. Фәнни коммунизмга үз билгеләмәсен урнаштыра: «XIX гасырның урталарына тугры зоһур илә[5], шимди[6], табигъләры[7] тарафыннан бер дине сәмави[8] кеби хөрмәт вә итагать күргән гыйльме гавамият иштиракыя[9]...» «Әлгасрел-җәдид» журналында Г.Тукай шигырьләре басылу турында ул «Вакыт»та кыска информацияләр биреп бара; бу яңа, яшь каләмнән киләчәктә зур шагыйрь үсәчәген хәбәр итә. Мондый фактлар карт хәзрәтнең игътибары нинди кыйблага юнәлгән булуын шактый ачык искәртәләр. Әйе, ул иҗатының башлангыч елларындагы кебек үк, алга, чын тарихи прогресска омтылышлы көрәш позициясендә кала. Шул омтылыш аның караш үткенлеген, иҗат активлыгын билгели.

Шул ук вакытта мәдәниятебезнең яңа яшь көчләре аны үз көрәштәшләре дип кабул итә алмыйлар, искеләр (картлар) сафындагы бер мөхтәрәм зат кебегрәк карыйлар. Моны нинди дер ялгышу, аңлашылмау нәтиҗәсе генә дип карап булмый. Риза хәзрәтнең үзенең дә ул яшьләргә мөнәсәбәтендә шундый ук үзен «аерым кую» барлыгын сизеп була. Бер моментка гына игътибар итик. Кичүчат

авылында туып үскән, Чыршылы авылы мәдрәсәсендә укыган чын татар егетен үз халкының сөйләм телен белеп бетермәгән дип уйларга һичнинди нигез юк. Шул ук вакытта язмаларында ул гарәп-фарсы алынмаларын мул итеп файдалана, аны үзенең стиль үзенчәлегенә әйләндерә. Бу омтылышның сәбәпләре күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесенең гомум иҗтимагый-сәяси программасына барып тоташа. Үзен тулысынча туган халкының милли һәм социаль азатлыгы өчен көрәшкә багышланган Р.Фәхреддинов царизм тарафыннан изелгән халыкларының бу көрәштә үзара ярдәмләшкән, берләшкән тәкъдирдә генәниндидер нитиҗәгә ирешү мөмкин икәнен аңлый. Бу мәсьәләдә Р.Фәхреддинов «Тәрҗеман» газетасында алга сөрелгән «бердәм хәрәкәт» программасын кабул итә һәм гомеренең ахырына кадәр шушы программага турылыклы булып кала.

Бу тотрыклылыкта ниндидер консерватизмның әсәре дә юк. Моны аның яшьләргә мөнәсәбәтеннән чыгып та аныклап була. Югарыда без Р.Фәхреддиновның Г.Тукайга карашын күрсәтеп үткән идек. Г.Ибраһимовка да аның шундый ук игътибарлы булганы билгеле. «Тезгенсез», - дип, Г.Тукайлар, Ф.Әмирханнар хәтта аңардан йөз чөергәндә, Р.Фәхреддинов Г.Ибраһимовка «Шура» капкаларын киң иттереп ача. Шул ук вакытта ул уртак дошман - царизмга каршы көрәштә бердәмлек хакына яшьләрнең сырт йоннарын кабартырлык консерватив көчләр вәкилләре белән дә компромисска керә ала. Моның белән Р.Фәхреддинов, төп максатына тугрылык саклаган хәлендә, конкрет эшчәнлектә реализм һәм мобильлек күрсәтә. Аның социаль позициясен «мәгърифәтче демократ» дип атап булыр иде. XIX йөз дәрәҗәсендә катып калу күренеше түгел. Р.Фәхреддиновның мәгърифәтче демократ булуы татар халкының күпгасырлык милли-азатлык көрәше белән бәйләнгән. Әйе, ул - милли азатлык көрәшчесе. Аның дөньяга карашы халкының шул күпгасырлык көрәшенең үзенә бер сөземтәсе булып тора. Аның өчен үтә мөһим булган белем, фән, прогресс кебек максатлар тулысынча

халык язмышы турында кайгыртуга багышланган. Нәкъ менә шул үзенчәлеге аны - язучы, галим, җәмәгать хадиме генә түгел, чын мәгънәсендә көрәшче, аңлы, максатчан көрәшче итеп таныта. Аның көчле ягы да шунда. Көрәштә аның беренче таянычы, ышанычы - киң катлау халык массасы. Бу аның иҗатының тирән халыкчанлыгында, эзлекле демократизмында да чагылыш таба.

Шул ук вакытта ул восстаниене, коралды сугышны көрәш чарасы итеп кабул итә алмый. Чөнки ул «татар восстаниесе» белән самодержавиене, Россия хәрби-бюрократик дәүләт машинасын җиңеп булмаячагын аңлый, тарих та шул хакта сөйли. Шуңа күрә ул изелгән халыкларның берләшеп, революция аша бу дәһшәтле көчне җиңү ихтималына да ышанып бетә алмый. Бу - аның идеологик позициясенең йомшак ягы. Шуннан парадоксаль каршылык килеп чыга. Көрәшче, үтәдән-үтә демократ булып та, ул шул ук максатны кыйбла иткән революцион демократлар белән кушылып китә алмый. Нәтиҗәдә яшьләр - революцион демократлар да аны үз итүдән шактый ерак торалар. Хәлбуки, аның социаль позициясендә революцион демократлар өчен дә кирәкле уңай программа, уңай эчтәлек бар. Мәгълүм ки, XX гасыр башында Һиндстанда Махатма Ганди җитәкчелегендә грандиоз коралсыз каршылык күрсәтү хәрәкәте формалаша һәм ул халыкара милли-азатлык хәрәкәтендә үзенә бер агым, юнәлеш төсен ала. Бу хәрәкәт шул чордагы рус иҗтимагый фикерендә, мисал өчен Л.Н.Толстой уйлануларында башкарак планда фәлсәфи чагылыш таба. Икенче яктан, бу тенденция яшьләрдә, революцион демократик лагерьда куәт ала барган берьяклылыкка - үткәндәге традицияләрне инкяр итүгә йөз тоткан кырыс революцион аскетизмга каршы тора.

Һәм, ниһаять, Р.Фәхреддиновның «кораллы көрәш» формасын «минсенмәвендә», үзара тыныч хезмәттәшлеккә нигезләнгән кешелек җәмгыяте тарихында кораллы бәрелешләрнең соңгы чара гына булганын искәртү, халыкның нигез әхлакый принципларын яклау, раслау өчен көрәш

моменты да бар. Шуңа күрә дә ул, Толстой, Гандилар кебек үк, үтә традицион һәм бу традиционлык, тегеләрдәге кебек үк, традицияләрне радикаль җимерүләр чорына кереп барганда да - искелекне яклауга, консерватив күренешкә әйләнми, алдынгы иҗтимагый көчләр әлегә аларны кабул итә алмаган шартларда да, чорының уңай эчтәлекле һәм киләчәккә омтылыш әхлакый-фәлсәфи казанышы булып кала.

Риза хәзрәтнең руханилыгы мәсьәләсе дә, билгеле, аның өлкән яшьтә булуы яки казыйлыгы кебек хәлләре белән бәйләнмәгән. Аның нигезе дә милли-азатлык хәрәкәтенең тарихи үзенчәлекләренә, чын халыкчан традиционлыкка барып тоташа. Берничә гасыр дәвамында әлеге хәрәкәтнең идеологиясе булган, әле дә киң катлау арасында шундый тәэсир көчен саклаган дингә ул башка төрле мөнәсәбәт күрсәтә алмый. Киресенчә, Р.Фәхреддинов тарихи зилзиләләр чорында мең еллар буенча халкыбыз үстереп килгән уңай традицияләрне яклап, саклап киләчәккә җиткерү өчен хәрәкәттә зур эшчәнлек күрсәтә. Аның гаять әһәмиятле бу эшчәнлеген һәр яклап халыкка җиткерү әле фәнни бурыч булып безнең алда тора.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Бәһанә - сылтау.
2. Фәхреддинов Р. Китабел-игътибар. Казан, 1888. - 30, 51 б.
3. «Мөстәфадел - әхбар», «Вафийятел-әслаф» - Ш.Мәрҗани әсәрләре.
4. «Шура». - 1909. - № 10. - 309 б.
5. Тугры, зоһүр илә - мәйданга чыккан мәгънәсендә.
6. Шимди - инде.
7. Табигълары - тарафдарлары, шул юнәлеш кешеләре.
8. Дине сәмави - илаһи дин.
9. Гыйльме гамавият иштиракыя - гыйльми коммунизм фәне.

Ф.К.Бәширов

Р.ФӘХРЕДДИНОВ ПРОЗАСЫНДА ТӘРБИЯ ҺӘМ ӘХЛАК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Татар дөньясының күренекле шәхесе, тарихи,әдәби һәм педагогик хезмәтләр авторы Риза Фәхреддинов татар проза жанрын үстерүдә дә нәтиҗәле эш башкарды. Әдипнең мәгърифәтчелек карашларын бәян итү йөзеннән мәйданга куйган «Сәлимә, яки гыйффәт» (1899), «Әсма, яки гамәл вә җәза» (1903) әсәрләре заман әдәби хәрәкәтендә күркәм урын били. Гомумән, галимнең күпкырлы эшчәнлеге проза әсәрләрен иҗат иткәндә дә уңышлы файдаланыла. Мисал өчен Р.Фәхреддинов тарафыннан Ш.Мәрҗанинең «Рихләтел- Мәрҗани» (1897), шулай ук «Исмәгыйль сәяхәте» (1903) эшкәртелеп һәм күп төрле аңлатмалар белән басыла. Ил гизү, сәфәр чыгу, сәяхәт итү хасиятләре әдипнең матур әдәбият өлкәсендәге эшчәнлегенә дә үтеп керә. Аның «Сәлимә, яки гыйффәт» повестенда Иран сәүдәгәре кызы Сәлимә белән татар шәкерте Идел буйлап сәяхәт иткәндә очрашалар. Әсәрдә мәхәббәт сызыгы сәфәр кылу, төрле шәһәрләр, халыклар, аларның эшгамәлләрен тасвирлау белән бергә үрелеп бара. Повестьның «Казан», «Болгар», «Самар» яки «Төрки кавемнәре» кебек бүлекләре тулаем диярлек сәяхәтнамә стиле белән иҗат ителгән. Бу ысул ике төрле максатка хезмәт итә. Беренчедән, ике яшь йөрәккә бер-берсен өйрәнү, күркәм сыйфатларын ачып ихластан гашыйк булу өчен вакыт һәм пространство ролен үти. Икенчедән, татар укучысын халыкның тарихы, күренекле шәхесләре белән таныштыра.

«Әсма, яки гамәл вә җәза» романында да сәяхәтнамә жанрының мәгълүм йогынтысы сизелә. Моны инде әсәрнең сүз башыннан ук тоярга мөмкин. Әдип вакыйгалар барачак урын, анда катнашачак кешеләр турында сөйләр алдыннан тарихка мөрәҗәгать итү кирәк дип саный һәм бу төбәкләр хакында иң борынгы чыганаклардан булган Ибне Фазлан язмаларына туктала: «Болгар төрекләренең, руслар вә баш-

кортлар әхвәле хакында иң иске мәәхәз (чыганак - Ф.Б.) ушбу әсәрдер, фәкать бәгъзе мөбаләгале (арттырулы - Ф.Б.) вә гакылы бик ерак хәбәрләре улдыгы инкяр улынмас. Шөйлә исә дә моның әсәре гыйльме тарих гашыйклары өчен кыйммәтле бер ядкарьдер». Р.Фәхреддинов бу юлъязмаларның тарихына кыскача гына тукталып уза, Ибне Фазлан белән очрашкан борынгы халыклар хакында мәгълүмат биреп китүне дә кирәк таба.

Сәяхәтнамә стиле романның сюжет үзенчәлекләрендә дә чагылыш таба. Габбас мелланың, хаҗга китеп, серле рәвештә юкка чыгуы, соңыннан ачыкланганча, угрылар тарафыннан әсирлеккә алынуы, алардан качып китеп, мең газап аша илгә кайтуы - болар барысы да әсәргә маҗаралы, мавыктыргыч сәфәр эчтәлеген дә өсти. Габбас мелланың башыннан үткәннәре «Исмәгыйль сәяхәте»ндәге герой күргән-кичергәннәргә охшаш булу да очраклы түгелдер.

Шул рәвешле, «Сәлимә, яки гыйффәт» повестенда вакыйгалар пароходта бара. Бу үзенчәлек сөйләнәсе хәлләрне бер фокуска туплап бирергә ярдәм итә. Шуңа мөнәсәбәттә хикәя киңлеккә омтылмый, төп игътибар геройларның рухи дөньясын ачуга юнәтелә. Аларның беренчесе, татар шәкерте - иске мәдрәсәдә тәрбия алган, әмма катып калган кадими фанатикка әверелеп өлгермәгән яшь егет. Җәдидләшкән башка бер мәдрәсәдә дә укырга өлгергән, дөньяны аңлау юнәлешендә дә пассив түгел, әмма гыйлем, мәгърифәт, һөнәр һәм сәнгать ягыннан әзерлегендә җитди җитешсезлекләр бар. Бу бигрәк тә әсәр геройларының икенчесе - Мисыр университетын тәмамлаган Сәлимә белән чагыштырып караганда ачык күренә. Сәлимә - гарәп, француз, инглиз телләрен камил белә, тарихтан хәбәрдарлыгы да зур. Хәтта татар теленә һәм тарихына кагылышлы материалларны татар шәкертеннән яхшырак үзләштергән. Сәлимә белән очрашып сөйләшкәч, егет дөньяга, тормышка һәм үз-үзенә бөтенләй башка күз белән карый башлый, зиһене ачылып, уйлары яктырып киткәндәй була.

Әдип повестьта чын кеше булу өчен, гыйлем белән бергә, гүзәл әхлак һәм кешелеклек сыйфатлары таләп ителүен раслый. Милләтнең киләчәге күркәм холыклы, тирән белемле яшь буында, ди автор һәм шуның өчен аңа «...дин, һөнәр гыйлемнәрене белдермәк, үземездән маһир остаз вә галимнәр йитештермәк, аңа делемездә файдалы рисаләләр язып бастырып нәшер итмәк, исламча илә бәрабәр русча белмәк, мәгъриб вә мәшрикъ делләре тәхсил иттерер (үзләштерер - Ф.Б.) өчен махсус мәдрәсә ачмак беренче вазифамыздыр...», дип белдерә.

Бу җәһәттән Р.Фәхреддинов искелек белән яңалыкның мәңгелек тартышына туктала һәм гыйлем өлкәсендә бу бәхәснең артык күпертелүен әйтә. Аныңча, «осуле җәдид» белән «осуле кадим» ызгышы - юк нәрсә. Искелекнең яңалык белән алышынуы яшәешнең катгый бер кануны. «Коръән һәм хәдисләрдә иске ысул да юк, яңасы да! Бер вакытта иске ысулга яңа диерләр иде, киләчәктә бәлки бу яңа ысулга һәм иске ысул исеме бирелер, чөнки дәхи йиңел вә яңа бер ысул дөньяга чыкмыш улыры Хаҗ фарыз улган ике кемсәгә, ат-арба илә вармакмы тиеш, юкса машинага утырмакмы тиеш, дия низагъ идешүләре нә кадәр көлке бер эш улыр исә, осуле җәдид хакында улган низагъ та бигайниһи (нәкъ - Ф.Б.) шуның кебидер...»

Р.Фәхреддиновның укучыга җиткерергә теләгән фикерләре лирик герой (татар шәкерте) исеменнән әйтелә, аның уйланулары аша бәян ителә. Г.Сәгъди билгеләп узганча, әдипнең «үткен каләм белән язылган бу хикәясендә төрле картиналар, тасвирлар аркылы сузылып, чәчелеп барган фикерләр»[1]енең төп өлеше әнә шул дөньяга күзе ачыла башлаган лирик герой уй-карашлары тирәсенә туплана. Шуңа да әдип, мәгърифәтчеләргә хас булганча, аны бәхетле итәргә ашыга. Нәтиҗәдә саф җанлы Сәлимә белән әдәпле шәкерт бәхетле гаилә төзиләр. Бу җәһәттән автор семья һәм тормыш турындагы фикерләре белән дә уртаклаша.

Әхлак һәм тәрбия мәсьәләләре «Әсма, яки гамәл вә җәза» романында да үзәккә алына. Биредә тәрбия прин-

ципларының төрле алымнары күзәтелә. Беренче чиратта бу гаилә тәрбиясе булып, аның эчтәлеге Әсма образы аркылы җентекләп хикәяләнә. Әсма - Габбас мелла белән Гайшә абыстайның бердәнбер кызы. Эчтәлектән күренгәнчә, Габбас мелла алдынгы карашлы, осуле җәдидәне кулланып эш итүче мөгаллим, гаиләсенә бик игътибарлы ата. Гайшә абыстай да бик кешелекле, саф күңелле, семья һәм йорт өчен җан атучы ана итеп тасвирлана. Әсманың балачагы менә шундый сәламәт мохиттә уза һәм гаиләдә алган тәрбиясе аны бик күп бәла-казалардан, аянычлы, үкенечле хәлләрдән йөз аклыгы белән чыгарга ярдәм итә. Ә инде әхлак нормаларын бозган һәм Габбас мелла гаиләсенә күп борчу-хәсрәт китергән типлар әсәр ахырында гамәлләренә тиң җәзаларын ала. Язучы, гомумән, гаиләне кечкенә бер дәүләт белән чагыштыра һәм «инсанның яшьлегендә алмыш тәрбиясе та каберенә* кадәр берлектә улыр, аерылмас» дигән фикерне бөтен әсәр дәвамында раслый.

Р.Фәхреддинов уңай тәрбия мәсьәләсенең сыйфат ягына да игътибар бирә һәм бу җәһәттән аның дәрәҗәсе буенча төрле баскычта торучы формаларын аерып чыгара. Әйтик, афәтле язмышка дучар булган ятимә Әсма берара туган тиешле Йосыф карт карамагына кала. Бу йортта кызга авыр сүз әйтүче булмый, хәлдән килгәнчә ярдәм итәләр, юаталар, кимсенми яшәсен дип тырышалар. Әмма бу яхшы мөнәсәбәт, гәрчә ихластан булса да, ата-ана йортында алган тәрбияне һич кенә дә алыштыра алмый. Әдип моңа аеруча басым ясый: «Тәрбия» дидек. Ләкин Йосыф бабай тәрбиясе ялгыз ашатып-эчертеп, хаҗәт киемнәрне бирмәктән гыйбарәттер. Әмма Габбас мелла тәрбиясе - җан вә күңелне нурландырмак вә зиһенне киңәйтеп, тәхсиле кәмаләт (тулы гыйлем алу) юлыны ачмак вә рәгъбәтләндермәктән (кызыксындырмактан) гыйбарәт иде. Ике төрле тәрбиянең арасында улан аерма бик бөектер».

Романда күтәрелгән мөһим проблемаларның янә берсе - мәктәп-мәдрәсә тәрбиясе. Мәгърифәтчелек идеологиясенең үзәк баганаларын тәшкил иткән бу проблема белем бирү

йортын, аның эчтәлеген аңлату белән бергә, киңрәк мәгънәдә дә кулланылырга мөмкин. Р.Фәхреддинов романында бу мәсьәлә нәкъ менә шундый яңгыраш ала. Әсәрдә тәрбия учакларының берсе булган мөселман ятим балалары өчен махсус салдырылган тәрбияханә тасвирлана. Ир һәм кыз балаларга аталып, ике бүлемнән торган бу ятимханә күркәм уку, белем бирү ягыннан дан тота. Биредә дөньяви фәннәрдән дәрес әйтүгә зур игътибар бирелә, әхлак тәрбиясе үзәккә алына. Бер үк вакытта гамәли дәресләргә дә җитди мөнәсәбәт урнаша. Әлбәттә инде, мондый мохиттә тәрбияләнеп үскән яшь буын киләчәктә милләтнең асыл ул-кызлары булып җитешәчәк. Кыз балаларга бүлемне сурәтләгәндә автор әлеге мәсьәләгә аерым туктала: «...бу талибәләр, бу мөтәгаллимәләр (укучы кызлар - Ф.Б.) атласларга гаркъ улынмыш кием калыплары улмай, бәлки гадәти киндергә вә тәкәллефсез пәрдәләргә борынмыш (төренгән) энҗе вә алмазлардыр. Бонлар ислам милләтеннән ничә гасырлардан бирле зайг улып (юкка чыгып - Ф.Б.) килмәктә улган «милләт аналарыдыр...»

Романда Әсманың сайлаган яры мөгаллим әфәнде дә шул юнәлештә тырышлыклар куючы шәхес буларак характерлана. Бар көчен белем бирүгә, файдалы һөнәр пропагандалауга, шәкертләрен милләткә хезмәт итүчеләр итеп тәрбияләүгә биргән мөгаллим әфәнденең тырышлыклары бушка китми: «Фикерле шәкертләр, күзләре ачык байлар күп вакытта боның хозурына килерләр вә сүзене аңларлар, күңелләренә шәвекъ (омтылыш - Ф.Б.), мәхәббәт, нәшат (шатлык - Ф.Б.) хасил иттекләре хәлдә таралырлар иде». Аңлашылса кирәк, мондый игелекле эшләрнең күркәм нәтиҗәләре дә озак көттермәячәк: «...яз көненең сачәкләре кабиленнән бере соңында икенчесе уларак, акрын-акрын мәйданга килер, соңра шөкер иделенәчәк дәрәҗәгә һәм ирешер...»

Күренә ки, бу рәвешле караганда мәктәп тәрбиясе аерым шәхес формалашу кысаларыннан үтеп, милли һәм иҗтимагый югарылыктан торып бәяләнә башлый. Дөрес

һәм нәтиҗәле белем ул ахыр чиктә милләтне яңарыш дәверенә алып керәчәк хәлиткеч көч икән. Башлангыч белем алу иң беренче көненнән үк хак юлга салына калганда, аның киләчәге дә якты була, җәмгыятьтәге тәэсире дә яхшы вә мактаулы эшләр булып калыплана.

Ә инде иске тип мәдрәсәләрне тасвирлаганда Р.Фәхреддинов каһкаһәле тонга күчә. «Әсма...» романында кадими мәдрәсә идеологы Хикмәт хаҗи Габбас мелла кебек алдынгы карашлы мөгаллимнең мәктәп ачып балалар укытуына шул кадәр дошман була ки, «әгәр дә мөмкин булса, мәктәбене ваттырып, урынында улан туфракны суга салдырыр иде». Үзе кебек «тәрәккъкый тормозларына» әверелгән иярченнәреннән гыйбарәт бер «ишәк җыены» вәкиле булырга теләгән теге яки бу мулла, мөгаллим бер «хикмәтле» сүз әйтеп, үзенең «лаеклы» булуын расларга тиеш. Шундыйларның берсе болай ди: «Грифель илә кара тактага язмак шәригатькә хилаф, соңра аны бозып алмак та хәрам!»

Инде мондый «хикмәтне» җитди чыганаклар белән дәлилләү дә таләп ителә. Куштан мулла ошбу сүзләр язылган китапның «университет тәбгыханәсендә» басылуын әйтә дә, сүз егәрен арттыру ниятеннән әлеге типография пәйгамбәр заманасында ук булган, дип ышандырырга тотына. Табигый ки, мондый аргументлар җәдиди мәктәп дошманы Хикмәт хаҗи күңеленә гаять хуш килә.

Әнә шул рәвешле очы очка ялганмаучы мантыйк сөргән уку йортыннан нинди фикерле шәкертләр тәрбияләнеп чыгачагын аңлау кыен түгел.

Гомумән, Р.Фәхреддинов прозасының төп үзенчәлегеннән чыгып, искә алынган хезмәтләрне *тәрбияви әсәрләр* дип атарга мөмкин булыр иде. Бу тип әсәрләр язучы белән укучы арасында күпер ролен үтәп, югары әхлак нормаларын халыкка җиткерүдә төп алым итеп танылды. Бу - заманның социаль эчтәлегеннән үсеп чыга торган табигый зарурият иде. А.И.Герцен билгеләгәнчә, «иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият үзенең ачу һәм вөҗдан авазын ишеттерү өчен бердәнбер трибуна булып тора»[2].

Р.Фәхреддинов «Әсма...» романында иҗат дөньясына югары бәя бирә: «Әдәбият илә иштигаль - күңелене сафламак вә нәфесне тәрбия итмәк бабында иң әсәрле улган дәвадыр, - ди. - Бинаән галәйһи (шуңа күрә - Ф.Б.) гаилә башлыгы вә милләт анасы улганнарга хөсне әхлак вә гыйбрәт дәресләре сөйләр. Буйлә итмәнең файдасы гаилә вә өммәт (милләт - Ф.Б.) өчен чиксездер».

Шул рәвешле Р.Фәхреддинов проза әсәрләрендә дә милләт хәлен кайгырткан, уңышларына сөенгән, кимчелекләренә сызланган шәхес буларак гәүдәләнә. Әдип тәрбия һәм әхлак мәсьәләләрен үзәккә алып, гомуммиллә идеясен күтәрә, татар халкының тәрәккыяте өчен кирәк булган чараларны билгели.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. - Казан: Татар.дәүләт нәшр., 1926. - 108-109 б.

2. Герцен А.И. Сочинения. В 30-и томах. 7 том. - М.: Изд. Акад.наук СССР, 1956. - С.198.

* Та каберенә - каберенәчә.

Р.Ф.Мәрданов

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ «ШУРА» ЖУРНАЛЫНДАГЫ ӘДӘБИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

XX гасыр башы татар газета-журналлары арасында эчтәлегенең байлыгы һәм күпкырлылыгы белән иң зур абруй казанганнарының берсе — мөбарәк «Шура» (Киңәш) журналы. «Әдәби, фәнни вә сәяси» бу журнал 1908 елның гыйнварыннан 1917 елның декабрь аена кадәр Оренбург каласында нәшер ителгән. «Шура» мәшһүр дини вә иҗтимагый эшлекле, галим һәм әдип Ризаэддин Фәхреддин мөхәррирлегендә, танылган татар алтын промышленниклары, җәмәгать эшлеклеләре Шакир һәм Закир Рәмиевләр наширлегендә чыккан. Журнал айга ике мәртәбә чыгып, бер елга 24 сан, ә ун ел дәвамында барлыгы 240 саны дөнья күргән. «Шура» журналы Идел-Урал төбәгеннән тыш, Россиянең башка тарафларына да таралган, шулай ук Төркестанда, Казакъстанда, Кавказда, Кырымда һәм Төркиядә дә укылган. Журналның колачлаган тематикасы гаять күпкырлы. Төп темалары исә - тарих, әдәбият, мәгариф һәм тел мәсьәләләре булган.

Татар вакытлы матбугаты җәүһәрләренең иң затлыларыннан берсе булса да, совет хакимияте дәверендә «Шура» журналына да, 1917 елга кадәр чыккан башка бик күп татар газета һәм журналлары кебек үк, «милләтче, буржуа органы» дигән кара мөһерләр сугылып килде.

Әдәбиятка һәм мәдәнияткә гаять югары дәрәҗәдә игътибар һәм әһәмият биргән, олуг шәхесләр тарафыннан җитәкләнгән вә нәшер ителгән журналда, әлбәттә, әдәби әсәрләргә һәм әдәбият мәсьәләләренә зур урын бирелгән. Журналда ун ел эчендә басылып чыккан язмаларның1358е әдәбиятка (шигърият, чәчмә әсәрләр, әдәбият тарихы һәм теориясенә) карый.

Матбугат мәйданында ун ел дәвамында балкыган «Шура» битләрендә барлыгы 880 авторның төрле язмалары дөнья күргән. Мәкаләләрнең зур бер өлеше, шулай ук редакци-

ягә килгән хатларга, бихисап сорауларга җаваплар журналның мөхәррире Р.Фәхреддин тарафыннан язылган. Рәмиевләр тарафыннан нәшер ителгән «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасының идарә-редакциясе, нигездә, бер үк кешеләрдән торган. «Шура» редакциясендә төрле елларда Ф.Кәрими, Ш.Камал, З.Бәшири, Җ.Вәлиди, Я.Вәли, К.Бәкер һ.б. эшләгән. Г.Тукайның да «Шура» редакциясенә эшкә чакырылганлыгы билгеле.

«Шура» журналының зур абруй казанып, югары гыйльми дәрәҗәгә ирешүе, һичшиксез, аның баш мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин эшчәнлегенең, киң эрудициясенең, фидакяр тырышлыкларының нәтиҗәсе. «Шура»ның гомумәдәби эшчәнлеге дә - әдәбият дөньясының рухи әһәмиятен тирәнтен аңлаган Ризаэддин Фәхреддиннең әдәбиятка мөнәсәбәтенең тулы чагылышы.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура» дагы эшчәнлеге дәверендә әдәбиятка, аерым алганда, шигъриятькә беркадәр талымсыз булган, битарафлык күрсәткән дигәнрәк фикерләр белән килешүе кыен. Чөнки «Шура»ның рухы һәм җаны булган Р.Фәхреддиннең журналда иң күп урын бирелгән әдәбият мәсьәләләренә битараф калу ихтималы бик аз. Әйтик, әдәбият галиме М.Мәһдиев «Р.Фәхреддиновның шигырьдә талымсыз булуы — үзе бер кызыклы күренеш. Ул, журналында яхшы шигырь белән начар шигырьне аерып тормаса да, чын шигырьнең нәрсә икәнен аңлаган булса кирәк»,[1] дип язган иде. Яисә Зариф Бәшири хатирәләрендә: «Үз вакытында «Сәлимә» шикелле шактый матур әдәби нәрсәләр язган Риза Казый нәрсә өчендер: «Мин әдәби нәрсәләрне матур иттереп эшли дә, төзәтә дә алмыйм, әдәбияттан, бигрәк тә шигырьдән хәбәрем дә аз!» дип, әдәби нәрсәләргә кул салмый иде,[2] дигән юллары бар. Р.Фәхреддиннең бу очракта үзе турында әдәбият өлкәсендә хәбәрсез дип әйтүенә нигезләнеп, аны талымсыз һәм битараф дип санау дөрес булып бетмәс. Әлеге сүзләрне ул гыйльми хезмәтләр белән күбрәк шөгыльләнү максатыннан һәм шигъриятьтә яшьләргә

өстенлек биргәнлектән әйткән булса кирәк. З.Бәширинең үз сүзләре белән әйткәндә, Риза Казыйның «үзе редактор, үзе секретарь, үзе әдәби сотрудник, хәтта редакциягә килгән хат һәм материалларны да күчереп чыгучы»[3] булганлыгын һәм «Шура» журналының ике атнага бер чыкканлыгын искә алганда, әдәби, шигъри әсәрләрне журнал өчен әзерләүне редакциянең башка бер хезмәткәре, төгәлрәге, үзе дә шагыйрь булган З.Бәширигә тапшыруы мантыйкка сыешлы һәм табигый. Ризаэддин Фәхреддин Шәрекъ әдәбияты һәм шигъриятеннән, шулай ук Европа, аеруча татар шигъриятеннән хәбәрдар булып кына калмыйча, татар әдәбияты тарихына мәртәбәле өлеш керткән галим дә. Татар шагыйрьләреннән Габдерәхим Утыз Имәни, Акмулла, Шәмсетдин Зәки, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Каргалый һ.б. шигъри әсәрләреннән бер өлеше беренче мәртәбә Р.Фәхреддин тарафыннан җыйналып, аның «Асар» исемле хезмәтендә дөнья күргәнлеген онытмаска кирәк.

«Шура» журналы төрки-татар әдәбияты тарихын барлау, өйрәнү һәм пропагандалау буенча зур эшчәнлек алып барган.

Р.Фәхреддиннең Шәрекъ һәм Көнбатыш әдәбиятларына, шул исәптән, төрки-татар әдәбияты һәм әдипләренә мөнәсәбәте «Мөсамәрә (Мәшрикъ берлә мәгъриб йолдызлары)»[4] исемле мәкаләсендә бөтен тирәнлеге белән чагылыш тапкан. Автор бу мәкаләсендә Шәрекъ һәм Гареб шагыйрьләрен, фикер ияләрен бер-берләре, ягъни Мәгарри, Ибне Мокаффәгъ, әл-Кятибләрне Һюго, Рабле, Сен-Симон, Вольтерлар белән чагыштырган. «Ислам дөньясындагы берлә Аурупадагы мөхәррирләр вә шагыйрьләр арасында бер-беренә охшаганнары бар... Гарәп лөгатендә бәлягать (*матур һәм төзек сөйләм - Р.М.*) ишекләрене ачучы Габделхәмид әл-Кятиб берлә француз лөгатене һәртөрле богаулардан ычкындырып, иркен җибәрүче Виктор Һюго бер-беренә бик охшыйлар... Француз лөгатендә шигырьләргә мизан төзүче Буало гарәп лисанындагы шигырьләргә гаруз төзүче Хәлил бине Әхмәдкә охшыйдыр»,[5] - дип

капма-каршы ике дөнья «йолдызларының» җәмгыяви, әдәби үсештәге охшаш якларын билгеләп, янәшә тасвирлаган, фикерләрен конкрет мисаллар белән дәлилләгән. Шунда ук «Уфада торган вакытларымда русларның Пушкин, Лермонтовлары, фарсыларның Фирдәүси вә Сәгъдиләре һәм дә Хәйям вә Фөзулиләре, гарәпләрнең Зөһәйер вә Ләбидләре булганда бездә шунлар җөмләсенә тезелерлек кешеләр булмасмы дип хыял берлә йөрдем. Хәтта тәҗрибә кылып карау касды берлә Һибәтулла ишан, Габдеррахман Тайсуганый, Шәмседдин Суфый, Әбелмәних хаҗи вә могасыйрларымыздан Дәрдмәнд, Хәйдәр Чулпаный, Гашыйк Шәйда вә Дәрвиш Садыйк әфәнде шигырьләреннән нәмунәләр җыйдым да «Юаныч» исеме берлә бер мәҗмуга тәртип иттем»,[6] - дип Р.Фәхреддин татар әдәбияты тарихына карата электән үк үзенең ныклы фикере һәм карашы урнашканлыгын белдерә. Р.Фәхреддин мәкаләләренә, гомумән, Шәрекъ белән Көнбатышны чагыштырулар, параллельләр хас. Әдипләр генә түгел, башка даирә әһелләре (философлар, тарихчылар һ.б.) хакында язганда да ул чагыштырулар үткәрә.

Журналның 1908 елгы дүрт санында дәвам итеп чыккан «Милли матбугатымыз» исемле мәкаләсендә Р.Фәхреддин матбагачылык, гомумән, гарәп хәрефләре белән китап бастыру тарихы турында яза. Фәнни эчтәлекле бу мәкаләнең 5 нче бүлекчәсе «Әдәбиятымызның нигезләре» дип аталган.[7] Анда автор Казандагы «Азиатская типография»дә һәм Казан университеты матбагасында гарәп хәрефләре белән беренчеләрдән булып басылган төрки-татар әдәби әсәрләре турында сүз алып бара. Төгәлрәге, Аллаһыяр Суфыйның «Сөбател-гаҗизин», Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кыйссасы, «Ләтаифе Хуҗа Насретдин», Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» әсәре, «Бәдәвам», «Кисекбаш»... - барлыгы 34 исемдәге, 1802—1852 елларда нәшер ителгән әдәби китаплар турында яза. Р.Фәхреддин бу мәкаләсендә «Кыйссаи Йосыф» әсәре авторының исеме Гали икәнлеге ачыклануын беренче мәртәбә яза. Мәкаләдә

әсәрнең Болгар дәвере әдәби ядкяре булганлыгын үзенең «Мәшһүр хатыннар» китабында билдергәнлеген искә ала.[8] «Мәшһүр хатыннар» китабын укыганнан соң Шәһәр Шәрәф «Кыйссаи Йосыф» әсәренең басма нөсхәләренә керми калган, әмма әсәр авторының исеме күрсәтелгән ахыргы ике юлын билдергәнлеген яза. Мәкаләдә шулай ук Әбелмәних Каргалый, Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә...», Җәмалетдин Бикташиның «Фәзаилеш-шөһүр» китаплары хакында язганда автор әлеге шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләрен моңарчы үзенең «Асар» хезмәтендә язып үткәнлеген дә искәртеп барган. Ягъни, Р.Фәхреддин әдипләр турында чыганакларга дә ишарә иткән.

«Шура» мөхәррире Р.Фәхреддин журнал укучыларның төрки-татар әдәбиятына кагылышлы күп санлы сорауларына тәфсилле җаваплар да биреп барган. Мәсәлән, госманлы төрекләре тарафыннан иҗат ителеп, уртак төрки әсәрләргә әверелгән, аеруча Идел-Урал татарларында гасырлар дәвамында иң яратып укылган «Сәед Баттал газый» кыйссалары һәм Мөхәммәд Чәләбинең тезмә «Мөхәммәдия» әсәре, Габдеррәхим Утыз Имәни турында укучылар сорауларына җаваплар бирелгән.[9] Шулай ук Һибәтулла Каргалыйның мәшһүр «Тәндә җаным...» шигыре турындагы төрле фикерләрне Р.Фәхреддин журнал битләрендә нигезле дәлилләр белән исбатлап, тәгаенләп бирә.[10] Бигрәк тә «Тәндә җаным...» шигыренең Казанда Мөхәммәдвәли Яхъязадә басмаханәсендә хаттат Лотфулла Әлмәти[11] кулы белән язылган нөсхәдән ташбасма (литография) ысулында 1860 елда нәшер ителгән «Китабе диване Ризаи» җыентыгында дөнья күрүе мөнәсәбәте белән татар укучыларында беркадәр аңлашылмаучылык туган булган. Чөнки китапның «диван» дигән атамасы традиция буенча аерым бер (бу очракта Ризаи исемле) автор әсәрләре булуны дәгъва итә. «Диване Ризаи» китабының иң ахыргы сәхифәләрендә урнаштырылган «Тәндә җаным...» шигыренең тексты Р.Фәхреддиннең «Асар» хезмәтендә дә бирелгән була. Шул сәбәпле кайберәүләр

авторлык мәсьәләсендә шик-шөбһәгә төшкәннәр. Хакыйкатьтә «Китабе диване Ризаи» исеме белән басылган шигъри җыентыкны асылда «Нәҗҗарзадә» исеме белән танылган азәрбәйҗан шагыйре Ризаэддин бине Ибраһим, госманлы шагыйре Исмәгыйль Хаккый, төрки-татар шагыйре Өмми Кәмал шигырьләре һәм Һ.Каргалыйның «Тәндә җаным» шигыре тәшкил итә. Болар Габдеррәхман әл-Әстерханинең «Шура»да дөнья күргән язмасында тәфсилләп аңлатылган.[12] Китапның «диван» дип аталып та, аерым бер автор әсәрләре җыентыгы булу кысасында калмау сәбәпләре журналның шул ук санында басылган Рәхмәтулла Елкибаев хатыннан аңлашыла. Хат авторы үзенең хаттат Лотфулла Әлмәти белән таныш булганлыгын белдергән, «Китабе диване Ризаи» хакында Л.Әлмәти әйткән сүзләрне язган: «Аның соңгы ягындагы касыйдәләренең байтагын мәдрәсәдә вакытта төрле китап читләреннән күчереп алган идем. Бонлар бервакыт бөтенләй югалып бетәрләр әле, мин монда кыстырып бастырсам, бәлки онытылмаска сәбәп булыр дип, язып куйдым. Кем әсәрләредер инде, анысын бер дә белә алмадым.»[13] Елкибаев хатирәсеннән соң Һибәтулла Каргалыйның улы Габделхакның «Тәндә җаным...» касыйдәсе, һич шөбһәсез, әтисенеке булуы турында раслап язган сүзләре бирелгән.[14] Р.Фәхреддин бу дәлилләрне берләштереп, үзеннән дә өстәмә язып, бәхәскә нокта куйган һәм шик-шөбһәләргә урын калдырмаган.

XX йөз башы — татар әдәби тәнкыйтенең формалашу чоры. Башка әдәби теоретик процесслар кебек үк, татар әдәби тәнкыйтенең асыл мәсьәләләре дә шул чордагы вакытлы матбугат битләрендә күтәрелә, фәнни бәхәсләр объектына әйләнә, төп нигез элементлары формалаша һәм ныгый. «Шура» журналында бу мәсьәлә әдәбият белеменең иң җитди проблемаларыннан берсе буларак күтәрелгән. Татар әдәби тәнкыйте тарихын өйрәнгән Р.Мөхәммәдиев татар әдәби тәнкыйте XX йөз башы вакытлы матбугатында, аерым алганда, «Вакыт», «Йолдыз», «Шура» битләрендә туды, үсте һәм ныгыды дип язган иде.[15]

«Шура» журналының иң беренче санында ук Р.Фәхреддиннең әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләсе басылган.[16] Мәкаләдә журнал битләрендә «Тәкъриз вә интикад» исемле махсус бер баб-рубрика ачылуы, «тәкъриз» һәм «интикад» терминнарының ни нәрсәне белдерүе яхшылап аңлатылган.

Аерым алганда, Р.Фәхреддин болай дип яза: «Гүзәл сәератлы, күп мәгълүматлы мөхәррирләр вә яки, көчләнеп улса да, анларга охшарга тырышучылар әсәрләренең интикад ителдегене гаять рәхәтлек үзәрендә сәер итеп торырлар. Зирә әсәрләренең интикад ителмәсеннән анлар истифадә итәрләр вә кәнделәренең мәсләкләрендә улан төзеклек вә бозыклыкны аңлап, үзенә күрә ислях чараларына керерләр. Гасырдашларымыздан бер кемсәгә «Шул әсәрләреңезгә исемеңезне ничөн куймадыңыз?» димеш идек. Ул да безләргә: «Интикад ителдегене күрмәк вә шуңа күрә дә бер мәсләк интихаб итмәклегем өчен! Исемем зикер ителсә иде, дустларым мәдех, дошманнарым зәм итәрләр, әмма бәңа нә файда улыр?» диде.»[17] Әлеге соңгы сүзләр авторның үзе турында булса кирәк. Чөнки Р.Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәф истәлекләрендәге «Әткәйнең күп еллардан соң сөйләгән сүзләре: «Сәлимә» белән «Әсма»ны язуыма сәбәп — роман тәртип итү генә түгел иде, бәлки күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып, укучыларга ирештерү иде. Духовное собраниедә эшләвем аркасында, шул әсәрләр хакында булачак яхшы вә яман фикерләрне язганны иркенләп ишетер өчен, әсәрләргә үземнең исемемне куймадым, псевдоним белән язган идем,»[18] - дигән юллардан бу фараз тулаем раслана.

Р.Фәхреддиннең псевдоним белән язуы турында сүз чыккач, шуны да әйтеп узарга кирәк. Ул хәтта 1917 ел ахырында да (!) журналда Кубкинскийның «Сәлимә», яки «Гыйффәт»кә карата басылган мәкаләгә җавап сүзендә дә үз әсәре икәнлеген белдермичә, имзасын «Гафил бине Габдулла» дип куеп, өченче зат исеменнән сөйли.[19] Гәрчә күп еллар элегрәк татар матбугатында «Сәлимә» вә

«Әсма» романнары Риза әфәнде әсәрләре идеке сөйләнмәктәдер»[20] дигән язмалар да чыккан була.

Солтан Рахманколый тарафыннан А.С.Пушкиннан татарчага тәрҗемә ителгән «Дубровский» әсәренә «Шура»да Р.Фәхреддиннең тәнкыйть мәкаләсе басылган. Мәкалә авторы боярлар-крестьяннар арасындагы вакыйгалар турында, «кәнди мәгыйшәтебездән алынып» әдәби әсәрләр иҗат ителсен иде, дигән теләген белдерә.[21] Үз милли җирлегебездәге крестьяннар тормышына нигезләнеп әдәби әсәрләр иҗат итү зарурлыгы мәсьәләсен күтәреп, Р.Фәхреддин татар әдәбиятының халыкчанлыкка һәм тарихи жанрга игътибар юнәлтергә тиешлегенә ишарә итә.

Ризаэддин Фәхреддин 1914 елда оренбурглы «Шаһиәхмәд углы»ның тәнкыйть хакындагы соравына, «Бер китапның интикад кылынуы ул китапның эштән чыгуыннан бигрәк, эшкә керүенә сәбәптер. Интикад сәбәбеннән моталәга юллары ачылыр, бик күп яңа фикерләр хасил булыр, тәдкыйк вә тәхкыйк мәйданнары киңәер, күп гакыллар эшкә керешерләр, мөхакәмәләр, мовазәнәләр башланыр. Мөәллифләр сайланырлар, араларындагы аермалар күрелер, халыклар яхшы берлә яманны аерырга үгрәнерләр»,[22] дип җавап бирә. Һәм шунда ук «интикад» турында махсус мәкалә язачагын белдерә. 1916 елда аның бу мәсьәләгә багышланган «Интикад вә тагын» исемле мәкаләсе басылып чыга. Р. Фәхреддин мәкаләсендә «тәнкыйть» сүзенә тәфсилле аңлатма бирелгән, тәнкыйтьнең асылы һәм хасиятләре турында да фәлсәфи фикерләр әйтелгән. Тәнкыйтьнең әһәмиятен Р.Фәхреддин «Интикад», әгәр дә шартлары ригаять ителсә вә өслүбе дә гүзәл булса, әсәр сахибе өчен дә, укучылар өчен дә файдалы булыр. Адәм угылы үзе хакында «мәдех» кенә түгел, бәлки «мәдех» берлә берлектә косурлары сөйләнүне дә ишетергә тиешле. Мәдех кенә ишетеп тору инсаннар өчен иң зарарлы нәрсәдер. Әгәр дә «мәдех»нең зарары яхшы аңлашылып җитсә иде, дошманнар үз дошманнарыны зәм итәчәк урында, мәдех кенә итеп торырлар иде»,[23] дип билгели. Автор бу

мәкаләсендә шәригатьнең һәм мөселманнарның тәнкыйтькә карашлары һәм мөнәсәбәтләре турында киң мәгълүмат бирә. Шунлыктан тәнкыйтьнең шартларын бәян иткәндә аларның шәригать таләпләренә туры килергә тиешлекләрен дә ассызыклап үтә. Ул тәнкыйть шартларын төгәл үтәлергә тиешле кагыйдә буларак сыйфатлый. Р.Фәхреддин тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә булырга тиешле төп 8 шарты хакында яза. Сүз ахырында ул тәнкыйтьченең инсафлы, гадел, тәнкыйтьләнүчегә карата дустанә булырга һәм үз эшен яхшы белергә тиешлеген ассызыклап үтә.[24] Шул рәвешчә, Р.Фәхреддин тәнкыйтьнең асылын ачып бирә һәм җентекләп аңлата.

«Шура»да 10 ел дәвамында 227 авторның һәм (авторлары билгесез булган) 997 шигъри әсәр дөнья күргән. Анда мәшһүр татар шагыйрьләреннән Дәрдмәнднең барлыгы 28 шигыре, Г.Тукайның 5, Ш.Бабичның 24, С.Сүнчәләйнең 27, М.Гафуриның 8, З.Ярмәкинең 14, Н.Думавиның 10, З.Бәширинең 8 шигъри әсәре басылып чыккан. Шулай ук мәгълүм шагыйрь һәм әдипләрдән Вакыйф Җәлал, Мирхәйдәр Фәйзи, Хәбиб Исхакый, Габдулла Мостакаев-Биги һ.б. да шигырьләре басылган. Журналда чыккан шигырьләр арасында саф лирик, тирән фәлсәфи эчтәлекле символизм, суфичылык һ.б. агымнар йогынтысындагы шигырьләр, үгет-нәсыйхәт, вәгазьчелеккә корылган такмак сыман, примитив тезмәләр дә бар.

«Шура» битләрендә әдәби эшләнеше ягыннан түбән сыйфатлы шигъри әсәрләр дә дөнья күргән. Әдәби җәһәттән беркадәр йомшаграк, «тозсызрак» әсәрләрнең басылып чыгуының да сәбәпләре журнал мөхәррире һәм идарәсенең дикъкатсезлегендә түгел. Беренчедән, «Шура»ның иң беренче санындагы программ мәкаләсендә журналның «мөшавәрәт», ягъни киңәш мәйданы дип белдерелеп, төрле фикерләр һәм төрле карашлар кабул ителеп урын алачагы турындагы сүзләр белән аңлатыла. Икенчедән, бу хәл Р. Фәхреддин һәм Рәмиевләрнең кеше фикеренә һәм иҗатына сабыр вә ихтирамлы карашлары белән бәйле.

Журналда төрки һәм мөселман әдәбиятларының үсешләренә мөһим йогынты ясаган әдипләрнең иҗатларына зур игътибар бирелгән. «Шура» сәхифәләрендә Шәрекънең әдәби йолдызларыннан Мәгарри, Мөтәнәбби, Сәгъди, Хафиз, Хәйям, Фөзули, Нәваи, Ясәви кебек затларның тормышлары һәм иҗатлары белән Ризаэддин Фәхреддин һ.б. авторлар журнал укучыларны тәфсилләп таныштырганнар. Журналда азәрбәйҗан әдипләреннән Фөзули һәм Мирза Фәтхегали Ахундовларга Р.Фәхреддиннең махсус мәкаләләре багышланган. Фөзули хакындагы мәкаләләрдә Р.Фәхреддин аның төрки телдә язуына зур әһәмият бирә һәм аны төрки телдә иҗат иткән шагыйрьләрнең беренче урындагысы дип белдерә.[25] Төрки телдә шигырь иҗат итү осталарыннан икенче урында Галишер Нәваи тора, дип яза мәкалә авторы.[26] «Фөзулинең шигырьләрене укыдыкларында әдипләр хәйран калырлар, моңа мәфтүн булырлар. Әгәр дә җир йөзендә төреклек (ягъни, төркилек - Р.М.) югалса иде, Фөзули илә Хамид әсәрләре төреклекне яңадан тергезергә кадыйрлардыр. Фөзули ... төрек телендә әсәрләр язып таратмак тугрысында бер ишек ачты вә башкаларга үрнәк булды. Бик күп төрек галимнәре вә төрек әдипләре төшкән хатага Фөзули төшмәде. Бәлки үз телендә көйләде вә үз шивәсе илә җырлады»[27] дип, Р.Фәхреддин әдипкә карата зур ихтирамын белдерә. Автор Фөзули хакында язганда аның Идел буе татар әдәбиятына йогынтысы зур булганлыгына да игътибар итә. «Шура»да Фөзули шигырьләреннән үрнәкләр дә басылган.

Мәшһүр үзбәк әдипләреннән Галишер Нәваи хакындагы мәкалә шулай ук Р.Фәхреддин тарафыннан язылган. Аның да төрки телдә иҗат итүенә сокланып, мәкалә авторы түбәндәгеләрне яза: «Галишер, төрки улдыгы хәлдә, фарсыча шигырь сөйләүчеләрнең иң могтәбәрләреннән мәгъдүддер. Төрек әдәбиятыны иң элек ошбу зат тәэсис итте диелсә, мөбаләга улмаз. Бундан мокаддәм әдәби сурәттә төркичә язучы кемсә улмадыгы мәрвидер... Галишер ялңыз шагыйрь генә дәгел, бәлки буныңлә бәрабәр

бөек бер хәким вә фәйләсуф иде... Фарсы лисаныны сәүмеш вә гүзәл шигырьләр сөйләмеш исә дә, ана теле улан төркигә мәхәббәте дәхи зиядә вә камил иде.[28]

Ризаэддин Фәхреддиннең журналда гарәп әдәбиятына нисбәтле мәкалә һәм язмалары Әбүл-Галә әл-Мәгарринең иҗаты һәм тормышына багышланган. Журналда алар нигездә Мәгарригә багышланган үз хезмәте[29] уңаеннан «Шура» редакциясенә килгән аерым хатлардагы полемик фикерләр уңаеннан язылган. Бер язмасы исә журнал укучыларыннан Габдулла бине Сәлимнең «Әлфе ләйлә вә ләйлә» исемле китапның авторы кем булуы турындагы соравына җавап рәвешендә басылган. Җавабында Р.Фәхреддин Шәрекъ һәм Европа халыкларында зур шөһрәткә ирешкән «Әлфе ләйлә вә ләйлә» китабын Шәрекъ галимнәре фарсыларга нисбәт итүләрен һәм аның сәбәпләрен тәфсилләп аңлата.[30]

Мәшһүр гарәп шагыйрьләреннән X йөздә яшәгән Мөтәнәббинең тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында Р.Фәхреддин 1916 елда күләмле очерк-мәкаләсен бастыра.[31] Ул «Шигырь пәйгамбәре» дип мәгъруф булган Мөтәнәбби Ислам дөньясында гына түгел, бәлки бөтен дөньяга мәгълүм бер адәмдер»[32] һәм Мөтәнәббине японнар, руслар, әрмәннәр һәм европалыларның да белүе турында яза. Р.Фәхреддин Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенең Сәед Шәриф исемле мөдәррисе тарафыннан Мөтәнәбби шигырьләренең беразы татарчага тәрҗемә ителгән булуы турында да хәбәр бирә.[33] Гарәп шагыйре Мөтәнәббинең дөньякүләм шөһрәтен икърар итеп, «бүген Мөтәнәбби сәламәт булып та, букчасына «Мөтәнәббигә тапшырылсын», дип нинди генә урындагы почта сандыгына нинди генә тел вә нинди генә язу берлә адрес язылып хат салынса иде, туп-тугры Мөтәнәбби торган урынга барыр вә үз кулына бирелер иде»,[34] дип яза Р.Фәхреддин. Шигырьләрен анализлап, алар хакында «бәлягать, фәсахәт вә мәтанәт игътибары берлә Мөтәнәббинең шигырьләре бик югары урындадыр. Шигырьләренең күбесе мактану, шелтәләү, баһадирлык, хикмәт вә фәлсәфәгә даир булып, мәгънәләре бик нечкә вә бик киң булу берлә

имтиязлыдыр. Гыйшык вә мәхәббәт хакында шигырьләре аз, әмма бар кадәресе гүзәл. Мәрсияләре әсәрле. Бик күп шигыре әмсал урынында йөридер. Фәйләсүфәләрне хәйран калдырырлык рәвештә хикмәтле вә мәгънәле шигырьләре күп. Үзеннән соң килгән шагыйрьләр, әдипләр моның шигырьләреннән, нәсерләреннән истифадә кылдылар вә бу көндә дә кылалар,[35] дип бәяли.

Р.Фәхреддин Шәрекъ даһиларының фәлсәфи иҗатларын һәм тәрҗемәи хәлләрен өйрәнүгә Европа галимнәренең зур игътибар бирүләрен, әмма шул даһи әдипләрнең варислары булган мөселманнарның бай мирасларына тиешле әһәмият бирмәүләрен һәрчак искәртеп тора.

«Шура» журналында Хафиз, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Мирза Бәдил кебек фарсы-таҗик әдәбияты классиклары хакында аерым мәкаләләр басылган. Алар да нигездә Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан язылган.

Р.Фәхреддин Хәйямның европалылар тарафыннан гаять хөрмәтләнүе, өйрәнелүе хакында җентекләп яза. «Франк галимнәренең бер кыйсме Ибне Хәйямне «Мәшрикъ Вольтеры иде дидекләре хәлдә, икенче бер кыйсме «бөйлә димәк аны дәрәҗәсеннән төшермәк улыр, бәлки Вольтер, Байрон, Шопенһауэр кеби мөтәфәккирләрнең җөмләсеннән җыеп бер инсан вөҗүдкә китермәк мөмкин улса, иштә бу Гомәр әл-Хәйям улыр иде», дидекләре мәрвидер. Франкларда улан яңа фәлсәфә Гомәр әл-Хәйям тарафыннан вөҗүдә китерелмеш фикерләрнең нәтиҗәсе идеке күп галимнәр тарафыннан игътираф ителмештер»,[36] дип язып, мәкалә авторы Хәйямның европалылар алдында никадәрле абруйлы икәнлеген аңлата. Р.Фәхреддин журналда Гомәр Хәйям турында Мисыр, Төркия һәм рус матбугатында язылган макәләләр хакында библиографик белешмә туплап бирә.[37]

Шул рәвешчә, бөек галим «Шура» журналында татар әдәби тәнкыйтен һәм теориясен, татар һәм Шәрекъ әдәбиятлары тарихын өйрәнү, пропагандалау буенча күпкырлы, нәтиҗәле эшчәнлек алып барган.

Йомгаклап әйткәндә, «Шура» журналының әдәбиятка мөнәсәбәте, әдәби зәвыгы Р. Фәхреддиннең әдәбиятка карашларын чагылдыра. Гомумән, «Шура» журналының матбугат мәйданында бай энциклопедик татар журналы булып танылуы - мөхәррире Р.Фәхреддиннең фидакяр эзләнүләре һәм чиксез тырышлыгының нәтиҗәседер.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Мәһдиев М.С. Реализмга таба. XX йөз башына татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре. - Казан: ун-т нәшр., 1989. - 34 б.

2. Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар: (Язучы истәлекләре). - Казан: Таткитнәшр.,1968. - 88 б.

3. Шунда ук. - 87 б.

4. Р.Ф. Мосамәрә (Мәшрикъ берлә мәгъриб йолдызлары) //Шура. - 1914. - №22. - 701-704 б.

5. Шунда ук. - 701 б.

6. Шунда ук. - 702 б.

7.Фәхреддин Ризаэддин. Милли матбугатымыз: 5. Әдәбиятымызның нигезләре //Шура. -1908. - №21. - 673-675 б.

8. Ризаэддин бине Фәхретдин. Мәшһүр хатыннар: Ислам әсәрләрендә вә әһле Исламга күпме хезмәт күстәргән хатыннарың тәрҗемәи хәлләре бәян иделән бер китаптыр. - Оренбург, 1903. - 307-308 б.

9. Мөрасалә вә мөхабәрә//Шура. -1913. - №1. - 26 б.; -1914. - №3. - 89 б.

10. Мөрасәлә вә мөхабәрә//Шура. -1910. - №13. - 409-411 б.

11. Лотфулла Әлмәтинең тәрҗемәи хәле аз өйрәнелгән. Аңа кагылышлы чыганаклар шактый буталчык һәм ялгышлар белән тулы. Мәсәлән, игътибарсызлык нәтиҗәсендә, югарыда сүз барган «Диване Ризаи» китабының хатимәбетем өлешендәге Лотфулла Гатаулла углы Әл-Әлмәти исеме тупас бозылып, «Лотфулла Галиулла углы Алматави» дип укылган һәм «Татар әдәбияты тарихы»ның күптомлыгында шул хаталы рәвештә урын да алган. Нәтиҗәдә, Әлмәткә нисбәтле шәхес Алма-Атага нисбәт ителгән. Лотфулла Әлмәти кулы белән каллиграфик нәфис итеп язылган нөсхәдән күчерелеп литография ысулы белән Казанда басылган «Китабе диване Ризаи»дан тыш, шул ук ысул белән 1861 елда нәшер ителгән «Китабе мәүлүд шәриф», Габделхәким бине Габдеррәшид һәм Лотфулла Әлмәти тарафыннан төзелгән, татар телендәге язмалар һәм аңлатмалар белән 1861 елда басылган Европа һәм Азия картасы мәгълүм.

12. Мөрасәлә вә мөхабәрә //Шура. -1910. - №13. - 409-410 б.

13. Шунда ук. - 410 б.

14. Шунда ук.

15.Мухамадиев Р. Проблемы формирования татарской литературной критики. -Казань: Татар.кн.изд-во, 1982.. - С.19.

16. [Фәхреддин Ризаэддин]. Тәкъръйз вә интикад //Шура. -1908. - №1. - 24-26 б.

17. Шунда ук. - 24 б.

18. Шәрәф Ә. Әткәем турында истәлекләр //Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык=Ризаэтдин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. - Казань: Рухият, 1999. - 48 б.
19. Идарә. [Кубкинский тәнкыйтенә карата]//Шура. -1917. -№23/24. - 540 б.
20. [Шәһидуллин Шәрәфетдин]. Ризаэддин әфәнде бине Фәхреддин // Заман календаре. 1909 ел өчен /Мөрәттибе Шәрәфетдин Шәһидуллин. - Казан: Харитонов матбагасы,1908. - 37 б.
21. [Фәхреддин Р.]. «Дубровский»//Шура. -1908. - №3. - 84 б.
22. Мөрасәлә вә мөхабәрә //Шура. -1914. - №22. - 699-700 б.
23. Р.Ф. Интикад вә тәган //Шура. -1916. - №16. - 392 б.
24. Шунда ук. - 412 б.
25. [Фәхреддин Ризаэддин]. Фөзули //Шура. - 1912. - №7. - 194 б.
26. Шунда ук. - 194 б.
27. [Фәхреддин Ризаэддин]. Фөзули //Шура. -1913. - №11. - 351 б.
28. [Фәхреддин Ризаэддин]. Галишер Нәваи // Шура. - 1909. №17. - 514 б.
29.Ризаэддин бине Фәхреддин. Әбүл-Галә әл-Мәгарри. «Мәшһүр ирләр»дән икенче җөзьэ. - Оренбург: Кәримов-Хөсәенев вә шөрәкясе, 1908. - 72 б.
30. Мөрасәлә вә мөхабәрә//Шура. -1911. - №9. - 285 б.
31. [Фәхреддин Ризаэддин]. Мөтәнәбби//Шура. - 1916. - №10. - 235-236 б.; №11. - 257-259 б.; №12. - 281-282 б.; №13. - 305-307 б.
32. Шунда ук. - №10. - 235 б.
33. Шунда ук. - №12. - 282 б.
34. Шунда ук. - №10. - 235 б.
35. Шунда ук. - №11. - 259 б.
36. [Фәхреддин Ризаэддин]. Гомәр әл-Хәйям//Шура. 1911. - №4. - 98 б.
37.Р.Ф. Гомәр әл-Хәйям//Шура. -1914. - №17. - 514-517 б.

СҮЗЛЕК.

Мөсамәрә - кич белән сөйләшеп утыру
Мәшрикъ - көнчыгыш
Мәгъриб - көнбатыш
Лөгать - тел
Лисан - тел
Мизан - үлчәү
Гаруз - метрика
Касд - теләк
Могасыйр - замандаш
Нәмунә - үрнәк
Хаттат (хәттат) - каллиграф
Касыйдә - мәдхия, ода
Тәкъриз - мактап бәя бирү
Интикад - тәнкыйть
Сәератлы - табигатьле
Рәхәтлек үзәренә сәер итү - рәхәтлек белән күзәтү
Истифадә итү - файдалану

Кәнде (и) - үзе
Ислях - үзгәртү
Кемсә - кеше
Интихаб - сайлау
Зикер итү - искә алу
Мәдех - мактау
Зәм итү - шелтәләү
Моталәга - өйрәнү
Тәдкыйк - җентекләп тикшерү
Тәхкыйк - хакыйкатькә чыгару
Мөхакәмә - хөкем чыгару
Мовазәнә - тигезлек саклау
Мөәллиф - китап язучы
Тагын - хурлау
Ригаять ителү - хөрмәтләнү
Өслүб - ысул
Әсәр сахибе - әсәр авторы
Косур - кимчелек
Инсан - кеше
Мәфтүн булу - нык соклану
Тергезергә кадыйр - тергезергә көче җитә
Могтәбәр - хөрмәтле
Мәгъдүд - саналучы
Тәэсис итү - төзү
Мөбаләга - арттыру
Мәрви - риваять ителгән
Хәким - акыл иясе
Дәхи зиядә - тагын да күбрәк
Мәгъриф - танылган
Бәлягать, фәсахәт вә мәтанәт игътибары берлә - матурлык, ятышлылык һәм куәтлелек ягыннан
Даир - кагылышлы
Имтиязлы - аерылып торган
Мәрсия - элегия
Әмсал - мисаллар
Кыйсем - өлеш
Бөйлә - болай
Мөтәфәккир - фикер иясе
Җөмләсен - барысын
Вөҗүдкә китермәк - ясамак
Иштә - менә
Игътираф ителү - танылу

III БҮЛЕК. ДИН ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ
ГЛАВА III. РЕЛИГИЯ И ОБЩЕСТВО

Равил Үтәбай-Кәрими

РИЗАЭДДИН БИНЕ ФӘХРЕДДИН - ИСЛАМИЯТ САКЧЫСЫ (ТЕЗИСЛАР)

«Кемнәр үтенде потка,
Кемнәр сорады юкка...
Кемнәр ничек җан сакласа -
Мин таяндым бер Хакка».
Галим-шагыйрь Фәрит Яхин.

Мәгълүм ки, Ризаэддин бине Фәхреддин (1859-1936) - барча вөҗүден – булмышын Ислами тәгълиматка нигезләнгән-әсасланган дөньяга карашын милләткә хезмәт итүгә багышлаган, гомере буена туган халкы күңеленә армый-талмый бөек Коръәни Кәримнең изге нурларын чәчеп яшәгән мәшһүрләрдән мәшһүр - татарның шан-шәрәфле галиме генә түгел, бәлки олуг укымышлысы (мәрхүм Д.С.Лихачев әйтмешли, «ученых сейчас много - но нет учености»), әдибе, мәгърифәтче-педагогы, матбугат эшлеклесе, Шәрекъ белгече вә философы. Юкка гына микән ак күңелле Мифтахеддин Акмулла аны: «Хөрмәтле Ризаэддин - бер камил зат», - дип зурлый. Замандашлары ук Р.Фәхреддинне тирән мәгълүматлы Шәхес булганы өчен ихлас ихтирам иткәннәр. Аның изге максаты - мөселманнарны Ислами мәгърифәткә өндәү, гасырлар дәвамында килгән гафләт йокысыннан уяту, Шәрекъ халыкларына эчкерсез киңәшләр бирү... Аның дөньяга карашында Руссо, Локк, Спенсер, Бердяев, Франк, Ильин, Розанов кеби мәшһүрләрнең иҗтимагый-сәяси-дини сөземтәләрен дә күзәтергә мөмкин. Гакыл һәм гаделлек, эчкерсез ихласлык, тугрылык, зыялылык, халыкчанлык кануннарына корылган

җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларны Р.Фәхреддин халыкны Ислами тәрбияләүдә күрде. Нәкъ менә шуннан, ягъни югарыда күрсәтелгән мәлләргә нигезләнгән тәрбиядән чыгып, безләр ул тоткан мәсләкнең асылын аңлыйбыз да.

Әйтеп китешем лязим ки, хезмәтенең бөтен өлкәләрендә, барлык баскыч-тармакларында да Р.Фәхреддин мәгариф вә Ислам тарафдары булып калды.

Безләр аның, Исламият сакчысы буларак, эшчәнлеген түбәндәге өлешләргә бүлеп күзаллыйбыз:

- 1891-1906 нче еллардагы Мәркәз Диния нәзарәтендәге хезмәт чоры (гыйльме Коръәния; «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре»);
- 1906 - 1918 нче еллардагы бибәһа эшчәнлек;
- 1918 - 1923 нче еллар;
- 1923 - 1926 нче сәнәләр;
- 1926 - 1936 нчы дәһшәтле еллар.

Әйе, нәкъ менә ошбу дәвердә Р.Фәхреддин Русиядә тереклек кылучы мөселманнарның Ислами фикер хакименә әверелде. Хәер, аның даны Русия Шәркында гына түгел - бөтен дөньяга таралды. Гыйльме әсрар (теология) өлкәсендәге хезмәтләреннән «Гакаид» (берничә мәртәбә нәшер кылынган), «Мөхәммәд» (1909), «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» (1914), «Җәвамигуль кәлим шәрхе» (1916) һәм нәшер ителмичә калган «Әлбәлягуль мөбин» (1924) китапларын атап китәргә тиеш булабыз.

Кыскасы, Р.Фәхреддин Ислами өлкәдәге эшчәнлеге белән халкыбызның дини-иҗтимагый хәятында эчке бер дәрт, зур илһам белән катнашкан, бу өлкәдә дә килер буыннарга хезмәтләр калдыруын үзенең инсани бурычы итеп санаган.

Ф.Г.Ислаев

РУСИЯДӘ ИСЛАМ-НӘСАРИ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН

Халкыбызның мәшһүр галиме Ризаэддин Фәхреддиннең бай мирасында ислам-нәсари мөнәсәбәтләре турында актуальлеген югалтмаган күпкырлы, тирән һәм мөһим фикерләр тупланган. Кызганыч ки, хәзергә кадәр олпат галимнең бу фәнни хәзинәсе галимнәр тарафыннан махсус тикшерелмәгән. Ислам һәм православие диннәре арасында булган мөнәсәбәтләр тарихы бүгенге көнгә кадәр нигездә чишелмәгән мәсьәлә булып кала бирә. Уебызча, Риза казыйның диннәр турындагы фикерләре тарихны өйрәнүчеләр өчен методологик әсбап булып тора алыр иде. Мәгълүм булганча, төрле китаплар, дәреслекләр, мәкаләләр аша бу мөнәсәбәтләр хакында халык арасында төрле уйдырмалар киң тарала. Соңгы вакытта Кавказда барган кангойгыч сугыштан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларының ислам диненә каршы фикер формалаштыру өчен мәкерле сәясәт алып баруын күрсәтеп китү зарур. Укучыга тәкъдим ителә торган мәкаләдә Ризаэддин Фәхреддиннең «Болгар вә Казан төрекләре» дигән сайланма әсәреннән файдаланыла, 1552 елдан алып Диния Нәзарәте оештырылган вакытка кадәр чорда ислам-нәсари, татар-урыс мөнәсәбәтләре хакындагы кайбер фикерләр хәзерге дәреслекләрдәге материаллар белән чагыштырылып бирелә.

Билгеле булганча, Казанны яулап алу походын Мөдһиш Иван тәре походы формасында оештыра: яшь патша үзенә көнчыгыштагы җирләрне («подрайская землица») яулап алу белән бергә яңа җирләрдәге мөселман һәм мәҗүси халыкларын православие диненә көчләп кертүне дә максат итеп куя. Алга куелган бу максатны тормышка ашыру өчен төрле патшалар гасырлар дәвамында күп көч куялар.

Риза казый бу хакта болай дип яза: «Шәһәргә керү белән руслар ирләрне һәммәсен кылычтан үткәрделәр, хатыннарны, балаларны хайван көтүе урынына көтеп, Мәскәүгә

алып киттеләр һәм алпавытларга өләштеләр. Хан үзе һәм сарай хезмәтчеләре - һәммәсе Мәскәүдә чукындырылды.. Өлкәне басып алганнан соң һәм тырнакларын батырганнан соң, руслар мәчетләрне, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ваттылар, җимерделәр, изге Коръән һәм башка китапларны яндырдылар. Язулы кәгазь һәм дәфтәрләрдән, язмалардан берсе дә калмады».[1]

Революциядән соң Диния Нәзарәтенең архивында сакланган тарихи ядкярләрне саклап калу өчен Уфадагы совет җитәкчеләренә язган ачык хатында мөфти ислам дине тарихына күзәтү ясап, бу вакыйгалар турында яңа фикерләр өсти: «Казан шәһәре алынганнан соң руслар бөтен авылларда йөреп байлыкны басып алдылар, мәчетләрне һәм мәдрәсәләрне җимерделәр, бик күп мөселманнарны чукындырдылар («керәшен нугае», «мәкруһ» дип йөри торган халыкларның күбесе - шул вакытта чукындырылган халыклар)».[2]

«Казан хөкүмәте бетү белән... гыйлем әһелләре Кавказга һәм Төркестанга качты. Кайбер авылларда кечкенә генә һәм күбесе яшерен рәвештә гыйбадәтханәләр ачылды, муллалар барлыкка килде». «Абыз ага» дип йөртелә торган бу муллалар ир һәм кыз балаларга үз өйләренә җыеп иман һәм намаз да өйрәтәләр иде».[3]

Татар халкы тарихындагы бу фаҗигале сәхифәләр Мәскәүдә чыккан хәзерге заман дәреслекләрендә бөтенләй икенче төрле тасвирлана: «Всем подданным бывшего Казанского ханства, даже упорно сражавшимся против русских, объявлена была милость и даны все права... Православная церковь мирно относилась к иноверцам и даже не думала, например, искоренять мечети, сохранившиеся не только вокруг Казани, но и в самом городе».[4]

Күргәнебезчә, дәреслектәге фикер Ризаэддин Фәхреддин фикеренә туры килми генә түгел, бәлки бөтенләй капма-каршы. Дөреслек кайсы якта икәнлеге тарих белән кызыксынган һәрбер кешегә мәгълүм, шуңа күрә бу уйдырмага аңлатма бирүнең хаҗәте юк.

Риза казый татар морзаларын чукындыру мәсьәләләре, аларның Русия тарихында тоткан урыны турында да фикерләр язып калдырган. Аның язуынча, «русларны һәм славяннарны «Россия мәмләкәте» хәленә китерүчеләр Екатерина иярченнәре булган немецлардан бигрәк, чукынган татар кенәзләре һәм мирзалары булды. Болар үз хөкүмәтләрен тәртипле һәм мәдәниятле бер хөкүмәт ясый алмасалар да, үз өлкәләрен үз кулларында тоту хакында чаралар табуга яраклы булмасалар да, «Олуг Россия» исемле мәмләкәтне төзү хакында руслардан артык хезмәт күрсәттеләр».[5]

Урыс кенәзләренә әверелгән татар морзаларына Риза казый ни өчен соң мондый бәяләмә биргән? Нинди язмыш чукынган татар морзаларын урыс патшасына тугрылыклы хезмәткә этәргән?

Казанны яулап алганнан соң Русия дәүләте татар морзаларын чукындыру өчен берничә гасыр дәвамында туктаусыз эш алып бара. Беренче мәртәбә морзалар Мөдһиш Иван чорында чукындырыла. Урыс патшасына хезмәткә күчкән татар аксөякләре яңа хуҗага тугрылыклы икәнлекләрен исбат итәргә тиеш булган. Ул заман өчен төп тугрылык билгесе булып урыслар диненә күчү саналган. Чукынган татар морзалары урыс кенәзләренә әйләнеп, мал-мөлкәтләрен саклап калалар.

Икенче мәртәбә морзаларны чукындыру XVII гасырның 80 нче елларында үткәрелә. 1680 елның 16 маенда морзаларны һәм йомышлы татарларны крестьяннары һәм утарлары белән патша карамагына күчерү турында фәрман чыгарыла. Сылтау итеп морза утарларындагы православный мәзһәбездә булган крестьяннарының ислам диненә күчү очраклары күрсәтелә. Бу указ нигезендә чукынган морзалар утарларын һәм крестьяннарын саклап калу гына түгел, бәлки дин алыштырган өчен 10 тәңкә акчага да тиенергә тиеш булалар.[6]

Указ турында хәбәр алганнан соң, Романов өязе морзалары патшага ирекле чукыну турындагы теләкләрен белдерәләр, православие диненә күчкәннән соң үзләренә

урыс кенәзе исемен бирүне үтенәләр. Бу теләкне патша бик теләп кабул итә, ә морзалар урыс кенәзе дәрәҗәсен алалар. Православие диненә күчкән өчен патша аларга хезмәт хакы билгели, хезмәттән өч елга азат итә. Чукынган очракта җинаять кылган морзалардан тартып алынган утарлары кире кайтарыла.[7]

1681 елның 24 маенда Романов һәм Ярославль өязләрендәге морзалар хакында яңа указ кабул ителә. Бу указ нигезендә мөселман морзалары утарларының чукынган туганнарына тапшырылу карала.[8] Шушы мәкерле ысул белән патша дин мәсьәләсеннән оста файдаланып, туганнар арасына низаг сала.

Морзаларны чукындыру турында төрле указлар әледәнәле чыгып торса да, алар иманнарын сатарга бик үк ашкынып тормаганнар, күрәсең. Аерым алганда, бу хакта Курмыш өязе морзалары 1682 елның 25 февраленә кадәр, бер атна эчендә, изге христиан диненә күчәргә тиеш дигән фәрман сөйли. Морзалар күрсәтелгән көнгә кадәр чукынмасалар, утарлары һәм җир биләмәләре чукынган морзаларга алып бирелергә тиеш була.[9]

Ул заманда Русиядә мәселман морзаларын эзәрлекләү очраклары Кырым ханына да билгеле була һәм ул Русия патшасына 1682 елның мартында язылган хатында болай ди: «Мәмләкәтегездә булган мөселманнарны көчләп һәм кыстап христиан мәзһәбенә кертәсез икән. Мондый эшләр падишаһлар дәрәҗәсенә лаек түгел. Бу бик яман эш. Бездә һәм бәхетле солтан кул астында хисапсыз дәрәҗәдә христианнар бар, безнең тарафыбыздан алар турында шундый бер эш булганы юк. Сез мөселманнарны дин мәсьәләсендә кыстамагыз, мөселманнар үз диннәрендә тыныч торсыннар»[10]

Кырым ханының әлеге кисәтүеме, әллә 1682 елның 27 апрелендә Русия патшасы үлгәннән соң тәхет өчен төрле төркемнәрнең үзара көрәше нәтиҗәсеме - әлегә билгеле түгел, тик бу чорда морзаларны христиан диненә күчерү турындагы указлар үтәлми кала. Ә элекке указлар нигезендә чукынганнар урыс кенәзләренә әверелә һәм тәмам урыслаша.

Ризаэддин Фәхреддин күзәтүе буенча, морзаларны чукындыру сәясәте Петр патша һәм аның варислары заманында да үткәрелә. Моны истә тотып, Риза казый болай дип яза: «Җирләрендә православный крестьяннары булган мөселман җир хуҗалары алты ай эчендә православный мәзһәбкә керергә тиешләр, шуңа риза булмаган мөселманнарның җирләре, йортлары һәм бөтен мөлкәтләре көчләп алыначак», - дигән фәрман чыкты. Бу фәрман 1729 елның 1 мартында, 1743 елның 28 сентябрендә тагын кабатланды. Чукынырга риза булмаган мөселман алпавытлар үзләренең җирләрен һәм мөлкәтләрен сатып яки залогка салып, акчалы булып калмасыннар һәм чукынудан котылмасыннар өчен, 1737 елның 21 сентябрендә: «Мөселманнарның русларга җир сатулары тыела» - дигән фәрман игълан ителде.[11]

Риза казый 1731 елда оештырылып, 33 ел буена татар-мөселман халкын чукындыру белән шөгыльләнгән махсус «Керәшен кантуры» турында да үз фикерен әйтеп калдырган. Аның керәшеннәрне икегә бүлеп каравы игътибарга лаек: «Рус хөкүмәте тарафыннан «Новокрещенская контора» ачылганнан соң чукындырылганнар - «мәкруһлар» дип, аннан элек чукындырылганнар «керәшеннәр» дип аталалар. Бу ике төркем арасында аерма зур. Керәшеннәр үзләренең иске төрек телен, кием-салымнарын саклап килсәләр дә, ислам диненнән һәм мөселманнардан ераклашканнар, христианлыкта торуларына артык пошынмыйлар».[12]

Шунысы аяныч, кайбер дәреслекләрдә, «Чукындыру конторасы»на бәяләмә биргәндә, аның татар-мөселманнар арасында озак еллар алып барган миссионерлык эшчәнлеге искә алынмый. Мисал өчен бер дәреслектән өзек: «Первые попытки обратить иноверцев в христиан относятся к XVII в. Более серьезные успехи были досигнуты в христианизации народов Поволжья, особенно после учреждения в 1740 году Конторы новокрещенских дел. По данным конторы, за 15 лет (1741-1756) она крестила 407 тысяч чувашей, черемис, удмуртов».[13]

Иң башта дәреслектә Чукындыру конторасын оештыру вакытын 1740 елда дип язу ялгыш икәнлеген күрсәтеп үтәргә кирәктер. Белгәнебезчә, ул миссионерлык учагы Казан губернасындагы Зөя (Свияжск) шәһәрендә, Богородицки монастыренда 1731 елда оештырыла. 1740 елда чыккан фәрман буенча Идел буендагы гайре урыс халкын масса төсендә көчләп чукындыру башлана. Дәреслектә чукындырылган халыклар арасында татарларның күрсәтелмәве бер дә очраклы хәл түгел - китап авторлары Русия хөкүмәте белән православие чиркәвенең татар-мөселманнарны чукындыру сәясәтен тарихтан махсус төшереп калдыралар. Кызыксынган укучы ул чордагы миссионерлык эше турында мәгълүматларны «Православные миссионеры в Поволжье» дигән китаптан ала ала.[14]

Ризаэддин Фәхреддин урыс халкының саны тиз артуны да чукындыру сәясәте белән бәйли: «Әгәр дә русларның мөселманнарны чукындыруга тырышулары беркадәр йомшак һәм уртачарак булса иде, рус халкы бу дәрәҗәдә үрчемәс һәм күбәймәс, ислам халкы да Болгар хөкүмәте вакытына караганда бу мәртәбәдә кимемәс иде. Болар мөселманнарны көчләп чукындыру юлына керделәр һәм шул сәбәптән ифрат дәрәҗәдә күбәйделәр».[15]

Русия хөкүмәте Екатерина Икенче, ягъни Әби патша тәхеткә килгәч, мөселман халкын көчләп чукындыру сәясәтенең нигездә тормышка ашмаганын аңлагач, ислам динен рәсми рәвештә танырга мәҗбүр була. Тик бу эшләр дә мөселманнарга вөҗдан иреге бирү нисбәтеннән түгел, ә Риза казый сүзләре белән әйткәндә, «Русия хөкүмәте ошбу эшләрне көймәсе комга утырганнан, картузы култыгыннан төшеп киткәннән, йомгак чуалганнан соң, теләр-теләмәс кенә эшләгән иде. Хәле әз генә төзәлү белән бу мәхкәмәне кысарга, муллаларны җәфаларга һәм алардан эт җиктерергә керешде».[16] Мондый сәясәт 1917 елгы революцияләргә кадәр өзлексез дәвам итә.

Гомумән алганда, урысча дәреслекләрдә ислам диненә нисбәтле уйдырмалар шактый. Шуларның тагын берсен

күрсәтеп китик: «Ислам призывал мусульман к священной войне против «неверных» - людей другой веры. В коране сказано, что мусульмане, убитые на такой войне, немедленно попадают в рай».[17]

Ислам дөньясында дингә көчләү юклыгы турында исә Ризаэддин Фәхреддин мондый фикер язып калдырган: «Дингә көчләү хакында ислам дөньясында бер генә кылыч та күтәрелгәне юк. Бу ислам тарихы белән таныш затларга мәгълүм...Христиан руханилары Аурупада төзелгән Ингзисиюн (инквизиция) мәхкәмәсе тарафыннан христиан диненә көчләү сәбәбеннән үтерелгән җаннарның дәфтәрләргә язылганнары гына да адәм ышанмаслык дәрәҗәдә күп. Шуларның яртысы утка салып яндырылган. Вөҗдан иреге хөкем сөргәнлектән, исламнарда мондый эшләр булмаганлыгы мәгълүм».[18]

Кызганыч ки, хәзергә кадәр Русиядә ислам диненең объектив тарихы эшләнмәгән. Ризаэддин Фәхреддиннең фикеренчә, «башкалар хакимияте астында яшәүче милләтләр өчен тарих белән шөгыльләнергә мөмкинлек юк. Тарихыбыз булмауның, ата-бабаларыбызның, кавем һәм кабиләбезнең хәлләре һәм гомер сөрүләре яхшы беленмәүнең сәбәбе үткәндәге галимнәрнең тик торулары, халкыбызның тарих гыйлеменә бәя бирмәүләре түгел, бәлки бу эшкә мөмкинлек булмау һәм заман тарафыннан ярдәм итмәүдер».[19]

Бу фикернең теркәлүенә йөз ел тирәсе вакыт үтсә дә, татар галимнәренең ислам тарихы өлкәсендә эзләнүләре зур уңышлар казана алмады. Җавабы - Риза казыйның югарыда китерелгән сүзләрендә. Икенче төрле әйткәндә, ислам, татар тарихы буенча объектив эзләнүләр мөмкинлеге бәйсезлек төшенчәсе белән тыгыз бәйләнгән.

Бу мөһим мәсьәләне чишү - киләчәк буын тарихчылары кулында. Русиядәге ислам тарихының төрле проблемаларын чишкәндә Ризаэддин Фәхреддиннең тарихчыларга калдырган васыятен онытмаска иде. Ул болай дип язган: «Гыйлем вә фәнгә хезмәт итәр өчен каләмеңнең хөр булуы, «хак» дип беленгән сүзнең кеше хәтере өчен яшерелеп калмыйча,

ачык сөйләшүе шарт. Бу эш гадәти адәмнәр кулыннан килә торган нәрсә түгел, бәлки бу - ялгыз әдәби батырлык ияләренә генә хас булган камиллек».[20]

Чыннан да, тик шулай эшләгәндә генә халкыбызның объектив дин тарихы язылыр дип өметләнергә була.

ИСКӘРМӘЛӘР

1 Ризаэддин Фәхреддин. Болгар вә Казан төрекләре. Казан. 1993.- 51-52 б.

2 Шунда ук - 245 б.

3 Шунда ук.

4 Богданов А.П. История России до петровских времен. М., Дрофа. - 1997. - С.199-200.

5 Ризаэддин Фәхреддин. Күрсәтелгән хезмәт. - 50 б.

6 Полное собрание законов Росиийской империи. (Далее - ПСЗ). - Т.2. - С.312-313.

7 Шунда ук. - С.267.

8 Шунда ук. - С.315.

9 Шунда ук. - С.403.

10 Ризаэддин Фәхреддин. Күрсәтелгән хезмәт. - 57 б.

11 Шунда ук. - 54-55 б.

12 Шунда ук. - 56 б.

13 Павленко Н.И. и др. Россия в конце ХУП - XIX веке: Учебник для 10 кл. М., Просвещение.- 1997. - С.93.

14 Ислаев Р.Г. Православные миссионеры в Поволжье. - Казань, 1999.

15 Ризаэддин Фәхреддин. Күрсәтелгән хезмәт. - 53 б.

16 Шунда ук. - 247 б.

17 Агибалова Е.В., Донской Г.М. История средних веков: Учебник для 6 кл. общеобразовательных учреждений. - М., Просвещение, 1998. - С.73.

18 Ризаэддин Фәхреддин. Күрсәтелгән хезмәт. - 227 б.

19 Шунда ук. - 52 б.

20 Шунда ук. - 171 б.

Ф.З.Яхин

РИЗА ФӘХРЕДДИНОВ ВАҺҺАБИЛАР ХАКЫНДА

Р.Фәхреддиновның ваһһабилар хакындагы мәкаләсе 1906 елда «Әл-гасрел-җәдид» («Яңа гасыр») журналының 2 нче санында дөнья күрә. Ул аны «Ваһһабилар кемнәр»? башы астында урнаштырган. Авторы Ризаэддин бине Фәхреддин, Уфа дип күрсәтелгән. Димәк, автор аны Уфа шәһәрендә яшәгән чагында ук язган, жанрына караганда ул, фәнни хезмәттән бигрәк, журналистик мәкалә стилендә эшләнелгән һәм фикерләрен публицистик калыпка корган. Шунлыктан бу мәкаләсен асылда сәяси юнәлештә иҗат ителгән публицистик әсәр дип карый алабыз.

Билгеле булганча, XIX йөзнең башлангыч чорында ук ваһһабичылык татар дөньясына үтеп керә. Шул ук йөзнең соңгы чирегендә иҗтимагый фикер үсешендә ныклап урнашкан алдынгы мәгърифәтчелек идеяләре дә ваһһабичылык тәэсирендә формалаша. Мәгърифәтчелекнең гәүдәләнеше булган «җәдидчелек»тә ваһһабичылык идеяләрен табуы кыен түгел. Асылда Р.Фәхреддиновның үзен дә, аның дини карашларын һәм тәрбия-әхлак тематикасын күргәндә нинди мәсьәләләргә зур игътибар бирүен дә искә алсак, бу яктан да аны ваһһабичы дип белдерә алабыз. Әмма бу карашларны татар әдәбияты һәм иҗтимагый фикере тарихында яктыртканда ваһһабичылык белән бәйләп карау әлегә актуаль булмады, шунлыктан ни сүзлекләрдә, ни фәнни мәкаләләрдә бу хакта ачык кына язылган һәм хәтта ваһһабичылыкның нәрсә икәнлеге аңлатылып бирелгән материалларны таба алмыйбыз. Хәтта ваһһабичылыкка караган үзенчәлекләр татар җәдидчелек хәрәкәтенең, татар мәгърифәтчелегенең асыл сыйфатлары итеп аңлатыла һәм тасвир кылына киләләр. Мәсьәлә киң планда алынып, һәрьяклап тикшеренү-эзләнүләрне, бәяләр бирүне таләп итә.

Ваһһабичылыкны прогрессив хәрәкәт дип карамау хата булыр иде. Шунысын алдан ук белдерергә тиешбез, согудиләрнең сәяси омтылышларында төп идеологик ко-

ралга әвереләдерелгән ваһһабичылык милли-азатлыкны хәрәкәтләндерү өчен дә актив файдаланылган.

Р.Фәхреддинов журналдагы мәкаләсен «Бу сүз башыны күрән затлардан бер чугысы: «Ваһһабилары белмәк нәдән лазем улды, беленмәсе лязим улан башка шәйләремез юкмы?» - дия бәхәс итәчәкләре күңелә кәлер», дип башлап китә һәм реаль училищеда укучы улының: «Әткәй? Ваһһабилар кемнәр?..» - дигән сорауны бирүен, аңа җавап биргәнендә генә бу мәсьәләгә дикъкать итүен белдерә. Урыс мәктәпләрендә укучы татар балаларына ваһһабилар хакында хаталы фикерләр бар икән. Мисалга И.Янчинның «География» (Ч.II, - изд. 25-ое. - Москва, 1904. - С.48) хезмәте алына һәм аннан ваһһабилар - «секта, не признающая Магомета» дигән билгеләмә китерелә. Шуннан соң Р.Фәхреддинов бу фикернең хата булуын аңлату өчен «Ваһһаби җәмгыяте» тарихын сөйләүгә күчә.

Мөхәммәд бине Габделваһһап бине СөләйманӘн-Ниҗәди Әт-Тәмйәми Әл-Ханбали (1703-1787), «Ваһһаби мәзһәбе»нә нигез салучы галим, үз чорының иң укымышлы затларыннан булган. Туган иле Йәмәндә белем алганнан соң Басра, Хиҗаз һәм Шам вилаятьләрендә сәяхәтләр итеп, анда исемнәре мәшһүр галимнәр белән очрашкан, алар белән кайнар бәхәсләр оештырган. Ул таркаулыкка дучар ителгән Ислам дөньясын ныгыту өчен җан ата. Шунлыктан шигый һәм сөнни мәзһәпләрдә урнашкан, бер-берсен инкяр итешүгә корылган каршылыкларны юкка чыгаруның, суфичылыктан һәм диндарлыктан, халык фикерен буып торганнарына күрә, котылырга кирәклеген яхшы аңлап эш иткән. Аның бу омтылышлары шул заманның галимнәре тарафыннан тәнкыйтькә очраган. Әмма Мөхәммәд бине Габделваһһап динне сафландыру, заман тузаныннан арындыру кирәклеген кайнар бәхәсләрдә дәлилләү юлын да тапкан һәм шул вакытларда ук аның теоретик карашлары да формалашкан. Аның «Китабу-тәүхид» хезмәтендә алар чагылыш тапканнар. Мөхәммәд бине Габделваһһап бу фикерләрен хаҗилар алдында да, гарәпләр арасында да

кайнарлык белән аңлата торган булган. Ул Ислам динен саф көенчә саклауны, Мөхәммәд пәйгамбәр заманындагы рәвешенә кайтаруны, бары тик Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси үзеннән теркәлеп алынган хәдисләр белән генә гамәл кылуны алга сөрә.

Р.Фәхреддинов шушы мәсьәләләргә тукталып, Мөхәммәд бине Габделваһһапның эшчәнлегенә уңай бәя бирә, аның үз артыннан күпләрне ияртә алуын да билгеләп уза һәм шул вакытларда Йәмәндә сәясәт белән шөгыльләнгән Габделгазиз шушы мәзһәбне үз максатларында файдалана башлавын да искәртә.

Габделагазиз бине Сөгуд ваһһабиларының җитәкчесе мәртәбәсенә күтәрелеп, бу мәзһәбкә сәяси төс кертә. Асылда диннең сафлыгы өчен көрәшкән ваһһабилар дин карендәшләре булган сөнни Төрек империясенә каршы азатлык хәрәкәте җәелдерәләр, Мәккәне үз кулларына төшерәләр, ваһһабилар буларак бик күп җирләрне буйсындыралар, хәтта Мисыр һәм Төрек мәмләкәтләренең гаскәрләре белән аяусыз сугышлар алып баралар. Р.Фәхреддинов ваһһабилар мәзһәбенең тәэсире тиз арада барлык Ислам дөньясына таралуын билгеләп уза. Гарәбстанда гына түгел, хәтта Һиндстанда да галимнәр Мөхәммәд бине Габделваһһапның фикерләрен яклап чыгалар. Ваһһабилыкны Р.Фәхреддинов асылда яңа бер мәзһәб булмыйча, «бәлки Исламны җәнабе Рәсүлуллаһ вә әсхабе гасырында улан садәлегенә вә табигый хәленә куймактан гыйбарәттер»[1], - дип аңлата. Әмма алар хакында һаман «Ваһһаби мәзһәбе» исеме астында яза. Мөхәммәд пәйгамбәр мәзһәбе буларак аңлатылган сөнниләрне инкяр итүчеләр буларак аларны бәяләү зур хата икәнлегенә аерым тукталып уза[2].

Ваһһабилар бу вакытларда мөселманнар арасында урнашып җиткән күп кенә йолаларны инкяр иткәннәр. «Бунлара күрә, үлекләр хозурына варып Аллаһтан хаҗәт сорамак, үлекләр исеме илә нәзерләр әйтмәк вә корбаннар чалмак, үлекләрдән ярдәм эстәмәк, каберләрә зиярат итәр өчен сәфәр әйләмәк, каберләр өстенә биналар сал-

мак, мәсҗедләргә манаралар куймак - мәнһи* эшләрдәндер»[3]. Р.Фәхреддинов ваһһабиларның шушы фикерләре белән килешүен белдерә, бу гамәлләрнең чыннан да Аллаһыга мөшриклек икәнлеген таный. Чыннан да Ислам дине бәла-казалардан бары тик Аллаһыга гына сыенуны таләп итә, гыйбадәт Аллаһыдан гайрегә дөрес түгел, чөнки бөтен галәмнең хуҗасы бары тик Ул гына. Бу - Мөхәммәд бине Габделваһһапның «Китабу-тәүхид»ендә генә түгел, бәлки мөселманлыкның нигезе булган иманның асыл эчтәлеген аңлатучы китапларда да тәфсилле язылган. Ә ваһһабилар һәммә йолаларны да тәүхид күзлегеннән уздыралар һәм тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән шәригатьтәге күп кенә хаталанудан гыйбарәт икәнлеген дәлилләп чыгалар. Әгәр дә татар әдәбиятының XIX нчы йөз башыннан үсешен күзәтсәк, ваһһабиларның йогынтысыннан безнең җәмәгатьчелекнең дә читтә калмаганлыгын күрербез. Ваһһабилар дөньяви карашларны дини схоластика белән сугаруга каршы килгәннәр, шуның белән фикер хөрлеген яклап чыкканнар. Шунлыктан аларны турыдан-туры фанатизмда гаепләүне хата дип бәяләр идем. Р.Фәхреддинов исә ваһһабиларны көферлектә гаепләргә омтылучыларның сүзләренә каты бәрелмичә генә, моны «гүзәл эш түгел» дип бәяли[4].

Ваһһабилар сугышка хәвеф намазы укып кергәннәр, тәкбир әйтеп көрәшкәннәр. Бу хәл Мисыр һәр Төрек гаскәрләрен куркуга салган. Мәкаләсендә Р.Фәхреддинов, тарихи чыганакларга таянып, Мисыр һәм Төрек гаскәрләре арасында ваһһабиларга карата симпатиянең шактый көчле булганлыгын да бәян итә. Ахырда: «Ваһһабилар - Рәсүл әкрам өммәтеннән вә безем дин карендәшемез улан мөселманнардыр»[5], - дип белдерә. Әмма аңа карап кына бу юлдагыларга иярүне кирәк эш дип санамый. «Шуйлә исә дә, - дип яза ул, - игътикад вә гамәл тугрысында мөтәббигать итәргә тиешле улан бер мәзһәб вар исә, ул да ялгыз Фәхрел-әнбия әфәндемез Мөхәммәд бине Габдулла Әл-Һашими Әл-Корәйши Әл-Мәкки Әл-Мәдинәи мәзһәбе-

дер. Мөмкин кадәр буның юлына иярмәк вә һич улмадыгында иярер өчен лязим улыр. Халыклар истәр ваһһаби улсыннар, истәр әшгари вә матриди мәзһәбендә улмак ла ифтихар тисеннәр, хаклык исә Рәсүлуллаһ юлында улмактадыр»[6].

Р.Фәхреддинов мәкаләсен шуның белән төгәлли һәм улына да бу рәвешле аңлатып биргәнлеген яза, урыс китапларындагы хаталы аңлау-аңлатуларга таянып эш итүнең буталуларга гына китерүен белдерә.

Ваһһабилар мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, аларның Ислам мәдәнияте үсешенә керткән өлешләре зур булганлыгын ассызыклап үтәргә кирәк. Әмма дин юлы, XYII нче йөз татар шагыйре С.Аллаһияр язганча, бик нәзек, анда бик тиз ялгыш юлга басарга, читкә чыгып китәргә мөмкин. Ничек кенә булмасын, дин ул рухани өлкә генә түгел, ул мәдәни, фәнни берәмлекләрне генә түгел, хәтта гадәти күзаллауларны да үз эченә ала, әхлакый нормаларны төзи. Тарихи үсеш дәверендә барлыкка килгән йолалар да нормалашып киткән икән, мәсәлән, Мәүлид бәйрәмен һ.б., аларны фундаменталистик-ревизионистик карашлардан чыгып инкяр итү динне сафландыра дип фикер йөртергә нигез була алмый. Ваһһабиларның фикерләре белән артык мавыгып китмичә, әмма мәдәниятебезне үсертүдә аларның идеяләреннән файдаланып, Р.Фәхреддинов кебек галимнәребез дөрес эшләгәннәр.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Әл-гасрел-җәдид. - 1906. № 2. - 91 б.
2. Шунда ук. - 92 б.

* Мәнһи - тыелган; мөшриклек - мәҗүсилек; тәүхид - бер генә Аллага ышану.

3. Шунда ук.
4. Шунда ук.
5. Шунда ук. - 93 б.
6. Шунда ук.

Татардагы мәгърифәтчелекне катгый төстә ваһһабичылыкка кайтарып калдыру белән килешеп булмый. Ваһһабичылар - борынгы «саф» ислам нигезләренә кайту тарафдарлары. Ә мәгърифәтчеләр, аерым алганда, Р.Фәхреддин, шушы нигезгә таянып, ислам тәгълиматын вакыт-заман таләпләреннән чыгып, иҗади рәвештә аңлау, үстерү позициясендә торганнар. - Ред.

А.Ю.Хабутдинов

РИЗА ФАХРЕДДИН И ТЕОЛОГИЯ ЭПОХИ ДЖАДИДИЗМА

Вопрос о соотношении религиозного и светского начал в татарском реформаторском движении конца XIX-начала XX вв. является одной из принципиальных проблем, определяющих сам ход формирования татарской нации. В современном определении указывается, что «нация - это большая социальная группа, характеризующаяся комбинацией нескольких типов отношений (экономических, территориальных, религиозных, культурных, языковых и тому подобных), возникающих, с одной стороны, из решения фундаментального антагонизма между человеком и природой на специфической компактной территории, с другой стороны, от отражения этих отношений в сознании людей»[1].

Основными условиями для полноценного национального существования являются: политический суверенитет, языковое и культурное единство и развитие законченной (полной) социальной структуры[2].

У мусульман России первым подобную теорию выдвинул в 1911 г. один из основоположников турецкого конституционного движения и лидеров мусульманского движения периода российской революции 1905-1907 гг. азербайджанец Ахмед бек Агаев. Он опубликовал в журнале «Тюрк юрду» статью под названием «Тюркский мир». Целью статьи был анализ формирования национального движения тюркских народов и прежде всего тюрок России. В ней дается анализ предпосылок возникновения таких явлений в тюркском обществе, которые автор обозначает французскими терминами «Nationalisme» (национализм) и «Coriscience Nationale» (национальное самосознание) и сравнительно-сопоставительный анализ с аналогичными явлениями у европейских народов. При этом он указывает, что «Nationalisme» (национализм) возник после Французской революции и был принесен из Европы на

мусульманскую почву от европейских учителей. Наиболее близкими процессами с созданием общности тюрок-мусульман России Агаев считает объединение Германии и Италии и завоевание независимости Балканскими государствами, то есть процесс превращения этнических общностей в нацию-государство (nation-state). У мусульман существовало два варианта этого проекта: федерация исламских государств (идея Джамалетдина Афгани и Мухаммада Абдо) и федерация тюркских государств под главенством Турции (идея Юсуфа Акчуры). Сам Агаев поддерживал последний вариант.

Важнейшими процессами, приведшими к образованию единства мусульманских народов России, Агаев называет создание новой литературы, прессы, возникновение промышленной и торговой буржуазии как класса у казанских татар и азербайджанцев, а также движение обновления, приведшее к овладению европейскими науками и возрождению исламских наук, то есть культурное и языковое единство и социальную стратификацию общества[3].

В 1913 г. Ахмед Агаев утверждал, что Французская революция 1789 г. оказала воздействие на последующие революции в России, Иране, Оттоманской Империи и Китае. Влияние революционной волны пересекло границы Европы. Прежде всего это было влияние ее идей, которое привело к распространению французских идей, прежде всего в форме распространения языка и культуры и создания «французской Европы»[4].

У татар первым выдвинул идею о взаимосвязи религиозного и светского реформаторского движения Юсуф Акчура в 1912 г. Акчура писал: «Несомненно, что в мыслительном и культурном движении северных тюрок в последние полвека я должен дать Шигабутдину Марджани особое место, это его место, по-моему, для признания его мысли и духа я доказываю посредством последующих событий, по-моему, Шигабутдин Марджани для начавшегося в нашем веке движения «таджаддуд» (реформации) самый великий предшественник (Precurseur)»[5].

С литературного арабского языка слово «таджаддуд» переводится как «самообновление». Современными учеными для обозначения джадидизма как общественного движения используется термин «тадждид» («обновление, реставрация, восстановление») для обозначения различия между реформой образования и модернизаторского движения мусульман России, в целом. Однако нам представляется более верным использовать для обозначения реформы образования термин «ысул джадид» (новый метод) и термин джадидизм (джадидчелек) для обозначения всего общественного движения. Использование терминов «таджаддуд» или «тадждид» связывает этот процесс с европейской реформацией, являвшейся прежде всего религиозным движением. Джадидизм же не обозначал изменение богослужебной мусульманской практики (гыйбадат) и догматики (акаид), а являлся преимущественно светским движением. Поэтому по примеру Ахмеда Агаева следует сравнивать это движение с процессом создания наций в Европе и использовать термин не «реформация», а «модернизаторство», как приспособление к реалиям современности.

Рассмотрим роль духовенства в движении за создание нации. При этом в случае различия в вероисповедании представителей правящей (милляте хакима) и подчиненной наций (милляте махкума) духовенство играло роль главного хранителя национальной традиции. Поэтому «движение духовенства за национальное самосознание и его политическая активность интенсивно продолжалось до того момента, пока национальное движение было сконцентрировано на культурных и языковых целях, и оно поддерживало идеологическое единообразие, не формулируя социальные или политические требования»[6].

Такая характеристика является верной для описания позиции официального мусульманского духовенства в лице Оренбургского Духовного Собрания. Однако целый ряд татарских богословов в период революции 1905-1907 гг. и позднее активно участвовал в мусульманском политическом движении, при этом такие улемы, как Галимджан

Баруди, Муса Биги и Габдулла Буби были избраны членами ЦК партии «Иттифак-аль-муслимин». Галимджан Баруди предлагался лично Гаспринским на пост Раис-уль-Улама, то есть главы религиозной автономии всех мусульман России. Позднее к ним присоединился Риза Фахреддин, оставивший пост казыя в 1906 г. и занявший место редактора журнала «Шура» - основного теоретического органа татарских джадидистов. Именно деятели круга Баруди и Фахреддин получили монопольный контроль над Духовным Собранием в мае 1917 г., и их позиции были подтверждены участием в «Милли Идарэ» в качестве членов коллегии «Диния Назараты». Сам Низам-Намэ (Устав) Диния Назараты был принят Миллет Меджлисе. Тем самым в организационном плане татарские улемы подчинились власти национального светского правительства и парламента.

Разумеется, мы не можем ставить вопрос о полном подчинении взглядов вышеупомянутых теологов доктрине джадидизма, как светского политического движения, направленного на создание нации мусульман России по европейскому типу. Вместе с тем необходимо поставить вопрос о том, насколько развитие светских институтов татарской нации получило теологическое обоснование.

Рассмотрим здесь позицию самого Фахреддина. Риза Фахреддин был противником так называемого «народного Ислама» с его культом святых. Он жестко критиковал языческие пережитки и выступал, в частности, против поклонения различным хранителям, а также «хужалар тавы» (горе хозяев) и «изгелэр чишмэсе» (роднику святых)[7].

Риза Фахреддин принадлежал и к той группе общественных деятелей, которые видели в деятельности Духовного Собрания прежде всего охранительные функции. Фахреддин сформулировал три основные задачи, обусловившие создание Собрания:

1) Привить любовь к России со стороны восточного Ислама;

2) Ослабить не имеющих официального статуса улемов, оказавшихся под скипетром России;

3) Превратить Ислам на берегах Волги и Урала в официальную религию и мазхаб и распространить везде мектебы и медресе[8].

В 1908 г., тогда уже бывший казый Риза Фахреддин, дал следующую характеристику школе среднеазиатской схоластики: «У нашего народа в течение почти целого века была введена схоластика. Латиняне (римляне - А.Х.) по причине схоластики вымерли. Греки погибли от схоластики». Фахреддин утверждал, что схоластика приводит к уничтожению и стагнации всех народов, использующих ее[9].

Таким образом, Фахреддин был противником как схоластического Ислама, так и Ислама народного в лице сект и местных культов. Следует отметить, что оба этих варианта являлись консервативными и выражали позицию противников реформы общественных учреждений, включая реформу Духовного Собрания и системы образования.

Риза Фахреддин в биографии великого улема и суфия Ибн-Араби писал, что религия Ислама должна давать людям ответы на все реалии современности и проблемы как этого, так и загробного миров[10].

В биографии Ахмада Мидхата Фахреддин утверждал, что необходимо как религиозное, так и светское знание. Он утверждал, что великие улемы Ибн-Рушд, Маари, Газали, Ибн-Араби и Ибн-Газали трудились во имя своей нации, Родины и религии[11].

Свое понимание идеальной личности татарского улема Фахреддин дал в биографиях Курсави и Марджани. Фахреддин начал биографию Курсави с определения его места среди улемов: «Его смерть была потерей не только для мусульман Казани и Булгара, но и потерей великого улема для всего мусульманского мира». Для Фахреддина улемы сохраняют свое бессмертие благодаря своим трудам и делам, и к таким персоналиям принадлежит Курсави.

Основное направление теологических трудов Курсави Фахреддин видит в акаид (догматике), где Курсави удалось доказать необходимость и каноническую безупречность нововведений и возобновления иджтихада. Фахреддин видит в «муджтахидлек дэгъвасы» (призыву к иджтихаду) у Курсави одновременно и продолжение традиции первых веков Ислама, то есть таких улемов, как Тафтазани, Дивани и Саид Ширази, и ориентацию на прогресс Ислама, его приспособление к эволюции общества, как у преемника Курсави Марджани и у Джамалетдина Афгани.

Фахреддин прямо говорит, что «муджатхидлек» занимались лучшие люди во все века, и он приводил к наиболее ярким и передовым изменениям. Причем именно «муджтахидлек» является лучшим методом для победы разума (аң). Фахреддин прямо ссылается на слова Джамалетдина Афгани: «В улучшении и очищении мусульманского шариата наш самый основной долг брать пример от умма зимми (немусульманских народов), исламская нация еще не готова выполнить этот долг». Фахреддин с сожалением говорит, что он слишком поздно понял эти слова и принял их суть, призывавшую мусульман к изучению всех современных наук и системы просвещения. Таким образом, для Фахреддина Курсави становится отправной точкой в попытке вывести мусульманский мир из-под влияния схоластики и обеспечить его постоянную эволюцию. Фахреддин призывает своих современников не повторять ошибки своих предков, а учиться всем наукам современности. Фактически в биографии Курсави Фахреддин впервые высказал свои тезисы, которые он будет развивать в своих философских работах 1910-х гг. и прежде всего в «Дини вэ иджтимагый мэсьэлэлэр» («Религиозных и общественных вопросах»)[12].

В биографии Марджани Риза Фахреддин приводит мнения о Шихабе-хазрете знавших его людей, в основном духовенства. Великий улем является для татар не только своеобразной точкой отсчета в общем для них движении, не только автором идей, теорий и представлений, вошед-

ших в плоть и кровь татарского общества, но и своеобразным провидцем, чьи расчеты являются актуальными для современников и потомков. Большинство свидетельств относится к реформаторской деятельности Марджани в сфере религии. В заключении статьи сам Фахреддин сравнивает Марджани с такими великими богословами-модернизаторами, как Джамалетдин Афгани и Мухаммад Абдо. Он говорит о сопротивлении многих «ысул джадид» («новому методу») и изучению европейских наук. Фахреддин писал: «Самый трудный объект для изменения - это вопросы религии, вопросы, так или иначе связанные с Шариатом. Один из улемов говорил: «Труднее изменить религию и привести ее к первоначальному состоянию, чем заложить основы новой религии»[13].

Поэтому в 1914 г. Риза Фахреддин выпустил книгу «Дини вэ иджтимагый мәсьәләләр» («Религиозные и общественные вопросы»), посвященную обоснованию реформ Нового времени и рассматривающую позицию правоверных мусульман по отношению к реформам. Само название работы говорит о необходимости синтеза религиозных и светских основ для развития исламской нации. В реформе права «Основные правила» зиждились на традиционной суннитской доктрине, что «Коран и сунна напрямую должны быть потребностью и доказательством для мусульманских правителей. Если это прямо нельзя найти там, то достаточно, чтобы доказательством были «иджма» (согласие) и «кыяс» (аналогия)». При этом при нововведениях необходимо использовать «известия ума, чувства, опыта, совести», которые «показывают свою близость к каждому из себя». Основным источником реформы права становилась «иджма», которая, «если она не противоречит Шариату, выражается в согласованном вынесении решений по реформам своего времени». При этом наряду с мнениями улемов, она учитывает позиции «глав благотворительных обществ, воинских командиров и глав других организаций, адвокатов и докторов, инженеров и торговцев, редакторов и писателей, рабочих». Таким образом,

Шура (Совет), принимающий правовые решения, превращается в орган мусульманской общины Нового времени. Шура должна действовать в соответствии с реалиями экономики и культуры и представлять собой союз всех классов, партий и обществ[14].

Фактически именно эта идея легла в основу создания Миллет Меджлисе, который представлял союз всех вышеупомянутых групп национальной элиты. На таком принципе представительства всех партий и общественных групп в 1917 г. строились и все местные мусульманские комитеты и бюро.

Фахреддин прямо ставил вопрос: «Зачем нужны усилия для «иджмы?» и отвечал: «Нации, которым приходится жить в мире, должны самостоятельно мыслить и в соответствии с изменениями времени и прогрессом нужно двигаться, чтобы политические, экономические и общественные дела соответствовали потребностям времени, их нужно соответственно обновлять и строить». При этом «в парламенте и Государственном Совете... нужно выполнять решения, согласные с Кораном и Сунной». Фахреддин считал, что «главная реформа» предстоит в сфере права. В итоге должна быть создана Конституция как «очень полезная вещь для исламского мира»[15].

Ислам должен сохранять значение как система мировоззренческих и моральных устоев: «Ислам, будучи универсальной религией, пригоден для всех времен, всех мест и государств, всех народов и наций. Если обязательно есть какая-то религия, которая пригодна для счастья в этом и том мире, для материальных и духовных достоинств, то эта религия, несомненно, религия Ислама». При этом мусульмане должны вернуться к истокам религии («саф дингэ юллары») времен асхабов. Фахреддин отметал позитивистскую доктрину об отсталости религии по сравнению с наукой, популярную среди социалистов и младотурок. Он заявлял, что когда «левые», являющиеся сторонниками европейского образования, утверждают, что «причиной нашего

упадка была религия», то они глубоко ошибаются. Для него только религиозность является основой высокой морали, поэтому «то, что люди религиозны, столь естественно, как и то, что они культурны». Образование для Фахреддина неразрывно связано с религиозным воспитанием[16].

Впрочем Фахреддин ставит вопрос не только о моральном и правовом самосовершенствовании мусульман. Он указывает на потребность развития военной сферы, говоря, что «нам нужны... пушки Круппа, железные дороги, юнкерские училища, кадетские корпуса, военные академии, броненосцы, миноносцы»[17].

Конечным идеалом Фахреддина является возникновение единого мусульманского правителя в лице халифа[18]. Если в вопросах участия в парламенте, создания собственного парламента или съезда, провозглашения конституции, реформы права, совмещения религиозного и светского образования Фахреддин в целом дает теологическое обеспечение программе «Иттифака», то в вопросе военного обучения и единого халифа он противоречит программе «Иттифака». Здесь его позиции сближается с позицией Габдерашита Ибрагимова. Характерно и то, что Фахреддин создает свою работу, формально не ориентируясь на конкретные условия России, а на условия всего мусульманского мира. Он также определяет «миллет» мусульман России прежде всего как часть мусульманской уммы.

Сходные идеи о единстве мусульманского мира в форме создания Шура-и-умма и о появлении единого исламского лидера на рубеже 1900-1910-х гг. высказывали не только такие сторонники исламского единства в лице Габдер. Ибрагимова и Зыи Камали, но и такой либерал, как Садри Максуди. Из этого следует, что в татарской национальной элите существовало понимание необходимости модернизации общественных институтов в сферах создания парламента, провозглашения конституции по образцу европейских государств при параллельном сохранении единства исламской уммы с ее догматикой и моральными основами. Эти

взгляды обозначали отход от традиционной исламской и оттоманской концепции «миллета» как конфессионального традиционалистского автономного образования в пользу создания постоянно модернизирующейся нации европейского типа. Эта задача занимала центральное место в деятельности татарских национальных лидеров после поражения российской революции 1905-1907 гг. и особенно младотурецкой революции 1908 г. вплоть до уничтожения Милли Идарэ в 1919 г. Татарским теологам и прежде всего Ризе Фахреддину выпала историческая задача богословского обоснования этих реформ, которая была им блестяще выполнена. Практическая реализация этих постулатов частично осуществилась в деятельности Милли Идарэ как единого органа, объединяющего в себе структуры как светской, так и религиозной автономии.

ПРИМЕЧАНИЯ

1. Hroch M. Social preconditions of national revival in Europe. - Cambridge, 1985. - P.4-5.
2. The formation of national elites: Comparative studies on govemments and non-dominant ethnic in Europe. - Vol.VI. - Dartmouth: New York University press, 1992. - P.1.
3. Агаев А. Түрк галәме. //Тюрк юрду. - 1911. - №2. - С.37-42, №3. - С.70-74; №5. - С.136-139, №7. - С.190-195.
4. Цит. по: Georgeon F. Des Ottomans aux Turks: Naissance d'une nation. - Istanbul: Les editions Isis, 1995. - P.176, 488.
5. «Мәрҗани» - Казан, 1915. - 425 б.
6. Hroch M. Указ.соч. - P.139-145.
7. Фәхреддин Р. Ибне Гарәби. - Оренбург, 1912. - 137 б.
8. Фәхреддин Р. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре. - 2 җөзьэ. - Оренбург, 1908. - 9-10 б.
9. Шунда ук. - 8-9 б.
10. Фәхреддин Р. Ибне Гарәби. - Оренбург, 1912. - 4 б.
11. Фәхреддин Р. Әхмәд Мидхәт. - Оренбург, 1913. - 138 б.
12. Фәхреддин Р. Асар. - 3 җөзьэ. - Оренбург, 1903. - 95-115 б.
13. «Мәрҗани» - Казан, 1915. - 382-390 б.
14. Фәхреддин Р. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр. - Оренбург, 1914. - 4, 67-68 б.
15. Шунда ук. - 67-69 б.
16. Шунда ук. - 131, 145, 160, 199 б.
17. Шунда ук. - 137 б.
18. Шунда ук. - 183 б.

А.Г.Хәйретдинов

РИЗА ФӘХРЕДДИН ҺӘМ МУСА БИГИЕВ

Исламиятнең күренекле галиме, тарихчы, публицист һәм рухани зат Риза Фәхреддинне XX йөзнең мәшһүр мөҗтәһиде, үзеннән унбиш яшькә кече булган Муса Жаруллаһ Бигиев (1873-1949) белән нинди уртак хезмәтләр һәм мөнәсәбәтләр бәйләгән соң? Әлеге мәкалә бу ике мәшһүр зат тормышындагы үзара аралашуларның кайбер сәхифәләренә багышлана.

1909 елда Муса Бигиевны Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә эшкә чакыралар. Бу чакыру, әлбәттә, очраклы булмый. Беренчедән, «Хөсәения» мәдрәсәсенең җәдиди юнәлештә эшләве үзенекен итә. Әлеге мәдрәсәнең тарихын өйрәнгән белгечләрнең раславына күрә, анда Бохара һәм Сәмәркандның кадими мәдрәсәләрен тәмамлаган мөгаллимнәр бик аз булган. Укыту ысулларын һәм алымнарын сайлаганда, аның эчке мохитен булдыруда мәдрәсәнең идарәсе Аурупа һәм Якын Көнчыгыш казанышларына йөз тоткан. Нәкъ менә шуңа күрә мәдрәсәдә укытучы мөгаллимнәрнең күбесе чит мөселман һәм Көнбатыш илләрендәге уку йортларын тәмамлаган затлар була. Аларның байтагы Идел-Урал мөселманнарының дини—иҗтимагый тормышында эз калдырып өлгергән шәхесләрдән хисаплана[1].

Муса Бигиев нәкъ шушындый кешеләрдән була. Мәдрәсәгә чакырылганчы Беренче Русия революциясе елларында ул Петербургта Габдерәшит казый Ибраһимов белән берлектә «Өлфәт» гәзитен чыгара, беренче мөселман съездларының эшендә катнаша, аларның документларын нәшер итә. 1905 елда, чит илдә вакытта, «Тарих әл-Коръән вәл-Мәсахиф» дигән хезмәтен бастыра. 1907-1908 елларда аның тагын берничә китабы дөнья күрә. Алар арасында Әбү Әл-Әгъләә Әл-Мәгарринең «Әл-Лөзүмиять» исемле шигъри җыентыгының тәрҗемәсе, борынгы мөселман галимнәренең әсәрләренә шәрехләр, «Әдәбияты гарәбия илә голүме исламия» исемле әсәре, абыйсы Мөхәммәдзаһир Бигиев-

